# БАЛАЧАК ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

ИКЕНЧЕ КИТАП



КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2010

УДК 821.512.145-1+3
ББК 84(2Рос=Тат)-4+5
Б20

Төзүчеләре:
*Талия Шакирова, Ленар Шәех*

Рәссамы *Алсу Тимергалина*

Б20 Балачак энциклопедиясе : икенче китап / төз. : Талия Шакирова, Ленар Шәех. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 200 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-01933-0

Татар язучыларының биографияләрен, портретларын, күренекле әсәрләрен үз эченә алган, төсле рәсемнәр белән бизәлгән «Балачак энциклопедиясе»нең әлеге икенче китабында кырык өч язучы урын алган.

Җыентык ата-аналарга, тәрбиячеләргә, укытучыларга мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары белән бергәләп уку өчен тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-1+3
ББК 84(2Рос=Тат)-4+5

Литературно-художественное издание

Для детей дошкольного и младшего школьного возраста

ЭНЦИКЛОПЕДИЯ ДЕТСТВА

**Книга вторая**

Составители: ***Шакирова*** *Талия Ривовна,* ***Шаехов*** *Ленар Миннемохимович*

Казань. Татарское книжное издательство. 2010
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

БАЛАЧАК ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

**Икенче китап**

Төзүчеләре: ***Шакирова*** *Талия Риво кызы,* ***Шәехов*** *Ленар Миңнемөһим улы*

Мөхәррире *Т.Р.Шакирова.* Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин.* Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова.* Корректоры *Г.М.Хәбибуллина.* Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.12.2010. Форматы 84×108 1/16. Шартлы басма табагы 21,0. Тиражы 2000 д. Заказ О-1703. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. **http://tatkniga.ru. E-mail: tki@tatkniga.ru.** Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978-5-298-01933-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Шакирова Т.Р., Шәехов Л.М., төзү, 2010
© Тимергалина А.А., рәс., 2010

# Дәрдемәнд

*(1859–1921)*



**Туган көне**

23 нче ноябрь.

**Туган урыны**

Башкортстанның Мәләвез районы Җиргән авылы.

**Тормыш юлы**

Дәрдемәнд (Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев) сәүдәгәр гаиләсендә туа. 1862 елда аларның гаиләсе Орск өязендәге Юлык авылына күчеп китә. Әтисе шунда алтын приискасы ачып җибәрә. Мөхәммәтзакир Моллакай авылы мәдрәсәсендә белем ала. 1880 елда Төркиягә китеп, бераз вакыт Истанбул шәһәрендә яши, үзлегеннән төрек телен һәм әдәбиятын өйрәнә. 1881 ел ахырларында Россиягә кайткач, ул абыйсы Шакир Рәмиев белән бергәләп нәшрият ачу артыннан йөри, ләкин, патша цензурасы рөхсәт бирмәү сәбәпле, бу уен тормышка ашыра алмый. 1906 елда алар абыйсы белән бергәләп «Вакыт» исемле көндәлек газета, 1908 елда «Шура» дигән әдәби-иҗтимагый журнал чыгара башлыйлар. Бу басмаларда Г.Ибраһимов, Ш.Камал, М.Гафури, Ш.Бабич кебек әдипләрнең милли идеяләрне яклаган әсәрләре басыла. Дәрдемәнд үзе дә, шагыйрь буларак, шушы басмалар аша танылa. Әмма газетаның аерым саннарын чыгару тыела. Газетаны саклап калу өчен аларга байтак тырышырга туры килә. 1912 елда абыйсы Шакир фаҗигале төстә һәлак булгач, газета-журнал чыгару мәшәкатьләре тулысы белән Дәрдемәнд җилкәсенә төшә.

1917 елгы Октябрь революциясеннән соң Дәрдемәнднең алтын приискалары конфискацияләнә, газета-журналлар чыгудан туктатыла. Шагыйрь башта гаиләсе белән Оренбургта яши, соңрак Орск шәһәренә күчеп кайта. Анда мәдәният эшләре белән шөгыльләнә, татар орфографиясен камилләштерү проектларын төзи. Иҗат эшен дә туктатмый.

Дәрдемәнднең әдәби мирасы сәнгатьчә эшләнеше, эстетик көче ягыннан татар әдәбиятының хәзинәсе булып тора. Ул аз сүз, кыска җөмлә-гыйбарәләр белән гаҗәеп җанлы шигъри сурәт тудыра. Аның поэзиясе үзеннән соң килгән татар шагыйрьләре өчен осталыкка өйрәнү мәктәбе булып хезмәт итә.

**Төп басма китаплары**

* Сайланма әсәрләр / төз. И.Рәмиев. Казан : Татар. кит. нәшр., 1959.

* Исә җилләр : шигырьләр, истәлек-парчалар, вак хикәяләр / төз. һәм иск. яз. Р.Даутов. Казан : Татар. кит. нәшр.,1980.

* Бәллү : шигырь. Казан : Татар. кит. нәшр., 1990.

* Агарган кыл : шигырьләр / төз. Р.Харис. Казан : Мәгариф, 1999.

* Дәрдмәнд : фотоальбом / төз., фоторәс. һәм макет авт. З.Бәширов; текст авт. Л.Хәмидуллин. Казан : Татар. кит. нәшр., 2003.

* Дәрдемәнд. Дэрдменд : шигырьләр = стихотворения / авт. предисл. и пер. с тат. В.Думаева-Валиева. Казань : Татар. кн. изд-во, 2009.



## БАЛАЛАР, ӘЙДӘ МӘКТӘПКӘ

Балалар, әйдә мәктәпкә,
Әтәч кычкырды күптән!
Тезелегез, кил рәткә,
Карады кояш та күктән.

Кошлар, кортлар һәм кеше –
Һәркайсы эш башлады.
Һәркемнең бар бер эше –
Берәү дә эштән качмады.



Бак, кырмыска йөк ташый,
Бал корткае – татлы бал.
Кошкай ояга мүк ташый,
Коштан, корттан гыйбрәт ал!

Басуда, кырда эш тулды,
Уянып урман шаулыйдыр.
Тукран күптән тукылдый,
Сандугачкай сайрыйдыр.

# ИКЕ ТУГАН

Борын-борын бар иде ике туган: сеңел белән абзый – тавык белән әтәч. Көннәрдән бер көн бакча эчендә йөргәннәрендә, әтәч карлыган күрде. Күрде дә пешмәгән яшел карлыганнарны чукып ашамага да кереште.

Сеңлесе тавык кычкыра:

– Туганым, куй, ашама! Карлыган пешеп өлгерсен, сабыр ит! – диде.

Тыңламады әтәч, чукыды ашады, чукыды ашады. Тәмам туеп булгачтын гына, ава-түнә өйләренә кайтты.

– Уф! – диде, әтәч әйтә, – эчем авырта!

Менә бөгәрләнеп сызлана башлады. Менә үкереп елый...

– Уф Алла! – ди. – Сеңлем, үләм инде!

Сеңлесе тиз шкафтан шешәләр карап, абзасына дарулар тамызып эчерде. Эченә горчица япты. Берничә көннәр узгачтын гына, әтәчнең сәламәтләнеп күзләре ачылды.

Әтәч инде тәмам сәламәтләнде, менә алар беркөнне кырга чыктылар. Кырның өстен хәтфә кебек йомшак үләннәр каплаган. Ямь-яшел! Төрле чәчәкләр үсә, матур күбәләкләр оча, чикерткәләр сикерә...

– Әйдә йөгереп уйныйк! – ди, тавык әйтә.

– Әйдә йөгереп уйныйк! – ди әтәч тә.

Әй йөгерәләр, әй уйныйлар! Әй йөгерәләр, әй уйныйлар!

– Беләсеңме? – ди, тавык әйтә. – Йөгереп уйнау бик файдалы була... Мин абыстаемнан ишеттем, – ди.

– Мин дә хәлфәмнән ишеттем, – ди әтәч, – йөгереп уйнау бик файдалы була...

– Әйдә тагын йөгерик!

– Әйдә йөгерик!

Әй йөгерәләр, әй уйныйлар. Әй йөгерәләр, әй уйныйлар! Тирләделәр, пештеләр. Бик сусадылар. Якында гына бер болак бар иде, суы салкын! Таштан ташка чылтырап ага... Йөгерде әтәч су эчәргә!

– Туганкаем, куй! – ди, тавык кычкыра. – Тирең кипми торып, эчә күрмә! Сабыр ит, – ди, – тирең кипсен.

– Йә, ни булыр дисең! Янып барамын ич, – ди әтәч.



Эчте дә эчте салкын суны тирле көенчә! Менә инде үзен бизгәк калтыратып селкетә башлады – тешләре шакылдый! Хәле бетте... Бичара, көчкә өйләренә кайтып егылды, тавыкның җилкәсенә таянып.

Шәфкатьле сеңлесе тиз докторга йөгерде. Дарулар алып кайтты, әч-че! Йа, нинди тәмсез! Әмма эчмичә хәл юк – үләсе килми бит! Бичара әтәч! Айлар буена түшәк өстендә калды, кузгалмастай. Әтәчнең сәламәтләнеп тышка чыга башлаганында тәмам инде көз булып җиткән иде. Беркөнне әтәч карый – күлнең өстен боз каплаган... Шоп-шома, йа Рабби, ялтырый – көзге кебек!


– Иһ-һу-у-м! – ди, әтәч әйтә. – Тукта, коньки шуыйм!

– Куй, батырым! Әйтә күрмә. Боз әле бик юка, – ди сеңлесе тавык. – Сабыр ит, боз бераз калынайсын.

Тыңлыймы соң тискәре! Йөгерде каршы боз өстенә. Шуып кына киткән иде, булт итте – төште-китте суның төбенә! Мескеннең йон гынасы калды ике бөртек боз өстендә...

# Фәхрелислам Агиев

*(1887–1938)*



**Туган көне**

12 нче март.

**Туган урыны**

Мордовиянең Краснослободский районы Тенеш авылы.

**Тормыш юлы**

Фәхрелислам Агиев, авыл мәдрәсәсендә башлангыч белем алгач, бер сәүдәгәргә ияреп, Харбин якларына чыгып китә, яллы эшләрдә йөри. 1906 елда Казанга килә һәм, экстерн тәртибендә Татар укытучылар мәктәбе программасы буенча имтихан тапшырып, башлангыч рус-татар мәктәпләре укытучысы дигән рәсми таныклык ала. 1908–1915 елларда Казан мәктәпләрендә укыта, 1913–1916 елларда балалар өчен «Ак юл» исемле журнал чыгара. Октябрь инкыйлабыннан соң ул, нигездә, тәрҗемә эше, уку китаплары төзү белән шөгыльләнә. 1917–1924 елларда Ф.Агиев туган ягында волость ярлылар комитеты рәисе, губерна татарлары арасында мәгариф эшләрен оештыручы була, Пенза шәһәрендә «Сабанчы» газетасын чыгаруда актив катнаша. 1924 елда Мәскәүгә күчә һәм РСФСР Мәгариф комиссариатында инструктор-методист, СССР халыклары Үзәк нәшриятының татар бүлеге сәркатибе, Үзәк татар драма театрының директоры булып эшли. Ялган гаепләүләр тагылып, 1930 елда ул кулга алына. 1938 елда Мәскәү төрмәләренең берсендә атып үтерелә.

Ф.Агиев шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, уку-укыту һәм тәрбия мәсьәләләренә, мөгаллимнәр тормышына караган мәкаләләр яза. Аның иҗаты бүгенге көндә тулаем өйрәнелмәгән.

**Төп басма китаплары**

* Куяннар : хикәя. Казан : Мәгариф, 1921.
* Сукыр Ильяс : хикәя. Казан : Мәгариф, 1921.
* Хикәяләр җыентыгы. Мәскәү : Нәшр. кооперативы матбагасы, 1926.
* Мәрхәмәт: хикәяләр һәм әкиятләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1990.

## КЕЧКЕНӘ КАРАК

Көннәрдән бер көнне кечкенә генә бер Күсе мәчеләр өеннән бер кисәк эремчек урлады. Карак кергәндә, сакларга калган Мәче йокымсыраган иде. Шуңа күрә кечкенә каракның эремчекне урлап китүен сизми дә калды.

Сакчы Мәче кисәктән генә уянып китте, аны кемдер энә белән чәнечкән кебек булды. Күзләрен ачып җибәрсә, ни күзе белән күрсен, эремчектән җилләр искән!



Мәче ары йөгерде, бире йөгерде, берни дә чыкмады. Каракның эзе дә юк. Шуннан соң ул елый-елый урамга чыкты. Ишектән генә чыккан иде, аны полицейский Мәче туктатты.

– Кара әле, чибәр егет, урамда еларга ярамый, – диде ул.

– Еларга ярамый, дигән була. Эремчегеңне урласалар, син дә елар идең, – диде сакчы Мәче.

– Юләр, аны башта ук шулай дип әйтәләр. Мин синең эремчегең югалганын кайдан белим?! Менә без хәзер ул явыз каракны эләктерербез, – дип, полицейский Мәче сакчы Мәчене юатты да үзе, иптәшләрен алып, каракны эзләргә китте.

Күп тә үтмәде, полицейский мәчеләр кечкенә карак Күсене, ике кулын артка бәйләп, хөкемгә алып килделәр. Ул бичара әле эремчекне ашап та өлгермәгән иде. Карак белән бергә эремчекне дә китерделәр.

Эремчек полицейский мәчеләрнең күзен яндырды. Эремчек исенә чыдый алмый, алар мырылдаша башладылар. Эремчек аларның һушына шулкадәр китте ки, аны кулдан кулга йөртеп, кечкенә каракны бөтенләй оныттылар. Үз чиратында кечкенә карак та авыз ачып тормады. Әкрен-әкрен артка чигеп сызды да китте. Ләкин мәчеләр моңа кайгырмадылар. Карак күздән югалса да, эремчек аларның күз алдында иде.



## СӘМРУГ ҺӘМ МАЙ КОҢГЫЗЫ



Борын-борын заманда булган, ди, тыныч кына торган дөньяда бер кечкенә генә Май коңгызы. Кайгылы көннәрендә кайгысын, шатлыклы көннәрендә шатлыгын уртаклашучы хатыны да булган, ди. Болар әбиле-бабайлы бик шәп, бик тату торганнар.

Май коңгызының ире үзен-үзе иң зур, иң көчле батырлардан санаган, ди. Бөтен дөнья халкы миңа гына карап тора, ничек миннән курыкмасыннар, көчледән куркалар шул, мин батыр булганга, миннән куркалар шул, дип, карчыгы алдында һәрвакыт мактана торган булган, ди. Бервакыт шулай мактанып торганда, һавада очып баручы кошны күргән, ди.



Менә сиңа батыр, менә сиңа көчле! Сәмругны күрү белән, ул тыз-быз килеп кычкырырга, канлы яшьләр түгеп еларга тотынмасынмы?!

– Карчык, кайда син, харап булдым, Сәмруг минем түбә өстемнән генә оча, мине чукып алмакчы була. Кая, тизрәк китер балаларны, килегез тизрәк һәммәгез! Ичмасам, соңгы минутларымда сезнең белән күрешеп калыйм. Әй Алла, харап булдык... – дип, дөньяны яңгырата башлаган, ди.

Май коңгызының бу кыланышларын күргән, кычкыруларын тыңлап торган Карга эче катканчы көлгән, ди, һәм Май коңгызына әйткән, ди:


– Әй юләр коңгыз, юләр коңгыз! Сәмруг түгел, мин дә сине чукып торуны үзем өчен кимчелек саныйм. Сәмруг түгел, чыпчык чукырлык та итең юк лабаса, дөнья күтәреп дулаган буласың шунда, – дип әйткән, ди.



Май коңгызы, башын күтәреп, Каргага караган да оятыннан колак артларына кадәр кызарып, оясына кереп киткән, ди.

# Галимҗан Ибраһимов

*(1887–1938)*



**Туган көне**

12 нче март.

**Туган урыны**

Башкортстанның Авыргазы районы Солтанморат авылы.

**Тормыш юлы**

Галимҗан Ибраһимов күрше Кешәкне авылы мәдрәсәсендә һәм бер үк вакытта туган авылындагы өч сыйныфлы земство мәктәбендә русча башлангыч белем ала. 1898–1909 елларда Оренбургтагы Вәли мулла, Уфадагы «Галия» мәдрәсәләрендә укый. Берникадәр вакыт казакъ далаларында, Әстерхан якларында мөгаллимлек иткәннән соң, 1909 елда Казанга килә. Бу чорда ул проза жанрында актив эшли, әдәби тәнкыйть һәм публицистика өлкәсендәге эшчәнлеген җәелдереп җибәрә. 1912–1913 елларда Киевка китә һәм университетта ирекле тыңлаучы сыйфатында укып йөри. Киев мөселман студентларының яшерен сәяси оешмалары эшендә катнаша. Шул эше өчен төрмәдә утырып чыга. 1913–1914 елларда Казанда чыга башлаган «Аң» әдәбият-сәнгать журналында җаваплы сәркатип булып эшли. 1915–1917 елларда «Галия» мәдрәсәсендә укыта. 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соң «Ирек», «Безнең юл», «Чулпан» газеталарында баш мөхәррир вазифасын башкара. Мәскәүдә һәм Казанда җыелган Бөтенроссия мөселманнарының ике корылтаенда, Уфада узган Милләт Мәҗлесе утырышларында катнаша. 1927 елга кадәр Казанда татар иҗтимагый-мәдәни тормышының һәм әдәби хәрәкәтнең алгы сызыгында торып эшли, яңа матбугат чараларын, Татарстан китап нәшриятын оештыруга, мәгариф системасын яңача коруга, яңа милли кадрлар тәрбияләүгә зур көч куя. 1927 елдан Г.Ибраһимов, үпкә авыруы көчәю сәбәпле, Кырымда яшәргә мәҗбүр була. Узган гасырның 30 нчы еллар ахырында башланган репрессияләр шаукымы аны да читләп үтми. 1937 елның 29 августында ул кулга алына һәм 1938 елның 21 гыйнварында Казанның Пләтән төрмәсе хастаханәсендә вафат була.

Г.Ибраһимов – әдәби әсәрләре белән генә түгел, әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть, тел гыйлеменә караган хезмәтләре белән дә татар мәдәниятен баеткан, аны үстергән әдип. Утыз еллык иҗат гомерендә ул егермеләп хикәя, дүрт роман, биш повесть, бер пьеса, унике фәнни хезмәт, тел-әдәбият буенча дистәдән артык дәреслек, әдәби тәнкыйть һәм публицистика буенча биш йөзгә якын мәкалә яза.

**Төп басма китаплары**

* Сайланма әсәрләр : 5 китапта. Казан : Татиздат, 1933–1934.
* Сайланма әсәрләр : 3 томда. Казан : Таткнигоиздат, 1956–1957.
* Әсәрләр : 8 томда. Казан : Татар. кит. нәшр, 1974–1986.
* Адәмнәр : хикәя, повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1998.
* Хикәяләр, повесть, роман. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2007.

---

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Галимҗан Ибраһимов исемен йөртә.

1987 елдан Башкортстан Республикасы Авыргазы районы Солтанморат авылында Галимҗан Ибраһимовның музее эшли.



## АЛМАЧУАР

*(Хикәядән өзек)*

Көткән көннәр якынлыйлар.

Бурлы бия буаз. Без хәзер аны җикмибез. Җиксәк тә, бик җиңелгә, якынга гына.

Әнкәй моның өчен һаман сукрана:

– Ике атың бар өстеннән нәрсә шул хәерче кебек лырт-лырт бер белән йөрисең? – ди.

Әткәй аны бер сүз белән туктата:

– Йә, куй шул сукрануыңны, – ди, – нигә, – ди, – баланы юкка елатырга, – ди.

«Бала» дигәне мин булам.

Чыннан да, берәр авыр йөккә, ерак җиргә җигә башласалар, мин әткәйгә барып сыенам, иркәләнәм; ул минем күзләремдә мөлдерәп төшәргә-ташырга торган күз яшьләремне күрә дә, мыек астыннан көлеп, башымнан сыйпый:

– Йә, син, Закир, юкка җылап барма... Ярар, җикмәбез, – ди.

Мин шатлыгымнан кая сикерергә урын тапмыйм. Көн буена аягым кая басканны белмим. Ни кушсалар, минуты белән эшлим.

Кайберәүләрнең бияләре кар эри башлагач та колынлады; язгы сабанга чыккач инде авылда һәр йортта диярлек колыннар күренә торган булды.

Әнә алар инде уйнаклап йөриләр. Әнкәләреннән аз гына калсалар, үзләренең яшь, көмеш тавышлары белән бөтен тауны, урманны яңгыратып кешниләр.

Их, кайчан минем колын да шулай булыр икән?! Хәер, күп көттермәс инде: бияңең эче калынайганнан-калыная бара. Сафа бабай әйтә, озакламас, колыннар инде, ди. Күз-колак була торырга кирәк, ди.

Малайлар мине һаман:

– Сөенчегә нәрсә бирәсең, Закир? – дип шаярталар.

– Шауламагыз, бирәсе әйберем әллә кайчан әзерләнгән. Тик тизрәк тусын гына!

Соңгы көннәрдә әткәй белән бик нык бәрелешү дә булып алды.

Колын итен бүреләр бик яраталар булса кирәк. Фәхриләрнең матур бер колыны бар иде. Төнлә шуны бүре ялалаган, ди. Кичә шуны ишеткәч, әтидән сорамыйча-нитмичә, нукта тоттым да йөгердем. Бияне яланда калдырырга ярамый. Кем белә, төнлә очрар да, колынны бүре ашап китәр!

Бик ерак түгел икән. Тиз таптым. Тотар өчен икмәк катысы да алып барган идем. Элек ул, аз гына кул сузып чакырсаң, үзе үк килә торган иде... Бу арада әллә ничек үзгәреп тора: юк-барга ачулана, якын барсаң, өстеңә йомылып килә.

Әле дә бардым. Икмәкне күрсәтеп чакырдым. Элекке кебек тоттыру кая, пырых-пырых итеп, үзалдына холыксызланып кызып тора. Мин аны тота алмыйча елап кайттым да әтигә ялына башладым:

– Колынлар чагы җиткән, – дим, – йортта гына асрыйк... Мин аны үзем карар идем, – дим.

Әти риза булмый:

– Ашатырга азык юк... Бернәрсә дә булмас, шунда болында, елга буенда йөрсен, – ди.

Мин еларга тотынам. Бүре куркынычын сөйлим. Әти һаман үзенекендә тора:



– Акылсыз булма. Авыл янындагы болынга бүре килми ул, – ди. – Йортта ашатырга юньле нәрсә юк, монда тотсаң, колыны начар булыр, – ди. – Бик курыксаң, малайлар белән көндез каравыллап йөр, кич өйгә кайтарырсың, – ди.

Бияне яхшы ашатмасаң, колыны начар була, дигән сүз мине җиңде. Мин башаяк риза булдым.

Тавык ояларыннан йомырка урладым. Яшереп куйган шырпыны алдым да, шуларга алдап, малайларны үзем белән елга буена, болынга, бия каравылларга алып китәргә әзерләнә башладым.

Көн матур. Язгы кояш нуры минем күзләремә карый. Ул, ахрысы, минем шатлыкны сизәдер, бераз елмайган кебек тоела.

Йомырка белән шырпы барлыгын белгәч, малайлар, сикерә-сикерә, минем белән бия сакларга бармакчылар.

Мин бер атуда ике куянны алмак булам: бияне дә сакларга, балык та тотарга. Балык дигәч, малайлар бары беравыздан Кондызлы күл ягына тарталар:

– Анда каптырырга да әйбәт, менә дигән чуртаннар, алабугалар да эләгә... – диләр.

Фәхри малае күзләрен елтырата-елтырата сөйли башлый:

– Без өченчекөн, – ди, – иртән, көтү киткәч барган идек, кояш төшлеккә җиткәнче каптырдык... Галәви – утызны, мин егерме дүртне алдым... Арада беләк юанлыгы кызылканатлар бар иде, бик зур бер җәен эләккән иде, җебем чыдамады, кармакны өзеп алып китте, – ди.

Боларны ишеткәч, башкаларның да күзләре кыза, барысы да, риза булып, шул Кондызлы күл ягына йөгерергә торалар.

Кызылканатлар, җәеннәр дигәч, мин дә, үземне-үзем онытып, иптәшләргә кушыла язган идем, бүген-иртәгә колынларга торган бурлы бия хәтеремә килгәч, кинәт туктадым:

– Юк, мин анда бармыйм, – дим, – әйдәгез Өзән елгага барыйк, анда да шәп каба, – дип, бурлы бия ягына тарта башладым.

Мин ялгыз идем.

Шулай да җиңдем: минем ак киез эшләпәгә тутырылган йомыркалар белән шырпыны исләренә төшергәч, малайлар риза булдылар.

Шул ук Апуш:

– Әйдәгез Өзән елганы сынап карыйк... Анда да былтырларда мин зур бер сазан белән шүкәләр эләктергән идем, – ди башлады.

Кармакларны, селәүчәннәр, икмәкләр, йомыркалар, шырпыларны алабыз да кыйбла якка, якты кояшка карап, болын буйлап Өзән елгага чабабыз...

Алабугамы, сазанмы эләгер, бөтенләй буш кайтырбызмы – миңа алары кыйбат түгел; минем бүген-иртәгә колынларга торган бурлы биям Өзән елга буенда, болынлыкта йөри. Әткәй аның муенына зур арканны бәйләгән дә тышауламый-нитми генә җибәргән. Арканның икенче башына кызыл калын дуга тагылган. Минем бөтен күңелем менә шул дугасын, арканын өстерәп су буенда, таллар арасында акрын гына йөргән бурлы биядә.

Без авылдан чыкканда, көн матур, җил юк иде. Болында безне кошлар сайрап каршы алдылар. Минем булачак колынымның әнкәсе, без барып җиткәндә, Әчеле тамак ярында ашамый-нитми, башын түбәнгәрәк салып, тик кенә тора иде. Ул миңа нәрсәдер уйлый кебек тоелды. Малкаем, син ни турында уйлыйсың? Аны күргәч, малайлар мине үрти-үчекли башладылар. Берсе әйтә, айгыр булыр, ди; берсе, бия булыр, ди... Миңа барыбер, тик исән-сау гына күрергә язган булсын иде.

# Нәкый Исәнбәт

*(1899–1992)*



**Туган көне**
29 нчы декабрь.
**Туган урыны**
Башкортстанның Салават районы Малаяз авылы.
**Тормыш юлы**

Нәкый Исәнбәт 1911–1913 елларда Уфадагы «Хәсәния», 1913–1916 елларда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укый. 1917 елдан татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Ике ел Уфа халык мәгарифе институтында белем алганнан соң, 1921 елда Харьков университетының 3 нче курсына укырга керә. Ләкин университет мәгариф институтына әверелү һәм укыту украин теленә күчү сәбәпле ул укуын ташларга мәҗбүр була. 1923 елдан Н.Исәнбәт Уфада яши, 1930 елның башында Казанга күчеп килә. Шул ук елның август аенда «Җидегән» дигән «яшерен контрреволюцион» оешмада әгъза булып торуда гаепләнеп, ун ел дәвамында әдәбияттан читләтелеп яши, укытучы булып урнаша алган төрле мәктәп-техникумнардан да куылып тора. Гаилә тормышын алып бару өчен, «Спартак» аяк киемнәре фабрикасына кара эшче булып урнаша. Бары 1930 еллар ахырында, Мәскәүдәге татар сәнгате декадасына әзерлек башлангач кына, ул әдәбиятка кире кайта ала. Шул вакыттан башлап, Исәнбәт, профессиональ язучылык хезмәтенә күчеп, әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Н.Исәнбәт матбугатка беренче мәртәбә 1914 елда «Ак юл» дигән балалар журналында шагыйрь буларак чыга. Иҗатының икенче төп тармагы драматургиягә дә ул яшьли килә. 1920 елларда, Уфа, Казан, Мәскәү театрларында куелган комедияләрдән башлап, үзен трагедия һәм драма остасы итеп тә таныта. Сәхнә кагыйдәләренә сизгер автор тамашачыны тетрәтә дә, көлдерә дә, юата да белә.

Исәнбәт – татар халкының рухи мирасын, тел-әдәбият хәзинәләрен, тарихи ядкарьләрен, фольклорын җыю-барлау, гыйльми өйрәнү һәм аларны системага салып, бастырып чыгару өлкәсендә армый-талмый эшләгән галим-энциклопедист та. Ул «Идегәй» дастанының җыйналма текстын эшләп дөньяга чыгара (1940). Аның өч томлык «Татар халык мәкальләре» (1959–1967) һәм «Татар халык табышмаклары» (1970) бу өлкәдә дөньяда иң күләмле җыентыклардан санала.

Нәкый Исәнбәт балалар өчен дә иҗат итә. Унсигез елын яшьләрне укытуга багышлаган язучы моны үзенең изге бурычы дип саный.

**Төп басма китаплары**
* Табышмаклар. Казан : Татгосиздат, 1941.
* Куянкай. Казан : Таткнигоиздат, 1956.
* Куян маҗаралары. Казан : Татар. кит. нәшр., 1958.
* Бәрәзә песие Мыраубай батыр маҗаралары һәм башкалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1974.
* Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. Казан : Татар. кит. нәшр., 1984.
* Әсәрләр : 4 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1988–1989.
* Татар теленең фразеологик сүзлеге : 2 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1989–1990.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе (1957, 1959), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1968), Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары кавалеры (1957, 1970, 1979), Татарстанның халык язучысы (1986).

## ТЫЧКАН, ӘТӘЧ, ПЕСИ

*(Мәсәл)*



Йөрергә чыккан
Бер нәни тычкан
Үз әнисенә
Кайтып сүз кушкан:
– Әни, әнкәем,
Йөргәндә йортта,
Очрадым анда
Ике ерткычка.
– Әйтче, бәбкәем,
Нindиләр алар?



– Алармы, алар –
Берсе зур җанвар!
Кигән мамыктан
Галифи чалбар.
Башында тарак,
Койрыгы урак.
Тордым мин аңа
Шаккатып карап!..
Борыны да кәкре,
Үзе бик эре.

Ай-һай бик усал,
Кып-кызыл сакал!..
Үзе итектән,
Балтыры чиккән,
Үкчәсе сырлы,
Үткен шпорлы...
Янарал кебек,
Үкчәсен тибеп,
Баса маршка
Бүксәсен киереп!..
Кычкырды бер рәт:
– Кик-ри-күк!.. – Кинәт!
Кот та калмады...
Качтым мин тизрәк!..
– Ай балам, балам,
Ай җүләр балам,
Ул – әтәч булыр,
Курыкма син аннан.
Йә, икенчесен
Ничек күрдең син?
– И-и әни, әни,
Ансы бик нәни.
Безнеке кебек,
Туны мамыктан,
Үзе мыекчан,
Йөри оекчан...
Сырты бик матур,
Буй-буй сызыклы.
Тик ул зур(ы)рак,
Бездән олырак.
Үзе гел миңа
Елмаеп карый.
Койрыгын үзе
Янга суккалый...
Ай юаш, юаш...
Бу кадәр булмас,
Бу кадәр холкы
Безгә охшамас!..
Карый яратып,
Миңа җан атып.
Әни, ул миңа
Ымлый шаяртып.
Ул шундый юаш,
Ягымлы булгач,
Чыгып уйныймчы
Янында бераз?
– Ай надан балам,
Ай җүләр балам!..
Шул бит күргәнең
Дошман – Мырауҗан!..



## ӘННӘ КУЯН

Мин – куяннар әннәсе,
Әннәсе дә нәннәсе.
Өчәү минем бәбием;
Өчәве дә – нәнием.

Бер малаем – Лүрт-лүрт.
Икенчесе – Һүп-һүп!
Өченчесе бик шаян,
Ике күзе дүрт-дүрт!

Өчесе дә – сикергеч,
Өчесе дә – чабышкы,
Өчесе дә – мыеклы,
Өчесе дә – мамыклы.

Өчесе дә – тәп-тәти,
Өчесе дә – ак кына.
Өчесен дә яшердем
Әрекмән куак астына.

Әй яшердем, яшердем –
Карга, козгын күрмәсен,
Төлке явыз элмәсен,
Аучы, юлчы сизмәсен!

Әй яшердем, яшердем –
Күрмәсеннәр берсе дә,
Һәммәсе дә дошманым,
Ышанмыйм һичберсенә!





## ӘБӘК

*(Уен)*

– Син – ак куян,
Йомшак куян;
Әбәк, әбәк!
Син кач, куян!

– Мин – күк куян,
Йөгерек куян;
Әбәк, әбәк!
Син тот, куян!



## БАКЧАДА

Әлли итеп ал үскән,
Бәлли итеп гөл үскән,
Гөлләр-гөлләр эчендә
Гөлдән чибәр кыз үскән...


Чибәр, чибәр, чибәр кыз!
Чибәр чигү чигәр кыз!
Яныңдамы кубызың?
Яле, чиртеп җибәр, кыз.

Күр, әйләнә күбәләк,
Каш очында түгәрәк.
Әйдә, булсын бер мәзәк,
Әйләнегез бергәләп.

Күбәләкләр күмәкләр,
Бигрәк нәни кунаклар.
Кач, үзеңне куалар,
Каш очыңа куналар!..

# Хәсән Туфан

*(1900–1981)*



**Туган көне**
9 нчы декабрь.
**Туган урыны**
Татарстанның Аксубай районы Иске Кармәт авылы.
**Тормыш юлы**

Хәсән Туфан туган авылындагы җәдит мәктәбендә һәм Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә белем ала. Җәйге каникул вакытларында үсмер егет, укуын дәвам итәргә акча юнәтү максаты белән, Урал рудникларында шахтёр, сәгать төзәтүче, Лысьва металлургия заводында токарь булып эшли. 1919–1922 елларда Улан-Удэ каласында качак татар балалары өчен ачылган мәктәптә укыта. Бер ел Лысьва шәһәрендә яшәгәч, 1924–1928 елларда Казанның Н.Нариманов исемендәге мәктәбендә мөгаллимлек хезмәтен дәвам иттерә. Кавказ һәм Урта Азия якларында җәяүле сәяхәттә була. 1930–1934 елларда Татарстан радиокомитетында әдәби һәм музыкаль тапшырулар мөхәррире, аннары 1937 елга кадәр «Совет әдәбияты» (хәзер «Казан утлары») журналында җаваплы сәркатип булып эшли. 1940 елда репрессияләнә һәм 1956 елга кадәр тоткынлыкта була. Аннары Казанга кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яши.

Х.Туфанның халык иҗатына нигезләнгән иҗаты, татар классик поэзиясенең традицияләрен алга таба үстереп һәм киңәйтеп, үзенә бер шигъри дөнья булып формалаша. Ул шигъриятебезне яңа эчтәлек һәм ритмик ачышлар, яңа төр шигырь үрнәкләре белән баета.

**Төп басма китаплары**

* Җырлар, шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1958.
* Юкмыш бабай малае : әкият. Казан : Татар. кит. нәшр., 1966, 2000.
* Сайланма әсәрләр : 2 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1974, 1975.
* Гүзәл гамь : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1990.
* Кайсыгызның кулы җылы?.. : шигырьләр, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2000.
* Әсәрләр : 5 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2007–2010.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1966), ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры (1970, 1980).

## ЮКМЫШ БАБАЙ МАЛАЕ

*(Әкият кыскартып бирелә)*

Бәлкәй атлы малай мин,
Яратам бик борчакны.
Борчак аркасында мин
Дөнья күрдем ничаклы!
Теләсәгез белергә,
Мөмкин сөйләп бирергә.
Борын-борын заманда –
Әти дә тумаганда –
Бабай белән икебез
Борчак чәчкән идек без.
Чәчкән идек уңсын дип,
Берсе унбиш булсын дип,
Түм-түгәрәк, тәп-тәмле
Бәхет булып тусын дип.
Әгәр аңа усаллар
Кул сузмаган булсалар,
Борчак уңачак иде,
Борчакның һәр бөртеге
Торна йомыркасы күк
Эре булачак иде.
Көннәрдән бер көнне без
Бабай белән икебез
Борчакка дип киттек без.
Ай киттек без, көн киттек,
Борчак җиренә җиттек.
Җиребезне күргәч тә,
Бабай елап җибәрде.
Ә минем күзләремә
Бер тамчы яшь килмәде...
Кемдер безнең борчакны

Шылдырган да тайдырган.
Безгә кышка азыкка
Тик саламын калдырган.
Әй бу карак дигәнең
Явыз икән, намуссыз.
Көзләр үтәр, кыш җитәр,
Без нишләрбез азыксыз?..
Әгәр ул менә хәзер
Күзгә күренсә минем,
Ну, мин ул хәерсезнең
Кирәген бирер идем!
Шундый уйлар уйланып
Утырганда моңаеп,
Җирнең аргы ягына
Күзем төште ничектер:
Әрем артыннан миңа
Йодрык күрсәтә кемдер.
Карасам мин яхшылап,
Күзләрне ачыб(ы)рак,
Йодрык дигән нәмәрсәм,
Юк, йодрык түгел кебек:
Сузылып куйды менә
Арлы-бирле бөгелеп,
Бастырык хәтле елан
Күккә сузылган сыман.
Әрем артыннан менә
Күтәрелеп чыкты бу,
Шүрәле бармагы күк
Чиксез озын ботны бу
Эре генә салгалап,
Безгә табан атлады –
Калдык-постык борчакны
Чүпләштерә башлады.

Әйтте бабай:
– Мин аны
Җүнсез бер кеше дисәм,
Безнең борчак карагы
Әнә бит ул кем икән –
Торна икән бит, улым!
Ах сине, урак муен!..
Киңәшеп алдык шунда,
Посып салам артына,
Шушы карак торнаны
Ничек тоту хакында.



Бабай миңа аңлатты
Ничек итү хәйләсен:
– Калдык-постык борчакны, – ди, –
Без дә чүплик, бәбкәчем;
Чүплик тә шыпырт кына, – ди, –
Колмакка салыйк аны,
Колмаклы суга салып
Бүрттереп алыйк аны;
Шулай итеп элгәре
Борчакны без исертик,
Аннары шыпырт кына, – ди, –
Аны без җиргә сибик.
Ачыккан торна шуны
Чүпләп йөрергә килер,
Чүпләп бетерү белән,
Мөгаен, ул исерер!..
Шулай итеп без аны
Эләктерик ботыннан!
Мин колмак җыеп килим
Урманнан, – диде бабай, –
Ә син салам астында
Көтеп тор мине, малай.
Тын да алмыйча гына
Салам астында ятам.
Килә әкренләп торна
Салам янына табан.
Алда ниләр буласын



Мин күп уйлап тормадым:
Эләктердем дә алдым
Бер ботыннан торнаның!
Торна югары табан
Мине сөйрәп йөгерә,
Ә мин, ычкынмасын дип,
Ныграк ябышам тегеңә.
Мине бераз сөйрәгәч,
Җәйде торна канатны:
Аермакчы була ул
Җирдән минем аякны.
Менә торна әкренләп
Һавага күтәрелә.
Минем тәпиләр инде
Куакларга бәрелә...

Шулай итеп, торнаның
Аягына тагылып,
Еракларга-а-а киттем мин
Туган илдән аерылып.

# Шәйхи Маннур

*(1905–1980)*



**Туган көне**

15 нче гыйнвар.

**Туган урыны**

Татарстанның Мамадыш районы Тулбай авылы.

**Тормыш юлы**

Шәйхи (Шәйхелислам) Маннур башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә ала. Аннары Мамадыш шәһәрендәге педагогия курсларын тәмамлый. 1921 елда анын әтисе, ачлыктан качып, гаиләсе белән Кузбасска күчеп китә. Уналты яшьлек Шәйхелисламның хезмәт юлы шунда башлана. 1933 елда Ш.Маннур урау юллар аша Казанга кайта. Казан педагогия институтына укырга керә. Институтны тәмамлагач, бер ел «Совет әдәбияты» (хәзер «Казан утлары») журналы редакциясендә эшли. 1938–1941 елларда әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. 1941 елда фронтка китә һәм сугышның соңгы көннәренә кадәр фронт газеталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Сугыштан соң М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының әдәби бүлек мөдире булып эшли. 1949 елдан профессионал язучылык хезмәтенә күчә.

Үзе исән чагында Ш.Маннурның дүрт дистәгә якын китабы дөнья күрә. Алар арасында балаларга атап язылганнары да байтак («Шаян дусларыма», «Миләүшә китабы», «Каз көтүче малай» һ.б.). Язучы шулай ук әдәби тәнкыйть, публицистика, очерк, тәрҗемә жанрларында да эшли.

**Төп басма китаплары**

* Тайга төбеннән. Казан : Татар. дәүл. нәшр., 1928.
* Шигырьләр. Казан : Татар. дәүл. нәшр., 1939.
* Җир-әнкәнең сылу кызы : шигъри повесть. Казан : Таткнигоиздат, 1956.
* Нәниләргә. Дәүләргә. Казан : Татар. кит. нәшр., 1965.
* Күңел йомгагы : шигырьләр, поэмалар : 2 китапта. Казан : Татар. кит. нәшр., 1968, 1971.
* Муса : роман. Казан : Татар. кит. нәшр., 1975.
* Агымсуларга карап : повесть. Казан : Татар. кит. нәшр., 1974.
* Чын сөю бармы : лирик повесть. Казан : Татар. кит. нәшр., 1980.
* Уткүз : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1986.
* Кояш, чык, чык! : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.

**Яулаган үрләре**

Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе», Халыклар дуслыгы орденнары кавалеры (1939, 1945, 1957, 1975).

---

1982 елда Татарстан Язучылар берлеге һәм Мамадыш районы хакимиятенең Шәйхи Маннур исемендәге премиясе булдырыла.

1995 елдан Татарстанның Мамадыш районы Тулбай авылында Шәйхи Маннур исемендәге музей-китапханә эшли.

## УРМАН ӨЕНДӘ

Урманда бер өй бар иде
Карт наратлар төбендә.
Нәни аю балалары
Тора иде шул өйдә.

Китте Ләлә шул урманга.
Уң кулында төенчек.
Барып җитсә, – каршысында
Кечкенә генә бер өйчек.

Ачты да ул өй ишеген,
Килеп керде эч якка.
Куркышып, нәни аюлар
Постылар бер почмакка.

– Курыкмагыз, – диде Ләлә, –
Менә сезгә бу бүләк.
Дуслашыйк та, без бу өйдә
Өчәү торыйк бергәләп.

Шуннан алар Ләләләрнең
Өенә юнәлделәр.
Бөтен кирәк-яракларны
Өчәү тартып килделәр.

Юындыра дустын Ләлә
Күбекле сабын белән.
– Шапшак булма болай, – ди ул, –
Тәти йөрергә өйрән.





Ачты Ләлә тәрәзәне
Йоклар алдыннан кичен.
Саф һава бик файдалы ул
Нәни балалар өчен.

Иртән аюлар Ләләне
Уяталар: – Тор инде,
Сәгать җиде тулган инде,
Безнең ашыйсы килде.

– Юк, – ди Ләлә, – ашыкмагыз,
Нигә кабаланырга?
Башта ясыйк физзарядка,
Аннан инде табынга!

Калын йомшак сөлге белән
Ышкый ул аркаларын.
Таза булып үсәр өчен
Файдасы бик күп аның.

– Инде чистарт тешләреңне:
Чистарт иртә-кичләрен.
Курыкма син, ныграк ышкы,
Ап-ак булсын тешләрең!

Аннан Ләлә, тарак алып,
Дустының чәчен тарый,
Ә тегесе башын сып(ы)ра,
Көзгедән карый-карый.

Чыкты алар саф һавага,
Уйнадылар туп атып.
Әй кызык ул туп уены!
Ләкин керергә вакыт.

Ләлә чакыра аш ашарга:
– Кулларны юыйк инде.
Китергән ул чишмә суы,
Матур сөлгеләр бирде...

Өй янында ачык табын,
Утыралар икәүләп.
Ашый алар токмач ашын,
Икесе дә бик тәмләп.

Бирде Ләлә дусларына
Алма, чия һәм җиләк.
Корт калмасын җимешләрдә –
Юып ашарга кирәк!

Ял итәләр алар хәзер
Өй янында һавада.
Үсәләр һәм тазаралар,
Ныгаялар һаман да.



# Мирсәй Әмир

*(1907–1980)*



**Туган көне**
6 нчы гыйнвар.
**Туган урыны**
Башкортстанның Мәләвез районы Җиргән авылы.
**Тормыш юлы**

Яшьли ятим калган Мирсәй Әмир башта туганнан туган абыйсы гаиләсендә, аннары балалар йортында һәм Эстәрлетамак интернат-мәктәбендә тәрбияләнә. 1926 елда Казанга килә һәм сәнгать техникумына (хәзер Казан сәнгать училищесы) укырга керә. Шул елда аның «Авыл яшьләре» журналында беренче хикәяләре басыла. Ике елдан ул, әдәбият дөньясына якынрак булу өчен, «Кызыл яшьләр» һәм «Авыл яшьләре» газеталарына эшкә урнаша. 1929 елда аның «Пар күгәрчен» исемле беренче хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Язучының шуннан соңгы хезмәт юлы Татарстан Язучылар берлеге, «Чаян» журналы, Татарстан китап нәшрияты, Татарстан радиосы белән бәйле. 1937 елда М.Әмир Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп сайлана, әмма ике ай да үтми, аны кулга алалар һәм Казандагы Пләтән төрмәсенә озаталар. 1939 елда ул аклана һәм Мәскәүнең М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларда укый.

М.Әмир – иҗтимагый-сәяси тормышта да актив катнашкан язучы.

Аның иҗаты чынбарлык белән бәйләнгән. Колхозлашу чорындагы сыйнфый көрәш, Бөек Ватан сугышы елларында фашист илбасарларына каршы көрәш, тыл батырларына дан җырлау, теләсә нинди авырлыкны җиңә ала торган нык ихтыярлы, рухи яктан бай, оптимист күңелле татар хатын-кызының реалистик образы, табигатькә мөнәсәбәттә кешенең рухи һәм әхлакый йөзен тасвирлау, юмор һәм сатира, балалар дөньясы – язучының төп темалары.

**Төп басма китаплары**
* Агыйдел : озын хикәя. Казан : Татгосиздат, 1934.
* Сайланма әсәрләр. Казан : Таткнигоиздат, 1953.
* Ялантау кешеләре : роман. Казан : Таткнигоиздат, 1954.
* Батыр : кече яшьтәге мәктәп балалары өчен хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1968.
* Саф күңел : роман-дилогия : 2 китапта. Казан : Татар. кит. нәшр., 1976.
* Миңлекамал : пьесалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1978.
* Безнең авыл кешесе : повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2007.

**Яулаган үрләре**
Ленин һәм ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1945), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1974).

## АЛДАКЧЫ БОЗАУ

### I

Матур җәй килде.

Алмагачлар яфрак ярды. Яфрак араларында төймә зурлыгы гына ямь-яшел алмалар бик күп. Чия агачлары яфрак ярды. Яфрак араларында борчак зурлыгы гына ямь-яшел чияләр бик күп. Слива агачлары яфрак ярды. Яфрак араларында солы зурлыгы гына сливалар бик күп.

Ирекләр авылга – дачага чыктылар. Алма, чия, слива бакчалары эченә килделәр. Ирек бакчада йөрде. Бакчада йөреп туйгач, урамга чыкты. Урамда үзе кебек бәләкәй генә бер кызны күрде. Тагын бәләкәй генә бер ала бозау күрде. Бәләкәй генә кыз күрше капка төбендә басып тора. Бәләкәй генә ала бозау Ирекләр капкасы төбендә ятып тора.

Ирек бәләкәй генә кыз янына килде.

– Син кем? – дип сорады.

– Мин – Миләүшә. Ә син кем?

– Мин – Ирек.

Алар әзрәк сөйләшми тордылар. Ирек әйтте:

– Әйдә, урамның теге башын карап кайтыйк.

Миләүшә әйтте:

– Куркам. Адашырбыз.

Ирек әйтте:

– Туп-туры барабыз, туп-туры әйләнеп кайтабыз. Адашмыйбыз.

Миләүшә әйтте:

– Кире кайтканда, үзебезнең өйне танымабыз. Монда өйләр бар да бертөсле.

Ирек урамдагы өйләрне карады. Чынлап та, өйләр бары да бертөсле. Ирек аптырамады:

– Безнең капка төбендә әнә ала бозау ята. Бүтән капка төпләрендә юк. Ала бозауга карап өебезне табарбыз, – диде.

Шулай дигәч, Миләүшә риза булды. Икәүләшеп, урамның теге башын карап кайтырга киттеләр.



## II

Ирек белән Миләүшә урамның теге башын карарга киткәч, кулына чыбык тоткан бер зур малай килеп чыкты. Кулына чыбык тоткан зур малай Ирекләрнең капка төбендә яткан ала бозауны куып алып кайтып китте.

## III

Ирек белән Миләүшә бик күп матур өйләр күрделәр. Бик күп матур бакчалар күрделәр. Урам бетте. Ирек белән Миләүшә кире борылдылар. Килгән юллары белән кайта башладылар. Бик күп өйләрне үттеләр. Бик күп капкаларны үттеләр. Бик күп бакчаларны үттеләр. Өйләр бер-берсенә охшаганнар. Капкалар да бер-берсенә охшаганнар. Бакчалар да бер-берсенә охшаганнар.

Ирек әйтте:

– Менә хәзер ала бозауга җитәрбез. Ала бозау янында безнең өй булыр. Безнең өй янында сезнең өй булыр.

Ә ала бозау очрамый да очрамый. Зур кара сыер очрый. Ала бозау очрамый. Озын сакаллы ак кәҗә очрый. Ала бозау очрамый. Ничек очрасын?! Ала бозауны бит теге, кулына чыбык тоткан зур малай, әллә кайчан ук куып алып кайтып китте инде. Ала бозау күптән абзарда.

## IV

Ирек белән Миләүшә аптырап беттеләр. Үзләрен ата каз талый язды. Бер әби коткарып калды. Үзләрен автомобиль таптап китә язды. Бер бабай коткарып калды.

Алар, бозауны эзләп килә торгач, урамның икенче башына килеп чыктылар. Инде урам да юк. Уң якка борылып китә торган тар тыкрык кына бар. Ирек белән Миләүшә авылның теге башына барганда, андый тыкрык юк иде.

Икесе дә арыдылар. Ачыктылар. Миләүшә елый да башлады. Кояш та баеп бара. Ирекнең дә елыйсы килә. Нишләргә? Адаштылар бит инде.

Әллә ниләр күрергә туры килер иде, бәхетләренә каршы, көтмәгәндә әниләре килеп чыкты. Әниләре дә Ирек белән Миләүшәне эзли-эзли арып беткәннәр.

Әй эләкте дә соң Ирек белән Миләүшәгә әниләреннән. Орыштылар да, үптеләр дә аларны әниләре.

Ирек шунда үзен аклаган булып маташа:

– Безне ала бозау алдады, – ди.

# Ибраһим Гази

*(1907–1971)*



**Туган көне**

4 нче февраль.

**Туган урыны**

Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Карамалы авылы.

**Тормыш юлы**

Ибраһим Гази, яшьли ятим калып, бала чагыннан ук төрле михнәтләр, мохтаҗлыклар күреп үсә. 1919–1924 елларда Тәтеш балалар йортында тәрбияләнә, шунда урта белем ала. 1924–1926 елларда Казандагы Өлкә партия мәктәбендә укый. Башта комсомолның Кукмара волосте комитеты, аннары Мамадыш кантон комитеты сәркатибе, Татарстан өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлегендә мөдир вазифаларын башкара. Шул ук вакытта Казанда чыга торган «Авыл яшьләре» журналында, «Кызыл яшьләр» газетасында мөхәррир була. 1931–1942 еллар арасында Татарстан Язучылар берлегендә эшли, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, «Совет әдәбияты» (хәзер «Казан утлары») журналында җаваплы мөхәррир була. 1943 елдан җиңү көненә кадәр фронтта татар телендә чыга торган «Сталин байрагы», «Кызыл Армия» газеталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә.

И.Газиның беренче әсәрләре – лирик парчалары («Көлмә, Идел!», «Соңгы чаң» һ.б.) матбугатта 1929 елда басылып чыга. Шуннан соң ул хикәяләр һәм кечкенә повестьлар яза башлый. Аларда шул чор эшче яшьләренең хезмәт энтузиазмын, искелеккә, әхлаксызлыкка каршы көрәш картиналарын сурәтли. Бөек Ватан сугышы елларында язылган хикәяләрендә туган ил азатлыгы өчен аяусыз көрәшне, солдатларның фронттагы батырлыкларын тасвирлый. Сугыштан соң, аерым алганда, илленче, алтмышынчы елларда иҗат ителгән повесть һәм романнарында сугыштан соңгы чорның кырыс шартларында кешеләрнең, Татарстан нефтьчеләренең фидакарь хезмәтен яктырта.

Язучының иң зур әсәре – «Онытылмас еллар» трилогиясе – чын тарихи вакыйгаларга нигезләнеп языла һәм шактый гына вакыт аралыгын үз эченә ала.

**Төп басма китаплары**

* Гади кешеләр : роман. Казан : Таткнигоиздат, 1955.
* Онытылмас еллар : 2 китапта. Казан : Татар. кит. нәшр., 1964, 1970–1971.
* Сайланма әсәрләр : 2 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1966–1967.
* Әсәрләр : 3 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1987–1988.
* Алмагачлар чәчәк ата : повестьлар, хикәяләр, әдәби парчалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1989.
* Хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2007.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1969), Хезмәт Кызыл Байрагы, ике мәртәбә «Почёт билгесе» орденнары кавалеры.



## МӘҮЛИЯ НИГӘ КӨЛДЕ?

Мәүлиягә быел унике тулды. Кечкенә чагыннан ук аны «дәү әнисе кызы», «чат дәү әнисе» дип аптыраталар иде. Маңгаена табарак сикергән кара кашлары да, чекерәеп торган кечкенә кара күзләре дә – барысы да дәү әнисенеке. Бер нәрсә булса, үз әнкәсе аңа: «Син минем кызым түгел, дәү әниең кызы, бар дәү әниеңнәргә», – дип яисә: «Алай сүз тыңламасаң, тотармын да дәү әниеңнәргә илтеп бирермен, алар кызы булырсың», – дип, Мәүлияне «куркыта» торган иде.

Тик шулай да бер ягы белән кыз үз әнкәсенә бик охшаган иде. Мәүлиянең әнисе, – карт кеше булмаса да, җыен юк-барга ышанучан кеше. Самовар сызгырса, кунак килә. Мәче битен юса, тагын кунак. Козгын кычкырса, бусы инде бөтенләй харап, берәр төрле бәхетсезлекне көт тә тор.

Борынгылар әйтмешли, алмагачның алмасы бик ерак төшми икән. Мәүлия дә, әнкәсе кебек, җыен чурт-гүргә ышана иде. Шуның аркасында ул быел, яз көне, бер экзаменын бирә алмыйча, көзгә калды.

Болай булды. Май ае иде. Шомырт котырып чәчәк ата иде. Экзамен бирәсе көнне Мәүлия, бусаганы уң аягы белән атлап чыгып, өйалды баскычыннан төште, урамга чыкты. «Әгәр дә хәзер, – дип юрады ул, – күршеләрнең Актырнагы каршыма чабып чыгып, койрыгын өч тапкыр болгаса, экзаменнарны бирә алам». Көн саен кызның каршысына чыга торган Актырнак (Мәүлия аңа гел ипи бирә торган иде) бу юлы да чабып чыкты, койрыгын болгый-болгый, кызның кулыннан икмәкне алды һәм кызны бераз озата барды. «Бирәм икән!» дип сөенде Мәүлия. Ләкин мәктәп каршындагы коега җитәрәк, кызның баш очында, биектә-биектә, козгын кычкырып җибәрде:

– Коңгыйк! Коңгыйк!

Мәүлиянең төсләре үк агарып китте. Козгын инде ул хәерлегә кычкырмый. Бирә алмый икән! Чырае киткән, бик каушаган хәлдә, Мәүлия мәктәпкә килеп җитте. Бик каушаган хәлдә экзаменга керде һәм бирә алмыйча елап килеп чыкты.

Җәй буе укып, әзерләнеп, бүген ул менә тагын экзаменга бара. Муенына галстугын бәйләде. Бусаганы тагын уң аягы белән генә атлап чыгып, өйалды баскычыннан төште. Урамга чыкты. Бу юлы Мәүлия «Казык башына киптерергә элгән чүлмәк күрсәм, экзаменымны бирә алам» дип юрап куйды. Чыгуга, күршеләренең читәнендәге кызыл чүлмәккә күзе төште. Ләкин чүлмәк күрү генә аз булып тоелды, тагын берәр нәрсә юрарга булды.

Мәүлия ерактан ук дәү әниләре капкасыннан бәбкәләрен иярткән каз чыгып килгәнне күрде дә «Әгәр дәү әни, мин узып киткәндә, читән аркылы карап калса, бирә алам» дип юрады.

Болай дип юрауның хәйләсе бар иде. Мәүлиянең дәү әнисе көн саен иртән казларны капкадан чыгарып җибәрә дә үзе, күлгә төшеп баручы каз бәбкәләренә



сокланып, артларыннан беркавым карап тора иде. Тик дәү әнисе көн дә казларны бик иртә чыгара торган иде, ә бүген никтер соңгарак калган.

Мәүлия дәү әниләре турысына җитте. Читәнгә күп итеп керләр эленгән, читән артында кемдер йөри. «Кер сыгып элә икән» дип уйлады Мәүлия. «Дәү әни, исәнме!» дип кычкырып узып китте.

Мәктәпкә бик куанып барып керде. Дәү әнисе читән аркылы карап тормады торуын, тик шулай да читән артында йөри иде бит. Барыбер түгелмени? Экзаменга бер дә курыкмыйча керде, билеттагы сорауларга шатырдатып җавап бирде.

Укытучы Әлфия апасы:

– Менә яхшы! Менә тырышкан! – дип, кызга бишле куеп чыгарды.

Мәүлиянең башы түбәгә тия язды. Кайтышлый, дәү әниләренә керергә, сөенеч алып чыгарга булды.

Капка турысына җиткәч, ишегалдындагы бабасының сукранган тавышын ишетте:

– Мур кырасы хайван! Кер чәйнәмәсәң, беткәнмени сиңа...

– Бабакай! – дип, Мәүлия йөгереп килеп керде. – Бабакай, бишлегә бирдем!

– Бик яхшы булган, кызым, бик яхшы. Менә бозауны ачуланам әле, киптерергә элгән керләрне чәйнәгән.

Бабасы шулай диде дә бакча читәненә кашынып торган бозауга таба кизәнде.

– Мин сине! Кит, ышкынма читәнгә! Аударырсың!

– Дәү әни өйдәме? – дип, Мәүлия өйалды баскычына йөгереп менде.

– Дәү әниең бүген таң белән духтырга киткән иде, раюнга. Биле сызлап тора.

Мәүлия аптырап калды.

– Соң әле иртә белән генә ишегалдында кер сыгып йөри иде ич.


– Юк, кызым, – диде бабасы. – Таңнан юлга чыкты. Менә керне карарга миңа кушып калдырган иде. Карадым... Мин сине! – дип кабатлады ул, читән янында дымлы матур күзләре белән юаш кына карап торган бозауга бармак янап. – Дәү әниең киткәч, өйнең рәте-башы югалды. Чәй дә куеп эчә алганым юк әле.

Мәүлия баягынак читән артында кемнеңдер мыш-мыш килеп азаплануын хәтеренә китерде дә, «Бозауга, дәү әни, исәнме! дип кычкырганмын икән» дип, көлмәс җиреннән көлеп җибәрде һәм, ашыга-ашыга, бабасына самовар куярга тотынды.



# Фатих Кәрим

*(1909–1945)*



**Туган көне**

9 нчы гыйнвар.

**Туган урыны**

Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылы.

**Тормыш юлы**

Фатих Кәрим 1922–1924 елларда Бәләбәй педагогия техникумының әзерлек сыйныфларында укый. Аннары, Казанга килеп, бер ел балалар йортында тәрбияләнә. 1925–1929 елларда Казан җир төзелеше техникумында белем ала. Студент елларында әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый, республика матбугатында аның яшьләр тормышына багышланган мәкаләләре, фельетоннары һәм балалар өчен хикәяләре, шигырьләре басыла. 1928 елда Казанда «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») газетасы чыга башлагач, Ф.Кәримне әлеге басманың редколлегиясе составына кертәләр һәм идарәнең җаваплы сәркатибе итеп билгелиләр. 1929–1931 елларда ул «Крестьян газетасы»нда – әдәби хезмәткәр, «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») һәм «Атака» журналларында җаваплы сәркатип булып эшли. 1931 елда хәрби хезмәткә алына һәм ике ел Идел буе хәрби округының Казанда татар телендә нәшер ителгән «Кызылармияче» газетасында корреспондент булып хезмәт итә. Аннан кайткач, Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты бүлеген җитәкли. Илһамланып иҗат иткән шагыйрь репрессия шаукымына эләгә һәм 1938 елда кулга алына. Дүрт елга якын төрмәдә утыргач, ирекккә чыгарыла, ләкин моның өчен ул «үз теләге белән» фронтка китәргә тиеш була. 1942–1945 елларда Ф.Кәрим фронтның алгы сызыгында сугыша, башта кече офицер, аннары взвод командиры итеп билгеләнә. Шәхси батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. Көнчыгыш Пруссиядәге соңгы сугышларның берсендә һәлак була.

1941–1945 еллар арасында Ф.Кәрим тугыз поэма, ике повесть, бер драма әсәре һәм йөздән артык шигырь иҗат итә. Аның бу әсәрләрендә сугыш чынбарлыгының катлаулы фәлсәфәсе, фашизмга каршы көрәшкә күтәрелгән гади солдатның сугыш кырындагы батырлыгы, эчке кичерешләре, туган халкына, туган җиренә, якыннарына олы мәхәббәте сурәтләнә.

**Төп басма китаплары**

* Яшен яктысы : шигырьләр һәм поэмалар. Казан : Татгосиздат, 1934.
* Мәхәббәт һәм нәфрәт : шигырьләр һәм поэмалар. Казан : Татгосиздат, 1943.
* Сайланма әсәрләр. Казан : Татгосиздат, 1947.
* Әсәрләр : 3 томда. Казан : Таткнигоиздат, 1954.
* Әсәрләр : 3 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1979–1981.
* Гармунчы аю белән җырчы маймыл : әкият. Казан : Татар. кит. нәшр., 1988, 2006, 2010.
* Кыр казы : шигырьләр, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2004.
* Сайланма әсәрләр : 2 томда. Казан : Мәгариф, 2009.

# ГАРМУНЧЫ АЮ БЕЛӘН ҖЫРЧЫ МАЙМЫЛ

*(Әкият кыскартып бирелә)*

Моннан күп еллар элек
Бик еракта, Таулыда
(Таулы дигән авылда),
Бер кеше гомер иткән,
Хәйдәр исемле икән.
Хәйдәрнең аты булган,
Колагы каты булган,
Сызгырсаң, ишетмәгән,
Сыптырсаң, килешмәгән,
Рәттән тугыз мәртәбә
Тибә булган тәртәгә.
Җәй үткән дә, көз җиткән,
Кырда үләннәр кипкән.
Хәйдәр киткән урманга,
Утын кирәк булганга.
Иртән чыгып киткән ул,
Кичкә барып җиткән ул.
Баргач туарган атын,
Салдырмаган камытын.
Ат ачыгып кешнәгән,
Хәйдәр аңа дәшмәгән.
«Түзәр әле», – дигән дә
Бәйләп куйган имәнгә.
Бертын изелеп йоклагач,
Төн буе кискән агач.
Кояш чыгып җиткәндә,
Хәйдәр атын җиккән дә
Күчәр сынар димәгән,
Бар кискәнен төягән.
«Ат бит ул, тартыр ла», – дип,
Кузгалган кайтырга дип.

Ат төн буе ач торгач,
Йөге дә авыр булгач,
Бер атлый да туктый, ди,
Хәйдәр аны тукмый, ди.
Тукмый, ди, егылганчы,
Чыбыркысы тузганчы.
Ат, мескен, хәле беткәч,
Аруы чиккә җиткәч,
Көянтәдәй сыгылган,
Аннан җиргә егылган.
Хәйдәрнең кыйланганын,
Малкайны кыйнаганын
Ак каенда утырган
Саескан күреп торган.
Тузгачтын чыбыркысы,
Хәйдәр, тешләрен кысып,
Сыек чыбык алырга дип,
Тагын атны ярырга дип,
Урман эченә кергән
Һәм коточкыч хәл күргән:
Икәү кочаклашканнар
(Ничектер дуслашканнар)
Маймыл белән Аю, ди.
Аю гармун уйный, ди.
Юл буйлап киләләр, ди,
Буылып көләләр, ди,
Маймыл, бармак шартлатып,
Урманны яңгыратып:
«Их-ма!» – ди икән,
Кычкырып җырлый икән...
Хәйдәрнең төсе киткән,
Теле кабыктай кипкән,
Калтыраган тезләре,
Шардай булган күзләре,

Карамаган атына,
Качкан куак артына.
Озын койрык саескан
Каен төбенә поскан,
Курыккан, имеш, үзе дә,
Яшь аккан, ди, күзеннән.
Маймылның егетлеге:
Булмаса да күзлеге,
Саесканны тиз күргән
Һәм Аюга белдергән.
– Ни кайгысы бар моның? –
Дип, Аю үз гармунын,
Чын гармунчылар сыман,
Култыгына кыстырган.
Саесканга килгәннәр:
– Ник елыйсың? – дигәннәр.
Саескан, яшен сөртеп,
Киткән Хәйдәрне тетеп:
– Рәхимсез ул, таш күңел,
Башкалар алай түгел,
Киләләр утынга дип
Шундый ук бер атлылар,
Килгәч йоклап ятмыйлар,
Ашаталар туйганчы,
Атның күңеле булганчы.
Чама белән төйиләр,
Какмый-сукмый йөриләр.
Маймыл йодрыгын төйгән:
– Ай ул Хәйдәрне! – дигән.
Аю, аңлагач хәлне,
Тузып киткән бермәлне,
Үрә торган йоннары.
Ачуыннан җиңнәрен
Сызганырга уйлаган,

Тик күлмәге булмаган.
Барса куак артына,
Анда Хәйдәр утыра.
– Сүс чыбыркың тузганчы
Синме ул ат кыйнаучы,
Төн буе ач тотучы?
Мин сине шуның өчен... –
Дип, Аю күтәргән кул,
Ләкин шул чакны Маймыл
Аюны тотып кала,
Читкә чакырып ала,



Учын куеп, тын гына
Пышылдый колагына:
– Ни булса шул булган, – ди, –
Калдырыйк бер юлга, – ди.
Аю бертын уйлый да,
Тирән итеп сулый да,
Уйнаклатып киң кашын:
– Риза! – дип селки башын.
Гармуннарын алалар,
Ат янына баралар,
Төрле план коралар,
Торгызмакчы булалар.
...Шулай бик нык тырышкач,
Саескан да булышкач,
Тирлиләр, кызалар, ди,
Атны торгызалар, ди.
Ат ашаган, ял иткән...
Хәйдәр кузгалып киткән.

# Җәвад Тәрҗеманов

*(1920–1995)*



**Туган көне**

8 нче июль.

**Туган урыны**

Казан шәһәре.

**Тормыш юлы**

Җәвад Тәрҗеманов, Яңа бистәдәге татар урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт химия-технология институтының механика факультетына укырга керә. Бөек Ватан сугышы елларында, институтта укуы белән беррәттән, хәрби заводта станоклар көйләүче мастер вазифасын башкара. Аспирантурада укый, 1950 елда диссертация яклый һәм техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Үзе укыган югары уку йортының металлар технологиясе кафедрасында – доцент, институтның «Гыйльми язмалар»ында җаваплы сәркатип һәм мөхәррир булып эшли. Белгечлеге буенча дистәләгән фәнни хезмәт яза.

Җ.Тәрҗеманов мәктәп елларында ук каләм тибрәтә башлый. «Безнең җавап» исемле беренче шигыре 1935 елда «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») газетасында басылып чыга. 1938 елда «Галстук» дигән беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә. Алтмышынчы елларның беренче яртысына кадәр язучының әдәби иҗаты тулысынча балалар әдәбиятына бәйле. Бу чорда ул кыска хикәяләре һәм бигрәк тә әкиятләре («Ябалак һәм Тавык», «Шуктуган», «Көмеш койрык» һ.б.) белән киң танылу ала. Алтмышынчы еллардан башлап өлкәннәр өчен дә яза башлый. Роман, публицистика, әдәби тәнкыйть, мемуар, очерк жанрларында актив эшли.

**Төп басма китаплары**

* Ботканы кем ашаган? : әкият. Казан : Татгосиздат, 1941.
* Сайланма әсәрләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1969.
* Көмеш дага : тарихи роман. Казан : Татар. кит. нәшр., 1971.
* Ачкыч һәм баскыч : сайланма шигырьләр, хикәяләр, пьесалар, мәкаләләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1980.
* Лобачевскийның яшьлеге : докум. роман. Казан : Татар. кит. нәшр., 1986.
* Балачак сабаклары : балалар өчен гыйбрәтле хикәяләр, әкият-пьеса. Казан : Татар. кит. нәшр., 1994.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе (1981).



## КЫШ

Уянып, бүген иртән
Карасам тәрәзәгә,
Ак сакаллы Кыш бабай
Кар алып килгән безгә.

Әйдәгез тауга барыйк,
Чанада шуып калыйк.
Бер тузан юк, саф һава,
Җиргә ап-ак кар ява.

## ЙОМШАК СУ, ЙӨГЕРЕК СУ!

Йомшак су, йөгерек су,
Син мине чиста ю!
Бер тап та калмасын.
Битләрем аллансын.

Авызым елмайсын.
Колагым тыңласын.
Күзләрем күрсеннәр.
Аяклар йөрсеннәр.

Тешләрем тазарсын.
Кулларым агарсын.
Йомшак су, йөгерек су,
Барын да чиста ю!



## ТАБИГАТЬ КИТАБЫ



Әйдәгез урманга
һәм кырга
Табигать китабын
укырга.
Бу китап гаять зур,
гаять бай.
Анда бар:
Җир,
Су,
Күк,
Кояш,
Ай.

## ЯКЫН ДУС

Бар минем дускаем,
Иң якын сердәшем,
Һәр җирдә, һәр эштә
Киңәшчем, иптәшем.

Өйрәтә ул миңа
Бар фәнне, телләрне.
Юк аның белмәгән
Сәнгате, һөнәре.

Күргәнен, белгәнен
Барын да аңлата.
Көлдерә, җырлата,
Уйлата, юата.

Син аны беләмсең?
Кем соң ул? Уйлап тап!
Иң якын дускаем,
Киңәшчем
Ул – китап.

# Гамил Афзал

*(1921–2003)*



**Туган көне**
23 нче май.
**Туган урыны**
Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылы.
**Тормыш юлы**
Гамил Афзалның әтисе 1931 елның җәендә, гаиләсен ияртеп, Магнитогорск шәһәренә төзелешкә китә. Такталачыкта беренче сыйныфны тәмамлаган Гамил башта татар эшче балалары өчен ачылган барак-мәктәптә, аннары Магнитогорскидагы татар мәктәбендә белем ала. Әдәбият белән кызыксына, Г.Тукай, Һ.Такташ шигырьләре тәэсирендә үзе дә каләм тибрәтә башлый. 1937 елда Троицк шәһәрендәге Татар педагогия техникумына укырга керә, ләкин, авырып китү сәбәпле, бер елдан соң аны ташларга мәҗбүр була. 1940–1949 елларда ул Магнитогорск металлургия комбинатының механика цехында эшли. Берничә ел гомуми торакта комендант, «Большевик» промартелендә тегү цехы мөдире вазифаларын башкара. 1954–1964 елларда Башкортстанның Калтасы районы Шәрип һәм Заболотский авылларында яши. 1965 елда Әлмәт шәһәренә күчеп кайта һәм кырык елга якын шунда яшәп иҗат итә.

Г.Афзалның халыкчан юмор, кылыч кебек үткен сатира белән сугарылган, эчтәлеге ягыннан гаҗәеп заманча һәм үзенчәлекле шигырьләре, тирән мәгънәле фәлсәфи лирикасы татар поэзиясендә яңалык булып кабул ителә. Аның иҗатына мәкаль-әйтемнәр, образлы сүзләр, канатлы гыйбарәләр куллану, укучыга тапкыр һәм җор фикер җиткерү хас. Шагыйрьнең образлары тормышчан, сюжетлары көлкеле һәм гыйбрәтле.
**Төп басма китаплары**
* Кышкы озын кичләрдә : хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1975, 1986.
* Айлы кичләр : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1977.
* Шундый-шундый эшләр : юмористик һәм сатирик шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1988.
* Сайланма әсәрләр : лирик һәм юмористик-сатирик шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991.
* Гомер кичүләре : шигырьләр. Казан : Рухият, 2000.
* Сайланма әсәрләр : 3 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2004.
* Рәхмәт! : лирика, юмор, сатира. Казан : Рухият, 2009.
**Яулаган үрләре**
Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1977), «Почёт билгесе» ордены кавалеры (1981), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985), Татарстанның халык шагыйре (1992).



## КАР СУЛАРЫ

Кар сулары ага гөрләшеп,
Дулкын дулкын белән серләшеп,
Ярларына сыймый ташкындай,
Нурлы язны мактап сөйләшеп,
Кар сулары ага гөрләшеп.

Ак күбекләр суда бөтерелә,
Вак дулкыннар уйный, сикерә,
Кыш бабайның соңгы карларын
Алып китеп зәңгәр диңгезгә,
Ак күбекләр суда бөтерелә.



## ТОРНАЛАР КИЛДЕ

Кар сулары аккан чакта,
Тезелешеп җылы яктан
Торналар кайтты безгә,
Канатлар кактылар безгә.

Кычкырдылар: «Торыйк-торыйк,
Сезнең белән дуслар булыйк,
Көзгә чаклы бергә торыйк!
Торыйк-торыйк, торыйк-торыйк!»



## ПЕСНӘК


Буранлы кышта
Нинди илләргә
Очасың, песнәк,
Салкын җилләрдә?

Туңа бит синең
Аякларың да,
Тала бит синең
Канатларың да.

Кунма син, песнәк,
Агач башына,
Мин бодай чәчтем
Тәрәз каршына.







## КӨЗ КӨНЕ

Җилләр исә, яңгыр ява
көз көнендә.
Тыныч, рәхәт моң тоябыз
без күңелдә.
Табигатьнең матурлыгы
төрле-төрле,
Күңелле дә, ямансу да
бу көз көне.


Яфракларын коеп барган
агачларга
Ял итәргә куна күчмә
кош төркеме.
Тезелеп-тезелеп очып китә
торналар да;
Күңелле дә, сагышлы да
бу көз көне.





# Гарәфи Хәсәнов

*(1921–1992)*



**Туган көне**
13 нче июнь.
**Туган урыны**
Казан шәһәре.
**Тормыш юлы**

Гарәфи Хәсәнов Яңа бистәдәге 13 нче номерлы татар урта мәктәбен тәмамлый. Октябрь районының Бикүле авылы мәктәбендә балалар укыта, аннары, Казанга кайтып, производствода станоклар көйләүче булып эшли. 1943–1956 елларда, Себер якларына китеп, балалар йортында һәм интернат-мәктәптә тәрбияче хезмәтен башкара. 1965 елда Казанга күчеп кайта һәм хезмәт эшчәнлеген шунда дәвам итә. 1981 елда лаеклы ялга чыгып, әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Г.Хәсәнов әдәбиятка бик яшьли килә. Унбер яшендә «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») газетасында «Әй күңелле лагерьда» дигән беренче очерк-хикәясе басыла. Унөч яшендә ул, өметле яшь язучы буларак, Татарстан язучыларының I съездында (1934) катнаша һәм анда балалар әдәбияты хакында чыгыш ясый. 1938–1941 елларда иҗат эше белән актив шөгыльләнә. Күмәк җыентыкларда һәм журналларда хикәяләрен («Яр башында болан», «Чуар таракан фаҗигасе», «Тәүфыйклы яшь бүреләр» һ.б.) бастыра.

Аның хикәяләрендә туган як табигате, хайваннар һәм кошлар, үсемлекләр дөньясы һ.б. темалар яктыртыла. Ул әлеге тереклек ияләрен кешеләр турында язган кебек җанландырып-сынландырып сурәтли, аларга сокланулы мөнәсәбәтен белдерә. Г.Хәсәновның әсәрләре табигатьнең моңа кадәр игътибар ителмәгән яңа серләренә, күзгә чалынмый торган гаҗәеп нечкә үзенчәлекләренә төшенергә ярдәм итә, табигатькә мәхәббәт тәрбияли.

**Төп басма китаплары**

* Унике матур : хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1968.
* Җирем-суым : хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1972.
* Чү! Сайрар кошым оя тибә... : туган як табигате турында кечкенә хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1976.
* Кошларым – дусларым : парчалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1979.
* Җир ул уртак йортыбыз : туган як табигате турында хикәяләр һәм повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1981.
* Елның дүрт фасылы : повестьлар, хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991.
* Табигать могҗизалары : хикәяләр. Казан : Мәгариф, 2004.

## АККОШ

Һәр тарафта тынгысыз гөрләвекләр челтери. Инде су читләре боздан арчылган. Ләкин әле яр буйларында, агач, куак төпләрендә ап-ак кар ята. Кичләрен, кояш баер алдыннан, кар өсләре алсу төскә керә. Шул чакны күктә, биектә, алсу күл өстендә, алсу кошлар төркеме пәйда була... Озын зифа муеннары алга сузылган, кыска, көчле аяклары – артка... Киң канатларын гаять салмак селтиләр. Алар, ерак юллар кичеп, тәмам арыганнар, хәлдән тайганнар. Син аларны кызганып куясың, камышлы күлгә төшеп, бераз ял итүләрен телисең. Ләкин алар баш очыннан гына узып китәләр. Хәер, арадан бер пары, иптәшләреннән аерылып, түбәнрәк төшә түгелме соң?.. Әйе, әйе!.. Димәк, бу күл – шушы пар аккошның туган төбәге, Аккош күле! Бу күлгә әнә алар, бары тик алар гына хуҗа. Башкалар шуны белеп китеп баралар икән.

Төшеп җитәрәк, аккошлар муеннарын аска бөктеләр; канатларын җилгә каршы җилпи башладылар; аякларын тырпайтып алга суздылар. Шул рәвешчә саллы гәүдәләренә «тормоз» ясап, су өстенә төшеп утырдылар...

Алсу күл өстендә алсу кошлар йөзә. Күкрәкләре суга шактый тирән кергән, гәүдә-койрык ягы кыйгачланып өскә күтәрелгән, ак муеннары мәһабәт бөгелеп, зур сары томшыклары су көзгесенә үк иелгән.

Менә алар икесе ике якка аерылып китәләр дә, кинәт борылып, бер-берсенә каршы килә башлыйлар. Бераздан, бөтенләй якынлашып, томшыкка-томшык килеп терәләләр, гүя исән-имин туган якларына кайту шатлыгын уртаклашалар, үзләренчә тәбрикләшәләр. Ул да булмый, томшыкларын зәңгәр күккә сузып, көмеш быргы авазлары чыгарып кычкырырга тотыналар. Бу – аларның язгы җыры, бу – аларның туй башлап җибәрү турында аваз салулары...

Син, аларның табигатькә, гүзәллеккә мәдхия җырлауларына сокланып, сак кына күл читенә якынлашасың. Ә алар игътибар да итми. Ләкин ул беренче карашка гына шулай тоела. Әгәр дә син әрсезләнеп китеп бу тирәдә артык буталсаң, еш килеп тавышланып йөрсәң, аккошлардан җилләр исәчәк. Бу күлгә хәтта алдагы елларда да әйләнеп кайтмаячаклар.



Аккош күле! Кайда гына юк андый исемдәге күлләр?! Ләкин хәзер күбесенең исеме бар, җисеме юк. Аларны әрсез бәндәләр биздергән, шуңа күрә аккошлар безнең якларда бик аз калган.

Сез шуны һәрчак исегездә тотыгыз: аккошлар – сак кошлар. Алар тынычлык яраталар, саф һава, көмештәй саф су яраталар.

# Мәхмүт Хөсәен

*(1923–1993)*



**Туган көне**
15 нче апрель.
**Туган урыны**
Казакъстанның Көнбатыш Казакъстан өлкәсе Жаңакала төбәгендәге Урда авылы.
**Тормыш юлы**

Мәхмүт Хөсәен, 1941 елда Кызылъяр шәһәрендәге татар урта мәктәбен тәмамлагач, берникадәр вакыт пионерлар оешмасында тәрбияче, җирле газетада әдәби хезмәткәр, «Экпенды» дигән сәнәгать артелендә мәдәни эшләр җитәкчесе булып эшли. Сугыш башлангач, үз теләге белән фронтка китә. 1947 елда хәрби хезмәттән кайткач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. Озак еллар (1952–1975) Татарстан китап нәшриятында эшли. 1975 елдан гомеренең ахырына кадәр әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Мәктәптә укыган елларында ук каләм тибрәтә башлаган М.Хөсәеннең беренче шигъри җыентыгы («Туган ил өчен») Ленинград хәрби нәшриятында басыла. Шуннан соң әдипнең тезмә һәм чәчмә әсәрләре тупланган кырыкка якын китабы дөнья күрә. Бу бай әдәби мирасның иң кыйммәтле өлешен башлыча кечкенә күләмле лирик парчалар, сонетлар, балалар өчен шигырьләр, юмор-сатира әсәрләре һәм җырлар тәшкил итә. Аның шигырьләренә ике йөздән артык җыр языла. Аерым шигъри әсәрләре украин, үзбәк, литва, таҗик, кыргыз h.б. телләргә тәрҗемә ителә. Шагыйрь үзе дә тәрҗемә эше белән актив шөгыльләнә.

**Төп басма китаплары**
* Туган ил өчен : шигырьләр. Ленинград : Оборона халык комиссариаты хәрби нәшр., 1945.
* Идел таңнары : шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1954.
* Чирәм җирләр сулышы : хикәяләр, очерклар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1960.
* Җир мәрҗәннәре : сонетлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1967.
* Мәхәббәт һәм моң : лирика. Казан : Татар. кит. нәшр., 1983.
* Яшь җәлилчеләр : җырлар (ноталары белән). Казан : Татар. кит. нәшр., 1989.
* Якты моң : лирика. Казан : Татар. кит. нәшр., 1997.

**Яулаган үрләре**
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1983).

## ПИПИЛӘР

«Пи-пи-пи-пи!» –
Ди-ди, ди-ди,
Унбер биби
Әнисенә,
Әтисенә
Тынгы бирми.
Белмим, нишләп
Кигән бишмәт
Актан алар?
Каршы килгән
Яңгыр, җилдән
Сакланалар.
Ак җиңнәрен
Җилпи-җилпи
Җырлый алар;
«Пи-пи!» – ди-ди,
Су һәм ипи
Сорый алар.
Әтиләре
Эре генә
Сүзен әйтә:
– Бак-бак-бак-бак!
Җимне тап, тап
Үзең әйдә.
Әниләре
Сабыр гына
Чайкый башын:
– Кок-кок-кок-кок!
Булмый, юк-юк,
Ялгышасың.
Нәни әле,
Бәби әле



Барсы алар;
Җил-давылга
Ничек каршы
Барсын алар?
– Кок-кок-кок-кок!
Алар тук, тук
Үссен әйдә!
Татлы-тәмле
Чирәмнәрне
Өзсен әйдә!
– Бак-бак-бак-бак! –
Кат-кат, кат-кат
Тырыш ата
Азык эзли,
Баткаклыкка
Бата-бата.
Шып-шып, шып-шып...
Арый томшык
Чукып-казып.
Көтмәгәндә
Килеп чыга
Тере азык!
«Пи-пи-пи-пи!» –
Ди-ди, ди-ди,
Унбер пипи
Әй ашыйлар
Суалчанны
Бии-бии.



Бала: «Пи-пи!»
Ана: «Кок-кок!»
Ата: «Бак-бак!»
Күл буена
Алпан-тилпән
Килә атлап.

Рәхәт суда!
Кайсы шунда
Зур иттереп
Авызын ача,
Кайсы куа,
Кайсы кача,
Кайсы ярга
Якынлаша;
Ата-ана
Бакылдаша,
Ә бәбкәләр
Шапылдаша.



Кызыгыннан
Без көләбез
Шаркылдаша-
Шаркылдаша.
– Матур, тигез,
Тату, – дибез, –
Үсегез сез,
Тиздән үрдәк
Булырсыз бит
Үзегез сез.

– Рәхәт нинди!
Рәхмәт! – ди-ди,
Унбер биби
Әтисенә,
Әнисенә
Канат җилпи:
– Пи-пи!
– Пи-пи!
– Пи-пи!

# Энҗе Мөэминева

*(1924–2009)*



**Туган көне**

18 нче май.

**Туган урыны**

Татарстанның Әлмәт районы Яңа Кәшер авылы.

**Тормыш юлы**

Энҗе Мөэминева, Әлмәт урта мәктәбен тәмамлагач, авыл мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Бер үк вакытта читтән торып Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетына укырга керә. Ике елдан Ташкент педагогия институтының көндезге бүлегенә күчеп, шунда математика белгечлеге буенча югары белем ала. 1948 елда Әлмәт районының Габдрахман авылына кайтып, гомере буе мәктәптә математика укыта.

Энҗе Мөэминева олылар өчен дә, балалар өчен дә иҗат итә. Аның «Ефәк яулыгым» исемле беренче шигырь китабы 1961 елда басылып чыга. Шуннан соң «Әниләргә һәм нәниләргә» (1964), «Шигырьләр» (1966), «Синең өчен язам» (1968), «Үрдәгем үпкәләде» (1969) һ.б. китаплары дөнья күрә. Аның әсәрләрендә хезмәт кешесенең самими уй-хисләре, хыял-омтылышлары сурәтләнә, гаилә кору, бала тәрбияләү, табигатьне саклау, әхлак мәсьәләләре үзәккә алына. Тел-стиль ягыннан караганда, халык иҗаты әсәрләрендәгечә гади тел белән, җиңел аңлаешлы итеп яза.

**Төп басма китаплары**

* Ефәк яулыгым : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1961.
* Бүләгем : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1970.
* Дуслар җыелгач : шигырьләр һәм табышмаклар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1986.
* Безгә килегез : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1992.
* Бим, Чәнчебикә, Чәнчеби һәм башкалар : шигъри хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1997.
* Еллар аша : шигырьләр, поэмалар. Казан : Рухият, 2004.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1994), Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты (2005).

## НИЧЕК ТЫҢЛАТЫЙМ?

Гимнастка апа бит әнә
Тупны ничек уйната!
Аның кебек булдыралмыйм,
Көне буе уйнап та.

Ничек кенә тырышсам да,
Тубым мине тыңламый:
Үз дигәнчә сикерә ул,
Мин дигәнчә уйнамый!

Моңардан да тискәре туп
Башка беркемдә юктыр!
Өйрәтегез әле мине:
Ничек тыңлатыйм тупны?



## УЛ АЛДАН КИЛЕП ҖИТКӘН



Мин туктасам – ул да туктый,
Мин йөгерсәм – йөгерә.
Кояш нигә минем арттан
Һаман ияреп килә?

Минем кунакка барганны
Әллә ул да беләме?
Әллә аның да кунакка
Барасы бик киләме?

Мин автобуска утыргач,
Ул туктап калыр микән?
Әллә автобус артыннан
Йөгереп барыр микән?

Автобустан төшү белән
Караган идем күккә,
Кояш миннән көлеп тора,
Ул алдан килеп җиткән!





## КЫШ БАБАЙ ХАТЫ

Менә шатлык Ләйләгә! –
Төнлә Кыш бабай килгән.
Уятмаган Ләйләне,
Йокласын әле, дигән.

Алып килгән күп итеп
Күчтәнәчләр, бүләкләр.
Хат та калдырып киткән,
Язып матур теләкләр.

«Мин һәр кичтә тәрәзәңнән
Карап үтәрмен, – дигән, –
Турыгызга кардан таулар
Өеп китәрмен», – дигән.

# Сажидә Сөләйманова

*(1926–1980)*



**Туган көне**

3 нче октябрь.

**Туган урыны**

Башкортстанның Яңавыл районы Яңавыл авылы.

**Тормыш юлы**

Сажидә Сөләйманова, Тәтешле урта мәктәбен тәмамлагач, ике ел авылда укытучы булып эшли. 1946–1950 елларда Уфада башкорт педагогика университетының тарих-филология факультетында югары белем ала. Аннары Башкортстанның Әбҗәлил районы һәм Татарстанның Минзәлә шәһәре мәктәпләрендә тарих укыта. 1955 елда Әлмәт шәһәренә күчеп килә һәм нефть техникумында – тарих укытучысы, Әлмәт шәһәр комитетында – лектор һәм шәһәр радиоүзәгендә радиотапшырулар мөхәррире булып эшли. 1973 елдан профессиональ язучылык хезмәтенә күчеп, гомеренең соңгы көннәренә кадәр әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

С.Сөләйманова – нигездә, лирик шагыйрә. Аның шигырьләрендә заман темалары, социаль күренешләр авторның үз шәхси биографиясе, кичерешләре белән тыгыз бәйләнештә бирелəләр. Аларда яшьлекләре сугыш чорына туры килгән буынның катлаулы язмышлары мәгънәле шигъри юллар, тәэсирле сурәт-образлар аша тасвирлана. Шагыйрә тормыш турында әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләрне шигъри образларда чагылдырган үзенчәлекле поэмалар («Җир-су», «Фал китабы», «Мәңгелек ут», «Сузган ике кулым» һ.б.), «Гүзәлия җыры», «Күңелем язлар көтә», «Саубуллашу вальсы» кебек популяр җыр текстлары авторы буларак та танылу ала. Ул зурлар өчен дә, балалар өчен дә бердәй яратып иҗат итә.

**Төп басма китаплары**

* Кыр казлары : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1963.
* Кем уяткан Ләйләне : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1964.
* Мәхәббәт сынавы : хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1975.
* Гөлбадран : повесть. Казан : Татар. кит. нәшр., 1980.
* Бер сәяхәт хакында хикәят : повесть, хикәяләр, очерклар, мәкаләләр, юлъязмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1996.
* Тормыш, исәнме! : шигырьләр, поэмалар. Казан : Рухият, 1998.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1980).

## КЕМ УЯТКАН ЛӘЙЛӘНЕ?

Иртүк торып битен юган,
Кем уяткан Ләйләне?
Уятмаган, үзе торган –
Бүген әни бәйрәме.

Пәрдәләрне ачып куйды,
Көн кояшлы, әй, ямьле!
Якты булсын, балкып торсын –
Бүген әни бәйрәме.

Өстәл өстен кат-кат сөртте,
Җәйде ап-ак җәймәне.
Чиста булсын, пөхтә булсын –
Бүген әни бәйрәме.

Күмәкләшеп без дә, дуслар,
Җырлап алыйк, әйдәле:
– Котлы булсын!
Гөрләп торсын
Әниләрнең бәйрәме!



## ЧӘЧӘКЛӘР ЯСЫЙМ

Бик чиста безнең Фоат,
Кулларын үзе юа.
Ашаганда, түшенә
Кулъяулык элеп куя.

– Карагыз әле монда,
Мин ничек ашыймын, – ди, –
Ашыймын да савытта
Чәчәкләр ясыймын, – ди.

Алдына куйган ашын
Ашый бит ул бетереп.
Тәлинкә төбендәге
Чәчәкләргә җиткереп.



## ҖИДЕ

Әллә бүген бәйрәмме,
Бар да котлый Әнвәрне.
Аның бит туган көне,
Җиде яшь тулган көне.

Кечесе дә олысы
Әнвәрнең кулын кысты.
Җиде портфель китерде
Әнвәрнең җиде дусты.

Тагын өчне өстәсәң,
Унга да тулыр иде.
Ун класска кадәрле
Җитәрлек булыр иде.



# Әхсән Баян

*(1927)*



**Туган көне**
8 нче декабрь.
**Туган урыны**
Башкортстанның Илеш районы Әшмән авылы.
**Тормыш юлы**

Әхсән Баян, күрше Ишкар авылы мәктәбендә җиде ел укыганнан соң, берничә ел күмәк хуҗалыкта эшли. 1947–1950 елларда район үзәге Югары Яркәй Мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе була, бер үк вакытта урта мәктәпне дә тәмамлый. 1951–1956 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. 1956–1962 елларда «Социалистик Татарстан» (хәзер «Ватаным Татарстан») газетасында хәбәрче, әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, 1962–1981 елларда «Казан утлары» журналында җаваплы сәркатип, баш мөхәррир урынбасары булып эшли.

Ә.Баян – иҗатының башлангыч чорында шигъри әсәрләр белән танылган әдип. Шигырьләре район газетасында 1943 елдан, республика матбугатында 1951 елдан басыла башлый, беренче җыентыгы («Дингез шавы») Татарстан китап нәшриятында 1959 елда дөнья күрә. Аның күпсанлы лирик һәм фәлсәфи-публицистик шигырьләрендә, баллада һәм поэмаларында үзе яшәгән заманның характерлы билгеләре, яшьтәшләренең романтик уй-хисләре, өметләре сәнгатьчә гәүдәләндерелә, һәм алар татар поэзиясе хәзинәсендә лаеклы урын алып торалар. Әдипнең «Яшьлегемне эзлим», «Язмыштан узмыш», «Тавыш – табигать бүләге», «Җәй белән җәй арасы» һ.б. китаплары шул турыда сөйли. Шул ук вакытта Ә.Баян яшь буын укучыларын да даими күз уңында тота. Көндәлек матбугат битләрендә басылып килгән шигырьләре һәм хикәяләре, «Мират», «Яшен исе», «Җил яратучы күркә» кебек әсәрләре аның бу юнәлештәге иҗади эшчәнлеген күрсәтәләр.

**Төп басма китаплары**

* Ут һәм Су : роман. Казан : Татар. кит. нәшр., 1973.
* Ак канатлар : шигырьләр һәм поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1983.
* Сайланма әсәрләр : 2 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1992–1993.
* Урланган ай : повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1997.
* Сайланма әсәрләр : 5 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2002.
* Җил яратучы күркә : нәни хикәяләр. Казан : Мәгариф, 2004.
* Тәкәрлек сагышы : шигырьләр, хикәяләр, публицистик язмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2007.

**Яулаган үрләре**

«Почёт билгесе» ордены кавалеры (1977), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1988), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1999), Татарстанның халык шагыйре (2004).

## БУЛМАГАЧ БУЛМЫЙ

Малай яр буенда балык каптырып утырганда, бераз читтә, куак арасында, әллә нинди чыр-чу ишетелә башлады. Курыккан, шапылдаган, сызгырган, сызланган һәм бүтән төр тавышлар...

Малай кармакларын тиз генә судан чыгарды да тавыш килгән якка ташланды. Анда, камыш арасында... кошлар сугыша икән. Вак кына камыш чыпчыклары олы бер кошның тетмәсен тетәләр. Кыйналучы кош авызын ачып күккә карап тик ята. Усаллашкан чыпчыкларны малай куып җибәрде. Һәм ни күзе белән күрсен, кыйналучы – кәккүк! Бөтен нәрсә шунда ук аңлашылды. Кәккүк камыш чыпчыклары оясына йомырка салырга кергән дә, аны бу нәни кошлар җыйнаулашып куып чыгарганнар, димәк.



Малай кәккүкне дәү әнисенең өенә алып кайткач, фараз расланып та куйды. Озак та үтмәде, кәккүк ишек янындагы почмакка күкәй салды. Шуннан соң малай, аңа иске сыерчык оясын үзгәртеп, йомыркасы-ние белән кәккүкне шул ояга урнаштырды. Бу эшне башкарганда, ул камыш чыпчыкларыннан кыйналганнан соң кәккүк инде акылга утыргандыр, үз оясын саклар, рәтле тормыш белән яши башлар дип өметләнгән иде. Ләкин бик каты ялгышты. Кая ул! Малай агачтан төшеп җиткәнче үк, кәккүгең, үзе салган йомыркаларны да, менә дигән ояны да бар дип белмәстән, пырхылдады да качты. Димәк, тагын каңгырып йөриячәк, тукмак алачак...

– Үзеңдә булмаса, кыйнап кына акылга утыртып булмый инде аны,– диде дәү әни.

## ЭТ ЯНЫНДА ТИЕННӘР

Кошларның үзләренә ят бүтән кош йомыркаларыннан бала чыгаруы беркемне дә гаҗәпләндерми. Ә хайван, җәнлекләр белән андый хәлнең булуы бик ишетелми. Шулай да сирәк булса да очрый икән.

Көтүче абый урманнан бик зәгыйфь тиен балалары табып кайта. Безнең якта тиеннәр инде беткән дәрәҗәдә бит. Бу ике тиен баласы үлсә, алар тагын да кимиячәк. Шуны уйлап, көтүче абый аларны терелтергә тырыша. Имезлектән көчләп диярлек сөт имезә. Имәргә өйрәнгәч, күршеләрнең әле генә балалаган эт оясына кертеп куя! Билгеле, эт, тиен балаларын кабып йотмасын дип, башта бик тә сак күзәтә. Мәгәр әле хәл җыеп өлгермәгән нәни тиеннәрне эт ялап куйгач, тынычланып үз эшенә китә.



Хәзер, авыл урамнарында ана эткә ияреп чапкан көчекләр артыннан сикергәли-сикергәли йөгергән тиен балаларын күргәндә, кешеләр бер дә гаҗәпләнмиләр. Малай да бу гаилә дуслыгына сокланып елмая гына.

## ЗИРӘК КАРГА

Көннәр җәйгә авышкач, күлләвекләр кибеп, тирә-юнь яшеллеккә күмелгәч, кешеләр утарда тәртип урнаштырдылар. Себерделәр, казыдылар, яңа үлән чәчтеләр. Чүп савытларының да тирәлеген чистартып, өсләренә ныклап япкач, кошларга ризык табу тагын такырайды.

Шулай да безнең таныш ала карга җаен китерде: тирәк агачы янындагы утыргычта бер сабый үзе кимереп йөргән сохариен онытып калдырды. Карга шуны, чукый-чукый, җиргә төшерде. Ләкин сохари һич кителми – чукыган саен катылана гына бара кебек иде. Озаграк азапланырга туры килгәнлектән, зирәк карга бәхетенә башкаларның да күзе төште. Җыйналды карга, чыкты шау-шу, китте төрткәләш, тарткалаш.

Безнең зирәк карга мондыйны сөйми. Ул горуранә читкә тайпылды. Читтән генә күзәтергә булды. Карга дуслар бер-берсен чукыса һәм бер-берсен чукыган хәтле үк сохарины шакылдатсалар да, томшык авыртудан битәр һич нәтиҗәгә ирешә алмыйлар иде. Каты ризык һич кимемичә элекке хәлендә кала бирде. Һәм сабыр гына көткән зирәк каргада соңыннан гына өмет чаткысы кабынды. Гаугалашып арыган каргалар томшыклары сызлаганчы интеккәч һәм бернинди уңышка ирешмичә таралышкач, читтәрәк торган карга инде беркемне кызыктыра алмаган сохарины капты да күтәреп тә китте.



Кипми калган күлләвек табып, сохарины шунда салды ул. Тиз арада ук йомшаган икмәк белән рәхәтләнеп көндезге ашын үткәрде. Бүтән каргалар бу вакытта тагын кайдадыр тарткалаша, төрткәләшә, чукыша иде бугай.

# Аяз Гыйләҗев

*(1928–2002)*



**Туган көне**
17 нче гыйнвар.
**Туган урыны**
Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылы.
**Тормыш юлы**
Аяз Гыйләҗевнең бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. 1945 елда Сарман урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул берникадәр вакыт күмәк хуҗалыкта, аннары комсомолның Зәй район комитетында эшли. 1948 елда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Әмма сугыштан соңгы репрессияләр шаукымы студент яшьләрне дә читләтеп үтми. Егерме ике яшьлек егет, «советка каршы коткы таратуда һәм милләтчелектә гаепләнеп», биш елга якын Казакъстан концлагерьларында җәфа чигә. Фәкать Сталин вафатыннан соң гына иреккә чыгарыла һәм өзелгән укуын дәвам итә. Университетны тәмамлагач, А.Гыйләҗев 1957–1961 елларда көндәлек матбугат редакцияләрендә эшли. Аннары Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларны тәмамлый. 1963 елдан профессиональ язучылык хезмәтенә күчә.

А.Гыйләҗевнең иҗаты күпкырлы. Ул үзен бигрәк тә озын хикәя-повесть остасы итеп таныта. Әсәрләрендә гади кешенең шәхес буларак рухи бөеклегенә дан җырлый, торгынлык чорында киң таралыш алган эгоизм, кешелексезлек, ваемсызлык кебек яман сыйфатларны фаш итә, әхлак, гаилә, яшәү мәгънәсе, намус-вөҗдан каршындагы җаваплылык һ.б. темаларны күтәрә. Язучы иҗатында драматургия жанры да зур урынны били. Аның тарафыннан кырыкка якын сәхнә әсәре языла.
**Төп басма китаплары**
* Тәрәзәләр : повесть, хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1967.
* Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят : повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1976.
* Җомга көн, кич белән... : повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1982.
* Яра : роман, повесть. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991.
* Әсәрләр : 4 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1993–1994.
* Йәгез, бер дога! : роман-хатирә. Казан : Татар. кит. нәшр., 1997.
* Сайланма әсәрләр : 5 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2002.
* Алсу, Илдус һәм сандугач : балалар өчен хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.

**Яулаган үрләре**
Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе (1978, 1985), Татарстанның Г.Тукай һәм РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты (1983, 1987), Татарстанның халык язучысы (1993).

## МАТУР

*(Хикәя кыскартып бирелә)*

Искәндәр авырып киткәч, Разыяның әнисе:

– Ишегалдында гына уйна, Искәндәрләргә кереп йөрмә. Терелгәч, бергәләп уйнарсыз, – диде.

Разыя авызын турсайтып урамга чыгып китте. Кыш килгәндә, һавада эре-эре кар бөртекләре бөтерелгәндә ничек инде берүзең генә уйнап булсын?! Аларның күршесендә Галия исемле бер кыз бар барын. Тик Разыя аны өнәп бетерми. Бер нәрсә булды исә, Галия үпкәләргә яисә сугышырга гына тора. Менә бүген дә Разыяның урамга чыгуы булды, Галия:

– Син безнең тауга килмә! – дип кычкырды.

Искәндәр күренмәсме дип, Разыя аларның тәрәзәсе янына барды. Җиң очына кунган бик матур, сырлы-сырлы кар бөртеген күрсәтергә уйлаган иде ул. Әмма суык Искәндәрләр тәрәзәсен кар бөртеге төсле бизәкләр белән каплап ук куйган икән. Разыя кулларын тәрәзәгә сузып караса да, буе җитмәде. Әтисе аны юкка гына «үскән кызым» дип йөри икән. Бер дә үсмәгән. Менә Равил абыйсы үскән, ичмасам. Җәй көне тәрәзәнең иң өстеннән Разыяга чыпчык балалары алып күрсәтте ул. Буе җитмәгән иде, үрмәләп менде. Тукта әле, Разыя да үрмәләп менә алмас микән?

Бик күрәсе килә иде аның Искәндәрне. Чирләгәч нindirәк булды икән? Әбисе авырып яңагын чуар яулык белән бәйләп куйгач, Разыяга бик кызык булган иде. Искәндәр дә шундый кызык микән?

Кечкенә кыз, кулындагы агач көрәген ташлап, почмактагы бүрәнә башларына ябышып, өскә менә башлады. Бүрәнә башларына кар сырылган икән, кулы шуып китеп, әллә ничә мәртәбә җиргә егылды. Күп тырышкач, өскә үрмәли башлады. Түбәнгә караган иде: башы әйләнеп китте. Чытырдатып күзләрен йомды, куллары-аяклары белән стенага ябышты. Төшәргә дә, менәргә дә куркыныч иде. Күз төпләреннән яшь бөртекләре килеп чыкты. Аннары Разыя акрын гына шыңшый башлады. Түзмәде, авызын зур ачып елап җибәрде. Тавышка

әллә каян Галия килеп чыкты. Ул, сыңар аягында сикергәләп, Разыя тирәсендә бөтерелергә кереште.

– Төшә алмый, төшә алмый! Гарьлек, әллә-лә! – дип чәрелдәде ул.

Өйалды ягында Искәндәрнең әбисе күренде. Ул, камырлы кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, Разыя янына йөгерә иде. Аны күргәч, Галия тишек бияләеннән чыгып торган кап-кара бармагы белән сипкелле борынын күтәреп мәзәк ясады һәм урамга чыгып йөгерде.

Әби елауданмы, туңуданмы калтырый башлаган Разыяны җиргә төшереп бастырды.

– Әй балакаем, балакаем! Кая болай менмәкче идең син?

– Тәрәзәгә.

– Нигә?

– Искәндәрне карарга.

– И кызым, кызым! – дип, Разыяның аркасын какты әби. – Озакламас, терелер. Шул чагында керерсең. Ә хәзер бар, кайтып җылын, битләрең туңып беткән.

– Мин туңмадым, – диде Разыя, иреннәрен түгәрәкләндереп.

Шулай да кайтып китәргә туры килде. Кайтса, әнисе яңа гына томаланган мичкә зур калай белән өчпочмаклар салып маташа. Разыя кулларын чәбәкләде:

– Әни, мин икене ашыйм, яме! – дип кычкырды ул.

– Аш-су янына өсне чишенеп керергә кирәк, кызым.

Бераздан, тамак төбен кытыклап, өчпочмакларның исе чыкты.

Разыя әнисен йөдәтеп бетерде:

– Әни, берне генә алып бир инде? – дип сорады ул.

Җөй тегеп утырган әнисе сәгатькә караштырып кына тора иде. Менә ул эссе бөркеп торган мич авызыннан сары майда кетердәп пешкән алсу өсле өчпочмакларны чыгарды.

Берне ашады Разыя, икенчегә тотынган иде, туйды. Чәй дә йотып карады, үтмәде. Ул, чәй тәлинкәсендәге зур гына өчпочмак кисәгенә карап, иреннәрен ялап куйды. Шул вакытта аның башына бер уй килде.

Ул, әнисе күрмәгәндә генә, өчпочмак кисәген өстәлдән бер читкә алып китте. Газета битен ертып алып, аның белән өчпочмакны бик әйбәтләп кенә төрде һәм киенеп урамга чыкты.

Әнисе:

– Озак йөрмә, хәзер әтиең кайта, – дип кычкырып калды.

Разыя Искәндәрне өчпочмак белән сыйларга уйлаган иде. Искәндәрләр ишеге төбенә җиткәч, тукталып калды: тәмле кисәкне Искәндәргә ничек бирергә? Шулай аптырап торганда, аның күзе болдырда уйнап йөргән песи баласы Матурга төште. Разыяның абыйсы, сугышта йөк ташучы этләр булган, дип сөйләгән иде ич. Матур да шундый эшне булдыра ала бит!

Матур тоттырмыйча озак кына интектерде. Тотам гына дигәндә, үзе белән уйныйлар дип белеп, аркасына ятты, аунады һәм чабып китте. Азаплана торгач, Разыя Матурны эләктереп алды. Ул озак уйлап тормады, бияләен тагып куйган җепне өзеп алды да өчпочмакны Матурның муенына бәйләп куйды. Бик саклык белән генә болдырга менде, өйалды ишеген ачты. Як-ягына каранып, Матурның колагына:

– Искәндәрнең үзенә генә бир, берәү дә күрмәсен, – дип пышылдады. Матурны өйалдына кертеп җибәргәч, үзе түбәнгә төште. Агач көрәген табып алып тау өйде, тау башына ике агач утыртып куйды. Кайсы якка борылса да, күзе Искәндәрләрнең өйалды ишегендә булды. Матур күренми дә күренми. Кызыйның түземе бетте. Ул яңадан болдырга менде һәм сакланып кына ишекне ачты. Башта ул берни дә күрмәде. Караңгыга күзеияләшкәч, Разыя иң элек өй ишеген һәм ишек янында тыныч кына өчпочмак ашап утырган Матурны күрде.

Разыя елаган тавышка өйдән Искәндәрнең әбисе килеп чыкты.

– Тагын ни булды, кызым? Ник елыйсың?

– Менә Матур...

– Нәрсә Матур?

– Өчпочмакны ашаган, бөтенесен ашап бетергән, бер почмагын да калдырмаган...

– Нинди өчпочмакны?

Разыя сөйләп биргәч, әби көлеп җибәрде. Разыяның иптәшенә булган якынлыгы аның күңелен нечкәртте. Ул Разыяны, күтәреп алып, өйгә алып керде. Чишендереп өстәл янына утыртты.

– Үзем дә бүген өчпочмак пешергән идем. Искәндәр ашады да йокыга китте, – диде ул. Өстәлгә булары чыгып торган ике өчпочмак китереп куйды. – Үзеңне дә сыйлыйм әле, кызым, аша, – диде.



Разыя ике өчпочмакны ашады да бетерде. Искәндәрнең әбисе пешергән өчпочмаклар тагын да тәмлерәк кебек тоелдылар аңа. Ни өчен икән?

Кече якта Искәндәр йоклый. Тупсада җеп муенса таккан Матур утыра.

– Һе, явыз! – дигән булды әби аңа карап һәм кечкенә тәлинкәгә сөт салып бирде.





# Гөлшат Зәйнашева

*(1928–2005)*

**Туган көне**

13 нче гыйнвар.

**Туган урыны**

Татарстанның Тукай районы Иске Теләнче авылы.

**Тормыш юлы**

Гөлшат Зәйнашеваның бала чагы Минзәлә районының Югары Тәкермән һәм Хуҗамәт авылларында уза. Хуҗамәт җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул Минзәлә педагогия училищесында, 1945–1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Хезмәт юлын Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире буларак башлый. 1952–1963 елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә мөхәррир, 1964–1966 елларда радиокомитетта музыкаль тапшырулар мөхәррире, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубы директоры, 1973–1983 елларда Татарстан китап нәшриятының кадрлар бүлегендә инспектор булып эшли.

Г.Зәйнашеваның беренче иҗат тәҗрибәләре – шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре – илленче еллар ахырларында көндәлек матбугатта һәм «Күңелле сәхнә», «Мәктәп сәхнәсе», «Эстрада» кебек җыентыкларда басылып чыга. 1958 елда «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче китабы дөнья күрә. Язучының әдәби иҗат эшчәнлеге күпкырлы булса да, ул күбрәк җыр жанрына игътибар бирә. Аның халык җыры традицияләре калыбында язылган, мәхәббәт, туган җир, табигать, яшьлек темаларын гәүдәләндергән лирик шигырьләре халыкчан гадилеге, ачык аңлаешлы чагыштыру-бизәкләре, музыкаль аһәңе белән аерылып тора. Шулай ук Г.Зәйнашева драматургия, балалар әдәбияты, әдәби тәрҗемә өлкәсенә дә үз өлешен кертә.

**Төп басма китаплары**

* Җырлап яшик!.. : шигырьләр, җырлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1971.
* Күңелле ял итегез!.. : эстрада әсәрләре. Казан : Татар. кит. нәшр., 1979.
* Илле җыр : җырлар (ноталары белән). Казан : Татар. кит. нәшр., 1988.
* Әбиемне яратам : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1997.
* Сайланма әсәрләр : җырлар, шигырьләр, пьесалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2006.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1988), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1991).



## КОЯШ ГОМЕРЕ*

*(Җырлыйм әнием турында)*

Бер кыз бала җыр чыгарган
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк, диеп,
Өйрәткән энесенә.

К у ш ы м т а:
Кояш, кояш
Мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!

Җырны чишмәләр ишеткән,
Кошлар отып алганнар.
Сандугачлар һәм тургайлар
Матур көйгә салганнар.

К у ш ы м т а.

Кушыл син дә, җырлыйк бергә,
Яңа матур җыр тусын.
Җирдә әниләр кояштай
Озын гомерле булсын.

К у ш ы м т а:
Кояш, кояш
Мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!..

* Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы.

## КОНФЕТ

Түгел борын заманда,
Кичә генә Казанда
Бер танышларга кердем,
Конфет хәтле кыз күрдем.
Ышанмасагыз әгәр,
Барып карагыз мәгәр,
Буе бер конфет кадәр!..
Әллә чын, әллә ялган, –
Бичара үсми калган!..
Кайгыра әниләре,
Кайгыра әбиләре,
Ник кызыбыз үсми, дип,
Бишектән дә төшми, дип,
Бакчага да йөрми, дип,
Сан да саный белми, дип,
Ничек укыр мәктәптә,
Бара да алмас хәтта!
Конфет хәтле, диярләр,
Уч төбендә чөярләр!..
Ник үсмәгән дисезме?
Белергә телисезме?
Көн-төн конфет сорый, ди,
Ә бирмәсәң, елый, ди,
Ашый, ди, бары конфет,
Иртә конфет, кич конфет,
Бер түгел, ун... унбиш...
Егерме биш конфет!..
Бәрәңге һәм ипине
Хәтта авыз итми, ди,
Ашамый, ди, күмәч тә,
Кача икән күргәч тә.



Яратмый, ди, аш һәм ит,
Суыра, ди, гел конфет!..
Эчми, ди, катык һәм сөт,
Сорый, ди: «Конфет!.. Конфет!..
Конфе-е-е-ет!..»

Һаман шулай яшәгәч,
Конфет кына ашагач,
Үсмәгән, гел үсмәгән,
Бишегеннән төшмәгән,
Кечерәя барган, ди,
Конфет хәтле генә булып калган, ди!



# Нәҗип Мадьяров

*(1928–2002)*



**Туган көне**
3 нче март.
**Туган урыны**
Татарстанның Арча районы Кызыл Утар авылы.
**Тормыш юлы**
Нәҗип Мадьяров Кызылъяр авылындагы җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, гади колхозчы, колхоз бухгалтериясендә хисапчы булып эшли. 1950–1953 елларда хәрби хезмәттә була. Аннан кайткач, туган авылында бухгалтерлык эшен дәвам итә. Эшеннән аерылмыйча, ел ярымлык бухгалтерлар курсын һәм Яңа Кенәр урта мәктәбен тәмамлый. 1957–1962 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. Район газеталарында авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире булып эшли, мәктәптә балалар укыта, Лениногорск шәһәренең телевидение студиясендә корреспондент вазифасын башкара. 1965–1980 елларда Балтач район газетасында мөхәррир урынбасары һәм авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире була. 1980 елдан башлап Н.Мадьяров Яр Чаллы шәһәрендә яши, андагы әдәби-мәдәни мохиттә кайный.

Язучының исеме әдәбият мәйданында илленче еллар ахырында күренә башлый. Беренче шигъри җыентыгы («Чык бөртекләре») 1960 елда дөнья күрә. Шуннан соң аның тагын ике дистәдән артык шигырьләр китабы басыла. Н.Мадьяровның лирик шигырьләрендә, юмор-сатира әсәрләрендә шагыйрьнең уй-фикерләре, тыйнак, ләкин эчке мәгънәгә бай самими хисләре, балалар өчен язылган шигырьләрендә исә сабыйларның тапкыр сүзләре, хыялый уйлары, кызыклы чагыштырулары ачык чагыла.
**Төп басма китаплары**
* Җәйге яңгыр : шигырләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1970.
* Рәшәле офыкларым : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1979.
* Көлке төенчеге : юмористик хикәяләр, мәзәкләр, фельетоннар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1985.
* Салават күпере : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1988.
* Әби күзлеген эзли : шигырьләр. Чаллы : КамАЗ, 1997.
* Әкәмәт : балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.
**Яулаган үрләре**
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1991).



## КАПМАДЫ БАЛЫК

Инешкә төштек...
Кармаклар салып
Күпме көтсәк тә,
Капмады балык.

Капмагач нишлик?
Бик кызык иттек –
Җыенып, өйгә
Кайттык та киттек.

Йөрсәк тә ярда
Байтак каңгырып,
Бик күп балыкны
Янга калдырдык.

## КАРА АККОШ

Бабай белән күзәтәбез:
Суда йөзә кара аккош.
Нигә кара булды икән?
Ул барыбер ак кош, пакь кош.

Исе китеп әйтте бабай:
– Бу – табигать кызыгыдыр.
Улым, улым, ул кош, бәлки,
Аккошларның нег(ы)рыдыр.



## БИК ЗУР МӘЧЕ

Зоопаркта Наилә
Шаккатты.
Юлбарысны күреп, телен
Шартлатты:

– Күргәнем юк иде монда
Килгәнче,
Ой, бигрәк тә зур икән ич
Бу мәче.

Тотар өчен моңа тычкан
Сирәктер.
Аңа, бәлки, бик зур тычкан
Кирәктер...

Һәм абыйсына борылып:
– Абый, – ди, –
Гулливерлар асрыймы соң
Аны? – ди.



# Роза Хафизова

*(1929–2005)*



**Туган көне**

6 нчы февраль.

**Туган урыны**

Татарстанның Бөгелмә шәһәре.

**Тормыш юлы**

Роза Хафизова, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1947–1951 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. 1951–1952 елларда Төмән өлкәсенең Тобол шәһәрендәге татар урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1952 елдан, лаеклы ялга чыкканчы, хезмәт юлын журналистлык хезмәте белән бәйли: төрле газета редакцияләрендә эшли, 1962 елдан «Ялкын» журналының баш мөхәррире була.

Р.Хафизова – әдәби иҗатын тулысынча балаларга багышлаган язучы. Аның нәниләр өчен әкиятләре һәм тәрбияви эчтәлектәге хикәяләре тупланган «Кыңгыраулар җыры» исемле беренче китабы 1967 елда басылып чыга. Ул – ике дистәдән артык китап авторы. Аның «Курай-малай маҗаралары» (1969), «Кирлемән» (1970), «Кашкарыйлар озын гомерле» (1975) һ.б. китаплары яшь укучылар арасында тиз арада популярлык казана. Әсәрләрендә язучы, яшь буынга тәрбия бирү мәсьәләләрен үзәккә алып, балалар күңеленә дуслык, гаделлек, намуслылык, тыйнаклык кебек сыйфатларны сеңдерергә, әкияти вакыйгалар, маҗаралар аша явызлыкка каршы көрәшүче, тырыш, ата-анага, өлкәннәргә ихтирамлы балалар образларын тудырырга омтыла.

**Төп басма китаплары**

* Курай-малай маҗаралары : әкият-повесть. Казан : Татар. кит. нәшр., 1969.
* Кирлемән : әкиятләр һәм хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1970.
* Әкиятләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1979.
* Сак-Сок тавышы : хикәяләр, әкиятләр, пьесалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1987.
* Актәпи ник моңая? : әкиятләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991.
* Карурманда ниләр булмас : әкиятләр, әкият-пьесалар. Казан : Мәгариф, 1999.
* Актәпи : әкият-повестьлар, әкият-пьесалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2004.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1974, 1983), Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты (2002).

## АК ӘТӘЧ – ЗАТЛЫ ӘТӘЧ

Яшәгән, ди, булган, ди, бик кыланчык һәм мактанчык бер әтәч. Кыланырлыгы да бар икән, ди, үзенең. Гәүдәсе биниһая зур, канатлары көчле, аяклары тимердәй нык, ди. Башындагы кәләпүше ата үрдәкнеке сыман карасу-яшькелт төстә, елкылдап тора, ди. Карасу-кызгылт канатларының очлары кап-кара, түше аклы-кызыллы, ди. Ә кикриге! Уттай янып торган андый зур кикрикнең гомер булганы юк, ди. Ә йөрүен күрсәгез! Тантаналы маршта барган солдатмыни, аякларын тездән бөкмичә, башын горур тотып, лапы-лопы атлап йөри, ди, бу. Тавышы гайрәтленең гайрәтлесе, ди. Бу төбәк әтәчләре кебек, күңелгә ятышлы итеп, «ки-кри-күк» дип кычкырмый, ди, ул. Киртәгә менеп баса да башта: «Ко-ко-ко», – дип тамак кыра. Аннары: «Как-ри-кук!» – дип, чит телдә кычкыра, ди. (Кайдан өйрәнгән диген?!) Аның тавышын ишеткән бер кеше: «Әтәче дә иясенә охшаган икән. Иясе дә нәсел-нәсәбен, туган телен оныткан маңкорт. Әтәче дә маңкорт икән, мал иясенә охшамый кемгә охшасын соң?!» – дип, эчтән генә тиргәп китә, ди. Иясе, чынлап та, үз телен санламыйча, гел чит телдә генә сөйләшә икән шул.

Ярый, хуш. Көннәрдән бер көнне маңкорт әтәч, ко-ко-колап тамак кырып, койма башына очып кунарга җыенган гына икән, өнсез калган: аның яраткан урынына йолкыш яшь әтәч кунган, имеш. Аның әле тәненә юньләп каурый да чыгып бетмәгән, ди. Үзе бәләкәй: шәрә канатларын җилпеп, ягымлы итеп: «Ки-кри-күк!» – дип кычкырып маташа, ди. Имеш, ко-колама, менә болай, үзебезчә кычкыр. Шулай дигән дә бу, маңкорт әтәч исен җуйган арада, үз ишегалдына сикергән.

Маңкорт әтәч койма башына менеп кат-кат кычкырган. Ишегалдына төшеп гайрәт орган. «Бу ни хәл бу?! Шул өтек нәрсә, койрыксыз әтәч ничек җөрьәт итә алган?! Ник ул минем коймага менгән? Өйрәтеп маташа тагын! Минме? Мин! Мин аны!» – дип озак дулаган ул. Ачуыннан тавыкбикәләрен чукып-чукып алган.

Шул көннән башлап маңкорт әтәчнең тынычлыгы югалган. Ул тавыкбикәләренә тиз-тиз генә җим тибенеп бирә дә үзе койма ягына йөгерә, койма ярыгыннан күрше ишегалдын күзәтә икән. Анда теге яшь әтәч тернәкләнеп килә, инде ак канатлар үскән, тәне ап-ак каурыйлар белән капланган, ди. Башында кып-кызыл кикриге тырпаеп тора, шпораларын ап-ак йон җилпәзәләр бизи. Кыяфәте горур, тавышы көчле. «Ки-кри-күк!» дип кычкырып җибәрсә, бөтен дөньяны яңгырата. Эләктерә алса, маңкорт әтәч аны күптән чукып ташлар иде инде. Булмый: күрше ишегалдына юл юк. Янәшәңдә генә шундый гайрәтле көндәш үсеп килсен әле, дуламас җирдән дуларсың!

Әһә, каптыңмы! Көннәрдән бер көнне, капка ачык калып, урамга чыкса, анда әлеге әтәч берни булмагандай җим тибенеп маташа. Маңкорт әтәч, канатларын борынгы немец рыцарьлары сөңгесе кебек очлайтып, иләмсез акырып, аның өстенә ташланмасынмы! Яшь әтәч тә куркып калмый, дошманын кыю каршылый. Тик көче әзрәк шул әле аның. Нихәтле генә тырышып караса да, җиңелә. Гарьлегеннән шартларга җитешеп, ишегалдына кереп тая. Ә маңкортның кәпрәюенә чик-чама булмый.

Ак әтәч, затлы әтәч ай үсәсен көн үсә, көч җыя. Бик зирәк акыллы әтәч була ул. Беркөнне бил сынашкан малайлардан каратэ алымнарын отып ала.

Әтәчләр, сугышканда, гомер-гомергә бер-берләренә ике канатларын бердәй тырпайтып ташланалар, томшыклары белән чукышалар. Ак әтәч, иртә дими, кич дими, һаман каратэ белән маташа, осталыгын арттыра. Ул бер канатын әз генә өскә күтәрә дә сыңар тәпие белән «дошман»ының башына тондыра. Көннең көнендә шөгыльләнә торгач, аның аяклары тимердәй булып ныгый, канатлары колач җитмәстәй булып үсә, томшыгы пәкедәй үткенләнә. Тәнендә яшь кан кайный, көрәшкә өнди. Ниһаять, каратэ алымнарын тәмам үзләштереп бетергәч, канатлары, аяклары, томшыгы беркем җиңә алмас булып ныгыгач, ак әтәч маңкорт белән очрашырга тәвәккәлли. Бу турыда үзенең бөтен тавыкбикәләренә хәбәр сала. Аннары тагын маңкорт әтәч коймасына сикереп менә дә: «Әй син, туган телеңне оныткан нәрсә, куркак булмасаң, чык мәйданга, мин сине акылга утыртам!» – дип сөрән сала.

Маңкорт әтәчнең күзләре акая, ачуыннан шартларга җитешеп, урамга атыла. Аның артыннан кыткылдый-кыткылдый тавыклар иярә.



Маңкорт белән ак әтәч такыр мәйданда очраша. Мәйдан тирәли һәр ике әтәчнең тавыкбикәләре урнаша. Тамашаны карарга хәтта башка йортлардан да көзге әтәчләр җыйнала.

Маңкорт әтәч үзенең җиңәчәгенә шикләнми дә. Моңа хәтле аның әле беркемгә дә баш биргәне юк! Ак әтәч тә нык тора: дөньяда каратэ алымнарын үзләштергән бердәнбер әтәч ич ул! Маңкорт әтәч, җен ачуларын җыеп, ике канатын берьюлы тырпайтып, кикриген торгызып, томшыгын очлайтып, ак әтәчкә ташлана. Ак әтәч аңа каршы ташланган җиреннән кисәк кенә яны белән борыла да уң канатын әз генә күтәрә төшеп, тимердәй тәпие белән тегенең башына тибеп җибәрә. Маңкорт әтәч, үзенә ни булганын да аңламыйча, артына утыра һәм, ялгышып, тавык кебек кыткылдап куя. И хурланалар моңа аның тавыкбикәләре, и гарьләнәләр! Кыткылдый-кыткылдый аңа көч бирергә тырышалар.

Маңкорт әтәч башын селки-селки исен җыя, кисәк торып, тагын ак әтәчкә ташлана. Ак әтәч бу юлы сул аягы белән аның муен тамырына тибә. Маңкорт әтәч тәгәрәп китә. Озак кына хәл җыя алмый ята. Сикереп торып тагын ак әтәчкә ташлана. Бу юлы ак әтәч уң аягы белән аның тамак астына тондыра. Маңкорт әтәч тәмам түнеп китә. Селкенә дә алмый ята. Ак әтәч, канатларын тырпайтып, бер аягы белән аның өстенә баса һәм, дөньяны яңгыратып: «Ки-кри-күк!» – дип кычкырып җибәрә. Маңкорт әтәч




көч-хәлгә, ава-түнә үз ишегалдына кайтып егыла. Ул тәмам мескен хәлгә төшә: кычкыруын оныта. Иртән кояш чыкканда, кайчакларда ул да таң атуын белдереп кычкырмакчы булып карый, ләкин, ничек кенә тырышса да, «ко-ко-ко»дан гайре аваз чыгара алмый икән.

Һәр таңда ак әтәчнең «Ки-кри-күк!» дигән ягымлы тавышы яңгырый. Тавыкбикәләре аны: «Ак әтәч – затлы әтәч», – дип мактап кына йөртәләр, ди.

# Мөхәммәт Мәһдиев

*(1930–1995)*



**Туган көне**
1 нче декабрь.
**Туган урыны**
Татарстанның Арча районы Гөберчәк авылы.
**Тормыш юлы**

Мөхәммәт Мәһдиев, күрше Сикертән авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1944–1947 елларда Арча педагогия училищесында укый. Арча, Саба районнарында балалар укыта. 1950–1954 елларда хәрби хезмәттә булып кайткач, туган ягында укытучылык эшен дәвам итә, читтән торып Казан дәүләт педагогия институтының тарих бүлеген тәмамлый. 1960–1964 елларда Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы каршында аспирантурада белем ала, кандидатлык диссертациясе яклый. 1990 елга кадәр КДУның татар әдәбияты кафедрасында ассистент, өлкән укытучы, доцент булып эшли.

М.Мәһдиев әдәби иҗат эшчәнлеген әдәбият тарихчысы һәм тәнкыйтьчесе буларак башлый. Татар халкының иҗтимагый фикер үсеше, әдәбият һәм әдәби тәнкыйть тарихы, халык авыз иҗатын фәнни-тарихи яктан өйрәнү мәсьәләләре белән җитди кызыксына, яңа карашлы фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары, гыйльми-тәнкыйди хезмәтләр яза. Прозаик буларак, аның әсәрләре узган гасырның алтмышынчы еллар ахырында күренә башлый. Роман һәм повестьларында ул сугыш алды, сугыш вакыты һәм сугыштан соңгы чордагы авыл тормышын, авыл халкының гореф-гадәтләрен, йола-ышануларын, җир кешесенең катлаулы тормышын сурәтли. Язучының татар прозасында беркемне дә кабатламый торган үз стиле, үз язу манерасы бар: аның әсәрләрендә кырыс реализм, драматизм, лиризм, юмор-сатира үзара аралашып, чиратлашып бара.

**Төп басма китаплары**

* Фронтовиклар : роман. Казан : Татар. кит. нәшр., 1973, 1988.
* Кеше китә – җыры кала : хикәя һәм повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1979.
* Ут чәчәге : роман, повесть. Казан : Татар. кит. нәшр., 1980.
* Мәңгелек яз : роман, повесть. Казан : Татар. кит. нәшр., 1986.
* Бәхилләшү : повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1990.
* Сайланма әсәрләр : 3 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1995–1996.
* Сайланма әсәрләр : 5 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2009.

**Яулаган үрләре**
Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1990), Татарстанның халык язучысы (1993).

## АВЫЛДАН КҮЧТӘНӘЧ

Искәндәрнең авылда апасы бар. Әтисенең апасы. Җәй көне Искәндәр шунда берәр ай ял итә, авыл балалары белән уйный. Авылда чишмәләр бик күп, ул чишмә суының тәме төрлечә, Искәндәр шуларның аермасын сизә.

Ләкин иң күңеллесе ат абзарында. Анысына ул һәр көн йөри. Апасыннан бер-ике кисәк каткан ипи ала да атлар янына килә. Арата арасыннан әни атлар, бала атлар аңа башларын суза. Искәндәр ваклаган ипине уч төбенә куя да аларга бирә. Башта бала атка, аннан әнисенә. Бала атның да, әни атның да иреннәре төкле була. Ипи кисәген әвәләп алганда, ул төкләр Искәндәрнең уч төбен кытыклый – Искәндәр чырык-чырык көлә, ә атлар, пошкырып, аңа рәхмәт әйтәләр.

Ишегалдында ул тавыклар, каз бибиләре белән сөйләшеп утырырга бик ярата, һәр тавыкка исем бирә. Бибиләр дә аны шау-гөр итеп каршылый. Алар Искәндәрнең тәпиенә менәләр, кайберләре алдына ук менмәкче була. Искәндәр аларны алып кочаклый, чирәмдә утырган килеш әле берсе, әле икенчесе белән сөйләшә. Каз бибиен битеңә якын китергәч, үлән исе килеп торган сөяк борыны белән биби аның иренен чукый, колак яфрагын кабып карый. Үзе пуф-пуф килеп сулый. Искәндәр белән уйнаганга бибинең әнисе дә сүз әйтми.

Ә тавыклар, үз яннарында озак тормаганга көнләшеп, бер читтә карап торалар. Алар Искәндәргә үпкәләгәннәр. Тик әтәч кенә элеккечә кычкырынгалап йөри. Аңа барыбер...

Ә аерылышкач, тавыклар үпкәләгәннәрен онытталар, Искәндәргә гел күчтәнәч җибәреп торалар. Төрлесе төрле төстә: сары, кызгылт, шәмәхә. Искәндәр моның ник алай икәнен белә: авылдагы апасы белән бергә алар әллә ничә тапкыр йомырка буядылар. Андый күчтәнәч килгән көнне Искәндәр ишегалдындагы иптәшләрен сыйлый. Бигрәк тә Инессаны. Инессаның авылда әбисе дә, апасы да юк, тавыкларны ул мультфильм буенча гына белә. Менә аның янында Искәндәр мактана инде.

– Бер тавык көненә ничә йомырка сала? – дип сорый ул Инессадан, йөзенә тәрбияче кыяфәте чыгарып.

– Сигез, – ди Инесса, бераз уйлап торгач.

Искәндәр кычкырып көлә. Инесса үпкәли, чөнки ул бакчада дәрес вакытында бөтен сорауларга әйбәт җавап бирә, ә монда сорауга җавап бирә алмый.

– Өчне сала, – ди ул янә, туры китермәмме дип ышанып.



Искәндәр тагын чырык-чырык көлә. Инесса баш вата, үпкәли.

– Берне! – дип кычкыра Искәндәр. – Көне буена берне!

Инесса ышанмый.

– Алайса, ничек кибеттә бик күп йомырка саталар? Дөньяда шул йомырка кадәр тавык буламыни?

– Була! Була! – дип шатлана Искәндәр. – Ә беләсеңме, безнең авылдагы апаның ничә тавыгы бар? Миллион! Юк, ун триллион! Егерме сигез триллион!

...Авылдан килгән буяулы йомырканы алар шулай бәхәсләшә-бәхәсләшә ашыйлар. Бу вакытта Искәндәр үзен тәҗрибәле олы кешеләр сыман тота, чөнки ул белә, ул барысын да күргән. Ә Инесса йомыркаларның буялганын да белми, йомырка нинди булса, тавыгы шундый төстә була дип уйлый...

# Резеда Вәлиева

*(1930)*



**Туган көне**
1 нче май.
**Туган урыны**
Башкортстанның Кыйгы районы Дүшәмбикә авылы.
**Тормыш юлы**


Резеда Вәлиеваның бала чагы һәм мәктәп еллары Башкортстанның Салават районы Насибаш, Лаклы, Михайловка һәм Каратаулы авылларында үтә. Урта мәктәпне тәмамлагач, ул 1947–1952 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. 1952–1986 елларда Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә мөхәррир булып эшли.

Р.Вәлиева – нигездә, балалар язучысы. Аның нәниләр турындагы шигырьләре көндәлек матбугатта илленче елларда дөнья күрә башлый. 1960 елда беренче китабы («Минем дусларым») басыла. Язучының иҗади уңышлары ватандарлык хисләрен чагылдырган поэмаларында, шигъри әкиятләрендә, бигрәк тә кече яшьтәге балалар тормышын, табигать матурлыгын, кош-корт һәм җәнлекләр дөньясын яктырткан лирик һәм юмористик шигырьләрендә ачык чагыла. Бер үк вакытта аның иҗатында мәхәббәт лирикасына, җыр һәм проза жанрларына да зур урын бирелә. Ул – тәрҗемә өлкәсендә эшләгән актив авторларның берсе. Рус балалар әдәбиятыннан ул Н.Верзилин, Н.Попов, Л.Смилянский, Л.Воронкова, А.Барто, С.Михалков кебек язучыларның әсәрләрен татар укучысына ана телендә укырга мөмкинлек тудыра.

**Төп басма китаплары**
* Якты йолдызым : шигырьләр һәм поэма. Казан : Татар. кит. нәшр., 1968.
* Зәңгәр иртә : шигырьләр, әкиятләр, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1980.
* Дәү әнигә барабыз : шигырьләр, әкиятләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1994.
* Зәңгәр алан әкияте. Казан : Раннур, 2000.
* Кояшлы яңгыр : сайланма әсәрләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2003.
* Якты Ярда калган балачак : сайланма әсәрләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.
* Мактанчык Кот-Кот : әкиятләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.
* Сүрелмәс җырым син : шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.
*Яраттым шул, яраттым... : җырлар һәм романслар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2010.

**Яулаган үрләре**
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1999).

## ИШЕГАЛДЫ БОЗЛАВЫК



Ишегалды бозлавык,
Таеп егылды тавык.
Ахры, тавыктан күрмәк,
Таеп егылды үрдәк.
Таеп егылды Гата,
Үкереп елап ята.

– Тукта, – дим, – үкермә син,
Кеше көлә күрмәсен.
Уйлап кара, – дим, – Гата,
Үзеңдә бит соң хата:
Иртәрәк торган булсаң,
Юлга ком сибеп куйсаң,
Булмас иде бозлавык,
Егылмас иде тавык.

Бәлки, тавыктан күрмәк,
Егылмас иде үрдәк.
Син дә егылмас идең,
Елап та тормас идең.
Дөрес түгелме сүзем?
Уйлап карале үзең!



## ШЫМ-ШЫМ БАБАЙ

Әлли-бәлли, бәү итә,
Кем ул тәрәзә чиртә?
Шым-шым бабай: «Керәм, – ди, –
Кем йокламый, беләм, – ди. –
Йокысы килмәгәннәргә
Йокы алып киләм», – ди.

– Йөрмә, бабай, кит инде,
Улым йоклый бит инде.
Әнә күзләрен йомган,
Кулларын сузып куйган.
Кит син, бабай, эндәшмә,
Йоклый улым, сөйләшмә.
Кирәкми инде, кермә,
Төш күрә ул, бүлдермә!

Бәү-бәү итә, бәү итә,
Кем тизрәк йоклап китә,
Шул уңган бала була,
Иртән иртәрәк тора.
Иртә торган балалар
Бәхетле була алар…

## ХЫЯЛЫЙ БАКА

– Бака, бака, бакылдык,
Ник болай кыланасың?
Нигә кабаланасың?
Кая соңга каласың?

– Әнә, әнә тегендә –
Салынкы тал төбендә –
Җәен симереп ята,
Мыекларын уйната.
Шуны тотасы иде,
Кабып йотасы иде!



# Хәкимҗан Халиков

*(1933–2002)*



**Туган көне**

16 нчы гыйнвар.

**Туган урыны**

Татарстанның Әтнә районы Мамыш авылы.

**Тормыш юлы**

Хәкимҗан Халиков, Чембулат җидееллык мәктәбен тәмамлагач, Арча педагогия училищесына укырга керә. Училищедан соң беркадәр вакыт Иске Өҗем мәктәбендә укытучы булып эшли. 1954–1960 елларда читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. 1963 елда Казанга күчеп килә. «Ялкын» журналында, «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») газетасында, Татарстан Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросында, «Идел», «Совет мәктәбе» (хәзер «Мәгариф») журналларында эшли.

Х.Халиковның беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре илленче елларга карый. Шигырьләре башта район газеталарында басыла, алтмышынчы елларда республика үзәк матбугатында да күренә башлый. 1969 елда мәктәпкәчә яшьтәге балаларга атап язылган «Йолдызлар ничәү?» дигән беренче шигырьләр китабы дөнья күрә. Аннан соң бер-бер артлы басылып чыккан китаплары («Шук бабай», «Энәбикә», «Эшләпәле дуслар» һ.б.) белән ул татар балалар әдәбиятында иң актив эшләүче әдипләрнең берсе булып таныла. Мәктәптә, балалар матбугатында озак еллар эшләгән тәҗрибәле педагог буларак, язучы балалар психологиясен яхшы белеп, аларның уй-хисләрен тирәнтен аңлап яза, нәниләр дөньясын төрле яклап яктырта.

**Төп басма китаплары**

* Озын колаклы батыр : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1974.
* Уйныйсың киләме? : сәхнә уеннары. Казан : Татар. кит. нәшр., 1980.
* Канатлы мәче : балалар өчен шигырьләр, әкиятләр, арифметик табышмаклар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1989.
* Сакчы күркә : шаян шигырьләр, тел шомарткычлар, арифметик һәм грамматик табышмаклар, әкиятпьеса. Казан : Татар. кит. нәшр., 1997.
* Сакаллы малай : шигырьләр, әкиятләр, әйтешләр, тел шомарткычлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2002.
* Канатлы куян : әкиятләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984), Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты (1998).



## АЮ БАЛАСЫ

Бал тапса анасы,
Бер аю баласы
Килеп тә утыра,
Ашарга тотына.
Әнисе: – Улым, – ди, –
Ю элек кулың! – ди.
Анның үз киресе:
– Туза, – ди, – тиресе.

## АГАЧЛАР ДА БЕЛӘ

Чыксам әгәр бакчага,
Җимеш суза һәр агач:
Чия суза чияләр,
Алма суза алмагач.

«Ник?» дисәгез, берсен дә
Корткычка тидертмәдем.
Сусаган чакларында
Суга да тилмертмәдем...

Шуңа күрә дә алар
Җимешне мул бирә шул:
Яхшылыкның кадерен
Агачлар да белә шул.
Менә шул!



## ӘКӘМ-ТӨКӘМ

– Әнкәң көткән,
Әткәң көткән,
Көтеп аргач,
Җимгә киткән.

Мин дә инде
Күпме көтәм,
Ник чыкмыйсың,
Әкәм-төкәм?

Күрим инде
Бер үзеңне,
Күрсәт инде
Мөгезеңне!

Аннан соң мин
Шундук китәм...
Шулчак сеңлем
Килеп җиткән.

«Тетә» мине:
– Нигә син, – ди, –
Шул мескенгә
Тиясең? – ди. –

Бәлки, кеше
Йоклыйдыр, – ди, –
Бәлки, шуңа
Чыкмыйдыр, – ди.

– Алай булса,
Китәм, китәм.
Тыныч йокла,
Әкәм-төкәм.



# Әнәс Хәсәнов

*(1935)*



**Туган көне**

23 нче июнь.

**Туган урыны**

Татарстанның Спас районы Көек авылы.

**Тормыш юлы**

Әнәс Хәсәнов 1954 елда Куйбышев (хәзер Болгар) шәһәрендә педагогия училищесын, 1959 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. 1959–1972 елларда Казан телестудиясенең балалар тапшырулары редакциясендә мөхәррир, өлкән мөхәррир, аннары иҗтимагый-сәяси тапшырулар бүлегенең баш мөхәррире хезмәтен башкара. 1972–1974 елларда Ленинградта (хәзер Санкт-Петербург) икееллык Югары партия мәктәбендә укып кайткач, ун елга якын Партия өлкә комитетының мәдәният бүлегендә инструктор булып эшли. 1984–1988 елларда Татарстан китап нәшриятында – баш мөхәррир урынбасары, 1988–1990 елларда «Татарстан коммунисты» (хәзер «Татарстан») журналында – җаваплы сәркатип, 1991 елдан Татарстан Югары Советы секретариатында – өлкән консультант, берничә айдан Татарстан Республикасы Президентының Матбугат үзәге җитәкчесе вазифаларын башкара. 2000 елдан ул – Президент Аппаратының Матбугат архивы мөдире.

Ә.Хәсәнов әдәбиятның төрле өлкәләрендә иҗади сәләтен күрсәтә: шигырьләр һәм проза әсәрләре, балалар өчен хикәяләр, пьесалар яза, әдәби тәрҗемәчелек белән дә шөгыльләнә. Язучы Рафаэль Мостафин белән берлектә алар Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең тормыш юлын, иҗтимагый-дәүләти эшчәнлеген яктырткан күләмле биографик-публицистик китап язалар.

**Төп басма китаплары**

* Җырым – ал җилкән : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2003.
* Кояшлы яңгыр : сәхнә әсәрләре, хикәяләр. Казан : Мәгариф, 2004.
* Минем сандугачларым : поэма, шигырьләр, хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.
* Әнис алмалар = Анисовые яблоки : повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1980), Татарстан журналистларының Х.Ямашев, Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премияләре лауреаты (1996, 2005), Халыклар дуслыгы ордены кавалеры (2001).

## НӘНИ АУЧЫ

*(Хикәя кыскартып бирелә)*

Базар шау-гөр килә. Кая карама – кеше, кеше. Әтиеңнең билбавына тотынып йөрмәсәң, монда адашып калуың да бар. Кем матур итеп, бизәкләп чиккән кәләпүшләр, кем күз явын алырлык күн читекләр, кем прәннек, конфет, клиндер сата. Ул да түгел, борынга балык, тозлы кәбестә, алма, буяу исе килеп керә.

Абдуллага бары да кызык, ул туктаусыз тирә-ягына каранып бара. Кем генә юк икән монда! Буҗак базары бер якта торсын!

Халык, халык. Озын-озын сакаллы, картузлы урыслар, аларның кара юбка кигән, кара шәл ябынган хатыннары, кәләпүшле, фәсле татар бабайлары, тагын әллә кемнәр тыз-быз килә. Кем малын мактый, кем сатулаша, кем каядыр ашыга. Бер урыс бик зур, күкрәк хәтле ак сакалын тарак белән ике куллап тарап утыра. Абдулла аның урыс икәнен белә. Андый сакаллы урыслар, аларның өенә килеп, сабын, бал сатып алганнары бар...

Ул арада әтисе, Абдулланың кулы ычкынуын тоеп, борылып карады. Ә улы кечкенә мылтыклар тезеп куелган кибет ишегенә карап телсез калган иде. Нинди матур, шома түтәле чын мылтыклар! Малай әтисенең:

– Әйдә, улым, кызыл билле прәннек алыйк та кайтыйк. Әниең дә чәй куеп көтә торгандыр. Әйдә, – дигәнен дә ишетми, шаккатып карап тора бирде. «Менә шундый мылтыгым булса, мин дә, аръяк Гарифулла абзый шикелле, Мүклесазга үрдәк атарга барыр идем», – дип уйлады ул.

– Абдулла... Абдулла, дим. Киттекме?

Ә малай, мылтыкка кызыгып карап торуыннан айнып:

– Це-це-це! – дип телен шартлатып куйды. – Әти, әти! Мылтык!

– Һе! Мылтык шул.

– Нәкъ Гарифулла абзыйныкы инде!

– Син аны каян беләсең?

– Ул Мүклесазга үрдәк атарга бара ич.

– Һм... Юк, болар аныкы шикелле түгел. Аныкы чын. Ә болар уенчык мылтык.

– Түтәсе шоп-шома ич!

– Һе-һе-һе! Анысы шома. Тик ядрә белән атмый ул. Бөке белән.

– Үрдәккә тисә, үрдәк егылып төшәме соң?

– Шап итеп. Тисә.

– Әти, әти, дим... Ал әле бер мылтык. Ә?

Абдулланың күзләрендә шулхәтле ялвару иде, әтисе бер аңа, бер тезеп куйган мылтыкларга карап торды-торды да озын мыеклы сатучыга:

– Знакум, давай покажь нам самый хороший ружьё, – дип сүз катты.



Озын мыек чылгыйларын бөтереп күтәртеп куйган урыс белән алар бик озак сатулашып, ниһаять, кап-кара көпшәле, ялтырап торган түтәле, кәкре тәтеле кечкенә мылтык сатып алдылар. Абдулла, аның каеш бавын җилкәсе аша киеп куйгач, нәкъ Гарифулла абзый булды. Ул инде кулын ычкындырып әтисе артыннан түгел, ә янәшәсеннән атлый иде. Алар әле тагын күпме кирәк-ярак сатып алдылар. Абдулла арып артта кала башлады. Моны күргәч, әтисе, көлемсерәп:

– Мылтыклы кеше арырга тиеш түгел, – дип куйды.

Абдулла, терек-терек йөгереп, аны куып җитә, әтисеннән калмаска тырыша иде...

Шулай итеп, Абдулла мылтыклы булды. Аңа мылтык алып биргәнне белгәч, малайлар аны кайткан көнне үк сырып алды:

– Күрсәт әле, малай, ә?

– Ядрәсе дә бармы?

– Атып карадыңмы?

– Бөке белән генә атамыни? Алайса, аның белән каз-үрдәк аулап булмый инде.

Абдулланың моңа кәефе китте:

– Нишләп булмасын?! – диде.

Беркөнне ул, дуслары Салих, Газиз белән Мүксазга барып, кыр үрдәге ауларга ниятләде. Кыяклы түмгәкләр арасында йөзеп йөргән үрдәкне күргәч, Абдулла мылтыгын төзәп маташкан арада, кыр үрдәге пылт итеп суга чумды. Ул арада чыр-чу килгән тәкәрлекләр, малайларның башларына тияр-тимәс очып, аларны өркетә башладылар. Үрдәк тә бүтән күренмәде. Ау уңышсыз чыкты. Аның каравы аучылар бер түмгәк өстендә үрдәк оясы таптылар.

Анда унлап үрдәк йомыркасы бар иде. Малайларның шатлыклары эчләренә сыймады, йомыркаларны, кәләпүшкә салып, өйләренә алып кайттылар.

Абдулла капкадан керүенә әнисенә:

– Әни, әни, менә шушылардан тәбия пешереп бир әле, – дип кычкырды.

Ул арада болдырда әтисе күренде.

Абдулла:

– Әти, менә үрдәк йомыркалары таптык. Өчесе Газиздә, өчесе Салихта да бар әле, – дип, әтисе янына йөгереп килде.

– Әй улым, улым, – диде Габделбари абзый. – Сез тимәсәгез, бу йомыркалардан шундый матур үрдәк бәбкәләре чыгар иде. Ул үрдәк хәзер нишли инде, ә? Булачак бәбкәләрен югалтканга кайгырып үлә бит инде ул. Син аның үлүен телисеңмени?

Абдулла аптырап калды. Чебиләрен саклап йөргән корт-корт тавыкны аның бик күп күргәне бар. Чебиен сыйпарга дип килгәч, ана тавык аның кулын да чукыган иде. Үрдәк тә бәбкәләрен шулай кайгыртадыр бит. Нишләргә соң?

– Әти, әти, мин ул үрдәкне бик җәллим. Әллә йомыркаларны үз урынына илтеп куйыйкмы?

– Менә дөрес итәрсез, улым. Илтегез шул, – диде әтисе.



Абдулла, кәләпүшендәге йомыркаларны саклык белән генә тотып, Салихларга йөгерде. Малайлар йомыркаларны үрдәк оясына илтеп салдылар да, шатланып, өйләренә кайтып киттеләр. Абдулланың әнисе аларны капка төбендә көтеп тора иде. Малайларга ул рәхмәт әйтте дә:

– Беләсезме, бер рәхмәт мең бәладән коткара, – диде. – Менә хәзер сезгә үрдәкләр дә рәхмәт укый инде. Шәфкатьле, миһербанлы егетләр булып үссеннәр дип тә телиләрдер әле.

Абдулла да, Газиз белән Салих та шатланып көлеп куйдылар.



# Клара Булатова

*(1936)*



**Туган көне**

18 нче март.

**Туган урыны**

Татарстанның Сарман районы Татар Карамалысы авылы.

**Тормыш юлы**

Клара Булатова, Сарман урта мәктәбен тәмамлагач, хезмәт юлын укытучылык эше белән башлап җибәрә. 1965–1969 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. Аннары Әлмәт районының Яңа Кәшер урта мәктәбендә тел-әдәбият укытучысы булып эшли. Гомумән, гомеренең кырык елдан артыгын балалар укытуга багышлый.

К.Булатова – дистәдән артык шигъри китап авторы. «Язлар алда» исемле лирик шигырьләр тупланган беренче китабы 1967 елда дөнья күрә. Ул шигырьләрен, нигездә, традицион татар шигыре калыбында яза. Төп темалары – туган җир, заман агышы, кеше язмышы, балалар тормышы һ.б. Шигъри теле халыкчан, чагыштыру-метафораларга бай, ихлас.

**Төп басма китаплары**

* Һәрвакыт янымда : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1969.
* Һәр язның үз җыры : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1978.
* Марс китабы : балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1982.
* Миләш кагы : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991.
* Әрнү : шигырьләр, поэма. Казан : Татар. кит. нәшр., 2003.
* Каурый канат – Җил Атым : шигырьләр, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2006.
* Камилә дигән матур кыз : балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2009.

**Яулаган үрләре**

Россия Мәгариф министрлыгының укытучы-методисты (1978), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1986), Татарстанның Мактау грамотасы иясе (1996).



## ӘЛЛӘ КАЙСЫН ТЫҢЛЫЙСЫ

Әби баса камырын,
Бабай итен тапаша.
Марс инде шул тирәдә,
Булышам дип маташа.

Бабай әйтә: «Һай, рәхмәт,
Яса, улым, яса, – ди, –
Пилмәнебез тәмле булыр,
Үзең ясап аша», – ди.

Әби җәя камырын,
Бабай итен салыша.
Марс та бик ясар иде –
Камыр кулга ябыша.

Әби әйтә: «Улкаем!
Син бәләкәй шул әле,
Пилмәнемне бозасың бит,
Карап кына тор әле».

Әллә эшләп ашасы,
Әллә карап торасы,
Берсе куша,
Берсе тыя,
Әллә кайсын тыңлыйсы.



## БАКЧАДА

Бабайның бакчасы бар,
Бакчада алмасы бар,
Алмагачның алмаларын
Үрелеп аласы бар.

Алмагачның алмаларын
Өзеп кенә алырга,
Тик Марсның буе җитми,
Нинди хәйлә табарга?

Уң кулын да суза ул,
Сул кулын да суза ул,
Аяк очларына басып
Үрелгән дә була ул.

«Үс әле, үс» дигән кебек,
Көлеп тора алмасы,
Рәхәтләнеп өзде Марс,
Күтәргәчтен бабасы.

## ӘНИЕМНЕҢ КЫЗЫ ЮК БИТ...

Әниемнең кызы юк бит,
Мин әнигә бер генә.
Кызы да юк, эш тә бик күп
Әнинең берүзенә.

Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.
Идән юам, җыештырам,
Кер юышам әнигә.

Кибеттән сөт алып кайтам,
Ипигә дә йөгерәм.
Әниемнең кызы юк та,
Малае бар бер дигән.



# Рөстәм Мингалим

*(1937)*



**Туган көне**
15 нче август.
**Туган урыны**
Самара өлкәсенең Келәүле районы Йолдыз авылы.
**Тормыш юлы**

Рөстәм Мингалим, Дәүләткол авылында җидееллык мәктәпне, Татарстанның Бөгелмә шәһәрендә авыл хуҗалыгы училищесын тәмамлаганнан соң, 1962–1967 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. 1977–1980 елларда Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларны һәм Дәүләт театр сәнгате институты каршындагы берьеллык театр курсын тәмамлый. «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») газетасында, Татарстан Язучылар берлеге аппаратында эшли.

Р.Мингалимнең «Әйт, Кояшым!» (1966) дигән беренче шигырьләр китабы балаларга багышлана. «Эзләр» (1967) исемле икенче шигъри җыентыгы зурларга адреслана. Алга таба шагыйрьнең күтәренке рухта, фәлсәфилирик уйланулар белән язылган «Минем дәүләт», «Күз карасы» кебек поэмалары һәм балаларга атап язылган җыентыклары («Галстуклы кәҗә», «Исәнме, әткәй!», «Учыма алган энҗе» һ.б.) дөнья күрә.

Ул проза һәм драматургия жанрларында да актив эшли. Курчак театрлары өчен пьеса-әкиятләр («Урман улы Зурмөгез», «Шүрәлеләр үч алмый» һ.б.), зурлар өчен комедия һәм драмалар («Кайда сез, ирләр?», «Тау астында илле бүре» һ.б.) яза. Әлеге әсәрләр эчтәлекләренең заманчалыгы, җитдилеге, тормышчан, тирән мәгънәле метафораларга бай булуы белән игътибарны җәлеп итә.

**Төп басма китаплары**
* Ә сәгать келт-келт итә : балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1968.
* Төнге әкият. Казан : Татар. кит. нәшр., 1973.
* Шигырьләр һәм поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1987.
* Тау астында илле бүре : пьесалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1990.
* Их, Самара яклары : балалар өчен шигырьләр. Казан : Мәгариф, 1998.
* Дәрт чүлмәге : шигырьләр, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2003.
* Кем кулларына калдырыйм? : шигырьләр, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2007.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1987), Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1997, 2005), Татарстанның халык шагыйре (2010).

## АК КУЯН

Абыем каядыр җыена,
Мине алмаска тели.
– Җылы өйдә тыныч кына
Рәсем ясап утыр, – ди.
– Иярт, абый, ни күрсәм дә,
Кайткач ясыйм, – дип әйттем.
Чаңгы такканымны көтте,
Абый мине ияртте...
Тик ерак бара алмадык.
Бер генә куян күрдек.
Борыным өши башлагач,
Әйләнеп өйгә кердек...
Абыем: – Куян яса! – дип,
Өстәлгә кәгазь куя.
Ничек ясыйм ди инде мин
Ак кәгазьгә ак куян?!



## Ә СӘГАТЬ КЕЛТ-КЕЛТ ИТӘ



Йоклаган сәгать иде,
Сатып алдык кибеттән.
Хәзер тора өстәлдә,
Йокламый ул бик күптән.
Күрсәтә ул вакытны,
Соңгармаска икәнне,
Кунакларга күрсәтә
Китәр вакыт җиткәнне.
Кайтыр чагын әтинең
Сөйләп тора әнигә.
Әйтә ашның пешкәнен,
Кайнаганын чәйнең дә.
Көн уза да, кич була,
Өй эче йоклап китә.
Ә сәгать келт-келт итә,
Ә сәгать келт-келт итә.
Җәй үтә дә, көз була,
Көз уза да, кыш җитә.
Ә сәгать келт-келт итә,
Ә сәгать келт-келт итә.
Кибеттәге шикелле
Йоклар иде бер тагын.
Йоклама, дип, әтием
Көн дә бора колагын.

## ЧИЯ

Агачта еште чия.
Түм-түгәрәк,
Матур чия!
Куе кызыл,
Зур чия!
«Чия булырга теләмим!» –
Диде җилгә шул чия.
«Ни булырсың?» – диде җил.
«Җил булам! – диде чия. –
Куе кызыл җил булып,
Бөтен дөньяга тулып
Йөгерәм!» – диде чия.
«Җил булма син, – диде җил, –
Син куркыныч булырсың,
Малайлар курыкмаслар да,
Кызларны куркытырсың».
«Алайса, болыт булам мин,
Чия булырга теләмим!» –
Диде болытка чия...
«Йолдыз булырга телим!» – дип
Кычкырды йолдызларга.
«Чия булырга теләмим,
Чия булырга теләмим!» –
Дип кычкырды кызыл чия
Күктәге айга шунда.
Шул чия икенче көнне
Юк иде агачында.
Төшеп югалды микән,
Ул йолдыз булды микән?



# Рабит Батулла

*(1938)*



**Туган көне**
26 нчы март.
**Туган урыны**
Татарстанның Зәй районы Түбән Олыҗы авылы.
**Тормыш юлы**

Рабит Батулла, Бишавыл урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Кадер авылы җидееллык мәктәбендә бер ел балалар укыта. 1956–1961 елларда Мәскәүнең М.С.Щепкин исемендәге театр училищесында белем ала. Ике ел Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында артист, 1963–1965 елларда Казан Курчак театрында һәм Казан телевидениесенең балалар тапшырулары бүлегендә режиссёр хезмәтен башкара. Татарстан Мәдәният министрлыгы тәкъдиме белән Мәскәү Театр училищесы каршында оештырылган берьеллык Югары режиссёрлык курсларына укырга китә. Аны тәмамлагач, ун елга якын Казан Курчак театрында, соңрак Мәдәният институтында режиссёр, режиссёр-педагог һәм Курчак театрында баш режиссёр булып эшли. 1977–1979 елларда Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларда белем ала. Аннан кайткач, Казан театр училищесында укыта.

Р.Батулла әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итә. Узган гасырның алтмышынчы-сиксәненче елларында ул балалар өчен хикәяләр һәм маҗаралы әкиятләр, юмор-сатира әсәрләре, театраль миниатюралар һәм пьесалар язса, тора-бара роман, кыйсса жанрында актив эшли. Татарның күренекле шәхесләре белән бәйле кызыклы вакыйгалар, ягъни сөйләкләр туплый, алар турында тарихи, әдәби һәм документаль очерклар яза.

**Төп басма китаплары**
* Пәһлеваннар иле : курчак театры өчен пьесалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1977.
* Серле сандык : маҗаралы әкиятләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1983.
* Кичер мине, әнкәй! : пьесалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1988.
* Сөембикә : роман-кыйсса. Казан : Татар. кит. нәшр., 1992.
* Елантау : әкиятләр, маҗаралы хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.
* Әсәрләр : 3 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2007.
* Сайланма әсәрләр : 5 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985), Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш һәм Г.Исхакый исемендәге премияләре лауреаты (1988, 1991), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2006), Татарстанның халык язучысы (2008).

## ТЫЧКАН БАЛАСЫ ЧИКЫЛ БЕЛӘН АТА МӘЧЕ МЫРЫЙ

Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, үрдәк үрәтник, бака тимерче, чыпчык күмерче булып торган чагында яшәгән, ди, әби белән бабай. Аларның беркемнәре дә булмаган. Көне-төне мич башында йоклап ята торган мәчеләре генә булган аларның. Көне-төне мыр-мыр килеп йоклаганы өчен аңа Мырый дип исем кушканнар.

Идән астында, сайгак башында яши икән бәләкәй тычкан баласы. Көне-төне чикылдаганы өчен әби белән бабай аны Чикыл дип атаганнар.

Әби белән бабай көн саен кәрзин totып базарга йөриләр икән. Ә ата мәче Мырый, йокысы туйган чакларда, берәр балык койрыгы эләкмәсме дип, әби белән бабайга ияреп базарга бара, ди.

Көннәрдән бер көнне базарга бара алмый калган, ди, ата мәче Мырый. Йокысыннан уяна алмаган ул.

Тычкан баласы Чикыл сайгак башындагы тишектән чыккан да, өйдә беркем дә юк дип, рәхәтләнеп бии башлаган. Ул болай дип үзенчә җырлый икән:

Һиннә-нәү, һиннә-нәү,
Һиннер-һиннер, һиннә-нәү!

Шуннан соң ул өстәлгә сикереп менгән дә, ашъяулыкның почмагын күтәреп, ипинең кибән башын кимергән, майны ашаган, сөтне чөмереп бетергән. Тамагы туйгач, идәнгә сикереп төшкән дә тагын җырлый-җырлый бии башлаган.

Һиннә-нәү, һиннә-нәү,
Һиннер-һиннер, һиннә-нәү!

Берзаманны... мич башындагы ата мәче Мырый... тычкан баласы Чикылның тавышына уянып киткән дә, сыңар күзен генә ачып: «Мырр, мияуу, кем мине уятты-ы?» – дип мырылдый икән. Караса, идән уртасында тычкан баласы Чикыл уйнап йөри.

– Әһә, – дип уйлаган ата мәче Мырый, – мин сине күптәннән сагалый идем, мин сине күптәннән тотып ашарга хыялланып йөри идем инде. Кызык итим әле! – дигән дә иплəп кенә мич башыннан төшкән, бабайның ачык авызлы зу-ур катасы белән тычкан баласы Чикылның кереп-чыгып йөри торган бердәнбер тишеген каплап куйган. Каплаган да, әй куып алып киткән ата мәче Мырый тычкан баласы Чикылны. Тычкан баласы Чикыл кая керер тишек тапмыйча



йөгерә икән. Идәннән мич башына, мич башыннан караватка, караваттан идәнгә... Ду китерә икән ата мәче тегене. Куа торгач, артыннан җиткән бит ата мәче тычкан баласының. Очлы тырнаклары белән тычкан баласын эләктерим дигәндә генә, тычкан баласы Чикыл өстәлдәге кефир шешәсенә кергән дә яткан. Мәче алай итә икән, болай итә икән, ялманып йөри икән шешә тирәли. Тәпиен тыгып карый икән шешәгә, тәпие җитми икән тычкан баласына хәтле. Ничек кенә итеп тычкан баласын шешәдән чыгарырга дип баш вата икән ата мәче. Шуннан тапкан бит хәйләсен: бабайның почмакта торган кармагын алып килгән дә, кармакка ипи катысы кигезгән дә, сала икән, янәсе, балык шикелле килеп капмасмы дип уйлый инде мәче. Тычкан баласы да ахмак түгел бит, кармакны чиертеп кенә җибәрә икән дә мәчегә кәҗә тоягы күрсәтеп җырлый икән:

Һиннә-нәү, һиннә-нәү,
Һиннер-һиннер, һиннә-нәү!

Әй ата мәченең ачуы килгән, мин сиңайтим, нишләргә белми икән. Шуннан тагын җаен тапкан бит. Шешәне аударган да тәпие белән әкрен генә өстәл кырыена китергән тәгәрәтеп. Шешә идәнгә төшеп ватылган. Мәче эләктерим дигәндә генә, тычкан баласы пыяла ватыклары арасыннан чыгып чапкан. Тагын киткән куыш. Тычкан баласы кая керер урын тапмыйча йөгерә икән. Аның артыннан ата мәче чаба икән. Идәннән караватка, караваттан мич башына, мич башыннан идәнгә. Зырый-бырый китерә икән ата мәче тычкан баласын. Тотыйм дигәндә генә, тычкан баласы Чикыл бабайның ертык ботинкасы эченә кереп тә киткән, аның артыннан ата мәче кереп, башы белән ботинкага кысылган. Тычкан баласы тиз генә ботинка башындагы тишектән чыккан да ботинка баулары белән мәчене бәйләп куйган. Сыртына менеп атланган да тычкан баласы Чикыл ата мәче Мырыйның, койрыгын тезген итеп тоткан да кармак таягы белән бирепме-бирә икән, ә үзе:

Һиннә-нәү, һиннә-нәү,
Һиннер-һиннер, һиннә-нәү! –

дип чикылдый, ди.

Кирәген биргән-биргән дә тычкан баласы Чикыл ата мәче Мырыйның, үз оясына кереп киткән.



# Гакыйль Сәгыйрев

*(1938–2009)*

**Туган көне**

15 нче февраль.

**Туган урыны**

Татарстанның Нурлат районы Әхмәт авылы.

**Тормыш юлы**

Гакыйль Сәгыйревнең әтисе Ватан сугышында хәбәрсез югала. 1951 елда әнисе, ике баласын ияртеп, үзенең туган якларына – Самара өлкәсенең Кошки районы Иске Фәйзулла авылына күчеп китә. Гакыйль монда җидееллык мәктәпне тәмамлый, рәссам булырга хыяллана. Әмма язмыш җилләре егеткә башка яктан борыла: ул, умыртка сөяген имгәтеп, гомергә йөри алмас хәлдә кала, хәтта куллары да әйбер тотмый. Шулай да егет төшенкелеккә бирелми, китаплар укый, карандаш яисә ручканы тешләренә кыстырып язарга өйрәнә һәм күңеленә килгән уй-фикерләрне кәгазьгә теркәп бара башлый.

Г.Сәгыйревнең беренче шигырьләре 1960 елда район үзәге – Нурлат шәһәрендә нәшер ителә торган «Дуслык» газетасында дөнья күрә. Озакламый республика газета-журналларында да исеме күренә башлый, бер бәйләм шигырьләре «Беренче карлыгачлар» дигән җыентыкка кертелә. 1970 елда Татарстан китап нәшриятында «Тормыш җиле» дигән беренче мөстәкыйль китабы басылып чыга. 1994 елда язучының тагын бер тупланмасы («Кабатланмас моң») укучыларга тәкъдим ителә. Аннары ул җыентык рус һәм татар телләрендә авторның үз рәсемнәре белән нәшер ителә.

**Төп басма китаплары**

* Тормыш җиле : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1970.
* Айбагарлар : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1983.
* Кабатланмас моң : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1994.
* Ике кояш : шигырьләр, хикәяләр. Димитровград : Симбирская книга, 2000.
* Шатлыклы иртә : балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2002.
* Йөрәк сере : шигырьләр, поэмалар, парчалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2006.

**Яулаган үрләре**

Татарстан Язучылар берлегенең Ш.Маннур һәм Г.Исхакый исемендәге премияләре лауреаты (1983, 2001), Халыкара «Филантроп» оешмасы премиясе лауреаты (рәсем сәнгатендәге уңышлары өчен, 1999).

## АКБАЙ

Өйдә ялгыз гына яшәү
Ялыктырды маэмайны.
Апасы, кайткач, урамга
Алып чыкты Акбайны.

Яңа яуган кар өстендә
Сикерде, чапты Акбай.
Малайлар уйлап тапмаган
Кызыклар тапты Акбай.

Кешеләр каршына килеп,
Шатланып өрде Акбай:
– Һау-һау-һау! Әйдә, дус булыйк,
Минем исемем – Акбай!

Кечкенә кыз куркып китте,
Тешләргә килгән диеп.
Белгәч, иркәләде үзен,
Йөнтәс башыннан сөеп.

Акбай кызны бик яратты:
– Сине уйнарга дәшәм,
Син курыкма мин өргәннән –
Мин бит шулай сөйләшәм.



## БЕЗ – ИКӘҮ

Иртән-иртүк без торабыз
Курчагым белән икәү.
Урынны җыештырабыз
Курчагым белән икәү.
Әйбәтләп ашап алабыз
Курчагым белән икәү.
Әнкәйне озатып калабыз
Курчагым белән икәү.

Кунак җыям,
Табынга
Мин салат ясыйм,
Ул ашамый утыра,
Мин чынлап ашыйм.
Баллы сагыз чәйнибез,
Икәү бүлешеп,
Ул чәйнәми – миңа бирә
Үзенең өлешен.

Укытучы-укучы
Булып уйныйбыз.
Ничек кенә укысак та,
Икеле куймыйбыз.

Кызык итеп без уйныйбыз
Курчагым белән икәү.
Көн буе уйнап туймыйбыз
Курчагым белән икәү.
Бернидән дә курыкмыйбыз
Курчагым белән икәү.
Арысак, ятып йоклыйбыз
Курчагым белән икәү.





## БӘЛӘКӘЙ ХӘМИТ

Телевизорда чит телдә
Җырлыйлар моңлы итеп.
Биеп-биеп тә алалар
Күмәкләп, кызык итеп.

Авылларын күрсәтәләр,
Урамнарын, йортларын,
Өйләрендә ниләр барын,
Йорттагы кош-кортларын.

Әни әйтә:
– Кайсы илдә
Яши икән бу халык?
– Безнең илдә түгелдер, – дип
Сүзгә кушылды Хәмит.
– Нишләп безнеке булмасын,
Карадым әллә ничә,
Тыңла әле: әтәчләре
Кычкыра ич безнеңчә!

# Бикә Рәхимова

*(1939)*



**Туган көне**
10 нчы апрель.
**Туган урыны**
Татарстанның Әлки районы Чуваш Кичүе авылы.
**Тормыш юлы**

Бикә Рәхимова (Миңлебикә Фәйзуллина) Түбән Әлки урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. Аннары Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер сәнгать) институтында, «Әлмәтнефть» берләшмәсендә, Казан шәһәре мәктәпләрендә һәм Татарстан китап нәшриятында эшли.

Б.Рәхимова актив әдәби иҗат эшчәнлеген сиксәненче елларда башлап җибәрә: шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр һәм мәкаләләр яза. Аның әсәрләре халкыбызның иҗтимагый тормышы хакындагы фәлсәфи-лирик уйланулары белән тыгыз бәйләнгән. Язучының беренче шигъри җыентыгы («Сәрвиназ») 1986 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрә. Аннан соң милли хәрәкәт дулкыннары тәэсирендә язылган лирик һәм публицистик яңгырашлы тезмә әсәрләре, җырлары тупланган «Ачыл, күңел!» (1989), «Иделләр Казанында» (1999), «Мәрхәмәт» (2005) китаплары басыла. Язучыга балалар дөньясы да яхшы таныш. Ул, нәниләргә атап, шигырьләр, хикәяләр, пьесалар («Кырмыскалар өендә», «Урман радиосы», «Җайдак малай» һ.б.) иҗат итә.

**Төп басма китаплары**
* Сәрвиназ : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1986.
* Ачыл, күңел! : шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.
* Кырмыскалар өендә : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991.
* Урман радиосы : шигырьләр, әкиятләр, маҗаралы пьеса. Казан : Татар. кит. нәшр., 1995.
* Мәрхәмәт : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.
* Җайдак малай : балалар өчен шигырьләр. Казан : Мәгариф, 2007.
* Бакый сагыш : мәкаләләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2009.

**Яулаган үрләре**
Татарстанның Мактау грамотасы иясе (1994), Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты (2009).

## КЫЗЫЛ КАРЛЫГАН

Кызыл карлыган пешкән,
Әйтерсең гел бөрлегән.
Чүбен утап, су сиптем,
Шуңа бик тиз өлгергән.

Сеңлемә матур итеп
Мәрҗән тезешим микән?
Кесәлгә дип җыйганны
Үзем изешим микән?

Берсен өзәм, икесен,
Тәгәри өченчесе.
«Мин күрдем, – ди бер чебеш, –
Үземә сөенчесе!»

Менә җаен да таптым:
Чеби муенына тактым.
Тамгалы булды чеби,
Югалтмас аны әби!



## САНА



Утырдылар сәпиткә.
Утырдылар икәү,
Утырдылар өчәү,
Утырдылар дүртәү,
Аннан булды бишәү,
Аннан булды күбәү!
Сәпит ничек чыдата?
Әлләме алар вата?
Кем шуңа башын вата,
Уйлары булыр хата:
Сәпиттә ике чыпчык,
Аннан булды өч чыпчык,
Аннан булды дүрт чыпчык,
Бишенчесе киткәнче,
Барсы очып беткәнче,
Син аларны санап чык!

## ЧУЛПАНГА БӘЛЛҮ

Әлли-бәлли, бәү итә,
Чулпан йокыга китә.
Чулпан йокыга киткәч,
Әнисе дә ял итә,
Әтисе дә ял итә,
Әбисе дә ял итә,
Бабасы да ял итә.

Әлли-бәлли, бәү итә,
Чулпан йокыга китә.
Чулпан йокыга киткәч,
Сары песи ял итә,
Чыпчыклар да ял итә,
Сандугач та ял итә,
Карлыгач та ял итә.

Әлли-бәлли, бәү итә,
Чулпан йокыга китә...



# Гәрәй Рәхим

*(1941)*



**Туган көне**
15 нче июль.
**Туган урыны**
Татарстанның Лениногорск районы Федотовка авылы.
**Тормыш юлы**

Гәрәй Рәхим (Григорий Родионов) Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Хезмәт юлын «Татарстан яшьләре» газетасында башлый. Аннары Татарстан китап нәшриятында, Татарстан Язучылар берлегендә, «Казан утлары» журналында эшли. 1979–1981 елларда Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларда укый. Бер үк вакытта РСФСР Язучылар берлеге идарәсендә әдәби консультант, Урал һәм Идел буе төрки әдәбиятлар комиссиясенең җаваплы сәркатибе, РСФСР милли әдәбиятлар эше буенча баш консультант вазифаларын башкара. 1992 елдан ул – Татарстан Дәүләт Советында референт һәм баш референт, мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр бүлеге мөдире хезмәтләрендә. Хәзерге көндә – Татарстан язучыларының әдәби фонд рәисе, Россия әдәби фонды Ревизия комиссиясе һәм Халыкара ПЕН-клубның татар ПЕН-үзәге идарәсе әгъзасы.

Г.Рәхим – өч дистәгә якын китап авторы. Ул – поэзиядә дә, проза, драматургия жанрларында да, балалар әдәбияты өлкәсендә дә актив иҗат итүче әдип. Аның әсәрләренә хис-кичереш белән фәлсәфи фикернең үрелеп баруы, ихласлык, нечкә юмор, халык авыз иҗатындагы сүз-бизәкләрдән оста файдалана белү хас. Шулай ук Гәрәй Рәхим – «Татар балалар поэзиясе антологиясе»н төзүдә катнашучы, «Татар поэзиясе антологиясе»нең төзүчесе, Мәскәүнең «Советская энциклопедия» нәшриятында басылган «Литературный энциклопедический словарь»ның татар-башкорт әдәбияты өлешләренең һәм «Борынгы Болгарны сагыну» дигән киноэпопеяның сценарие авторы.

**Төп басма китаплары**

* Чәчәк сатучы малай : хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1968.
* Шатлык елы : мәктәп сәхнәләре өчен пьесалар, скетчлар, парчалар, хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1972.
* Көннәр язга авышкач : повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1979.
* Татлы сагышларым : повестьлар, хикәяләр, публицистика. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991.
* Иске самавыр торбасы : хыялый хикәя. Казан : Мәгариф, 2000.
* Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2001, 2003.

**Яулаган үрләре**
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1980), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1984), Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (2007).

## МИН ЯСАГАН КАР БАБАЙ

Мин ясаган Кар бабайга
Бөтен урам сөенә,
Чөнки ул чын кеше кебек
Сөйләшә, җырлый белә.
Йә кинәт көлеп җибәрә,
Скрипка сыздыра,
Йә ул сандугач шикелле
Чут-чут дип сайрап тора.

Матур итеп шигырь укый,
Мәзәк сөйләп көлдерә,
Хәтта һава торышын да
Бер көн алдан белдерә.
Бу Кар бабайны ясавы
Кыен булмады һич тә,
Нәни транзисторымны
Куеп калдырдым эчкә.



## БЕЗНЕҢ ТАУДА

Кем чанасы шәп җилдерә,
Кем шуарга остарак;
Кем курыкмый биеклектән,
Ә кем йөри астарак;
Кемнәр кышны яраталар,
Кемнәр курка суыктан;
Кемнәр карны билдән ера,
Ә кем йөри тубыктан;
Кем егылмый бер тапкыр да,
Кем ята гел мәтәлеп;
Кемнең авызы өшегән,
Кемнеке тора көлеп;
Кемнәр уңган, кем булдыклы,
Кем түзем, шат күңелле;
Кемдер елак, түземсез һәм
Артык куркак түгелме?! –
Монда бар да ачыклана,
Монда бар да беленә;
Иренмичә, чанаң тартып,
Безнең тауга кил генә.



## ЯФРАКТАГЫ НОТА

Укытучы апа безгә
Ноталар бүлеп бирде.
– Бүгенге җырның исеме –
«Көзне озату», – диде.
Ә мин бер яфрак алдым да
Шуңа карап җырладым.
Бер тамчы да ялгышмадым
Һәм артка да калмадым.
Чөнки бит көз, безнең яктан
Китеп барган чагында,
Зур-зур сары яфракларга
Көен язып калдырган.



# Равил Фәйзуллин

*(1943)*



**Туган көне**

4 нче август.

**Туган урыны**

Татарстанның Балык Бистәсе районы Балтач авылы.

**Тормыш юлы**

Равил Фәйзуллин, Котлы Бөкәш урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында югары белем ала. Студент елларында ук «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй»), «Ялкын» һ.б. газета-журнал редакцияләрендә эшли. 1965–1966 елларда «Совет әдәбияты» (хәзер «Казан утлары») журналында бүлек мөдире вазифасын башкара. 1966 елда бер елга хәрби хезмәткә алына. Аннан кайткач, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршында аспирантурада укый. 1968–1972 елларда Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт оешмасын җитәкли. 1973–1977 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе булып эшли. Аннары унике ел буе профессионал язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. 1989 елдан бүгенге көнгә кадәр «Казан утлары» журналының баш мөхәррире вазифасын башкара. 1990–1995 елларда Татарстан Югары Советы депутаты була.

Р.Фәйзуллинның шигърияте узган гасырның алтмышынчы елларында – фәнни-техник революция чорында формалашкан буынның дөньяга карашын, тормышка мөнәсәбәтен, рухи һәм әхлакый эзләнүләрен нечкә тоем, тирән уй, фәлсәфи фикер аркылы яңача, заманча чагылдыруы белән үзенчәлекле. Шигырьләрендә кыскалыкка, аз сүзлелеккә омтыла. Ул әдәбият, сәнгать, иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә, сәясәткә багышланган әдәби-публицистик мәкаләләр, эссе-уйланулар, новелла-парчалар, әдәби портретлар, юлъязмалар авторы буларак та киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш.

**Төп басма китаплары**

* Наз : лирик шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1973.
* Шигырьләр һәм поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1976.
* Кошлар юлы : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1981.
* Сайланма әсәрләр : 5 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 1992–2001.
* Мәхәббәтнамә : мәхәббәт шигырьләре. Казан : Татар. кит. нәшр., 2003.
* Газиз китабы : балалар өчен шигырьләр. Казан : Мәгариф, 2005.
* Сайланма әсәрләр : 6 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның М.Җәлил исемендәге Республика премиясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1970, 1978), РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985), Татарстанның халык шагыйре (1999), Халыклар дуслыгы ордены кавалеры (2006), Татарстан Фәннәр академиясенең мактаулы академигы (2007).

## ТАБИГАТЬ КОЧАГЫНДА

Гөл-чәчәкләр өзмәдек без,
Куаклар сындырмадык.
Яшел урман аланында
Уйнадык та җырладык!

Кояшка карап елмайдык,
Җилләргә сәлам әйттек,
Һәркем өйгә алып кайтты
Бер кочак сәламәтлек!




## БИНОКЛЬ

Киләчәк үзе йөгереп
килеп баса минем алга!
Телим генә, минем алда –
кешеләр дә,
агачлар да,
мәйданнар да,
кош-кортлар да.

...Әнә әни эштән арып
кайтып килә зур урамнан.
Бинокльдән карадым да –
әни шундук минем янда!

Өстәвенә – сагынылган да!



# СӘГЫЙТЬ БЕЛӘН СӘГАТЬ

Сәгать әйтә:
«Тек! Тек! – ди. –
Уян, торып
киттек!» – ди.
Сәгыйть әйтә:
«Ник? Ник? – ди. –
Йокы килә
бик! Бик!» – ди.

Сәгать әйтә:
«Тек! Тек! – ди. –
Синең эшең
бик күп!» – ди.
Сәгыйть әйтә:
«Көтәр лә!
Үз вакыты
җитәр лә!..»





Сәгать әйтә:
«Тек! Тек! – ди. –
Сәгыйть, яхшы
ишет! – ди. –
Вакытыңны
әрәм итмә
бөртек! – ди. –
Без, сәгатьләр,
бик күп! – ди. –
Сезнең гомер
бер тик! – ди. –
Йоклап ятма,
киттек! – ди. –
Максатларга
җитик! – ди. –
Илгә хезмәт
итик!» – ди.

...Сәгыйть торды
уянып.
Сәгать сукты
куанып!

# Фирая Зыятдинова

*(1945–2006)*



**Туган көне**

5 нче сентябрь.

**Туган урыны**

Татарстанның Әтнә районы Мамыш авылы.

**Тормыш юлы**

Фирая Зыятдинова, кичке урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының тарих-филология бүлегендә югары белем ала. Бер ел мәктәптә укыта. 1969 елда Татарстан китап нәшриятына эшкә урнаша һәм утыз ел буена шунда мөхәррир булып эшли.

Ф.Зыятдинованың беренче шигъри тәҗрибәләре мәктәптә укыган елларында ук матбугат битләрендә – башта район газетасында, алга таба республиканың үзәк газета-журналларында басыла. 1968 елда лирик шигырьләре яшь авторларның күмәк җыентыгына – «Беренче карлыгачлар» китабына урнаштырыла.

Ул – лирик шагыйрә. Аның төп темалары – яшьлек мәхәббәте, кеше күңеленең матурлыгын, сафлыгын, табигать белән бердәмлеген данлау, яшәүнең кадерен белү, нинди очракта да аның бәхет икәнлеген тою. Шигырьләре хискә, кичерешләргә бай. Шунлыктан аның күп шигырьләре көйгә салынган.

Шагыйрәнең балаларга атап язган шигырь китаплары һәм басмада дөнья күргән тәрҗемә әсәрләре дә бар.

**Төп басма китаплары**

* Матур буласым килә : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1986.
* Язгы ярсу : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1988.
* Ташкын : шигырьләр, җырлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991.
* Айнур : балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1995.
* Мин кояшка елмаям! : шигырьләр, җырлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2000.
* Бака туе : мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2003.
* Утның яшисе килә : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.

## ТАТАРЧА БЕЛМӘҮЧЕ КӘҖӘЛӘР

Шундый безнең Алиябез:
Үлеп әкият ярата.
Сөйли аны әнисе дә,
Сөйли аны Марат та...
Әкият иле Алиянең
Туган иле диярсең!..
Бердәнбер кызың сорагач,
Әллә ниләр сөйләрсең.
«Козлятушки, дитятушки,
Ваша мать пришла –
Вам молочка принесла...»
Кәҗә шулай җырлый, диеп
Сөйләп китә әнисе.
Урысчалап такмаклауга
Алия соң ни дисен?!
Тыңлап-тыңлап тора да ул
(Тыңлый белә ул үзе!),
Әнисе сөйләп бетергәч,
Әйтеп куя үз сүзен:
– Бу кәҗәләр бер генә дә
Татарча белмиләрме?
Татарчаны белмәгәнгә,
Урысча сөйлиләрме?



## КОШЛАР ТУЕ

Җимлек ясады Айнур,
Шундый матур җимлеге!
Кызылтүшләр, песнәкләр
Белсен әле кемлеген!

Коштай очып, канатланып
Чыгып китте урамга –
Үзе ясаган җимлекне
Талга элеп куярга.

Иртәгесен ниләр күрсен! –
Вәт тамаша, вәт уен!
Әллә сабан туемы бу?
Юк ла, бу – кошлар туе.

Бөтен урман кызылтүше,
Бөтен урман песнәге –
Бар да шунда җыелган,
Авыз итик әле, диеп,
Айнур дусның сыеннан...

Айнурның бит дуслары да
Үзе кебек уңганнар:
Иртәгесен ботак саен
Җимлек элеп куйганнар!

Бу ни гаҗәп хәл бу тагын?
Ни тамаша, ни уен?
Әллә сабан туемы бу?
Юк ла, бу – кошлар туе!



Бөтен урман кызылтүше,
Бөтен урман песнәге
Бар да шунда җыелган,
Авыз итик әле, диеп,
Дусларыбыз сыеннан.

Чыпчыклар да очып килгән,
Күгәрченнәр җыелган...
Кем соң инде баш тартсын ди
Шундый кунак сыеннан?!



# Ринат Мәннан

*(1946)*



**Туган көне**
6 нчы февраль.
**Туган урыны**
Татарстанның Чистай шәһәре.
**Тормыш юлы**

Ринат Мәннан (Архипов), 1960–1964 елларда Казан медицина училищесында белем алганнан соң, бер ел Самара өлкәсенең Клявлино районында фельдшер булып эшли. Армия хезмәтеннән кайткач, 1968–1974 елларда Казан дәүләт медицина институтында укый. Башта Мордовия Республикасында, аннары Чистай шәһәрендә табиблык итә. 1978 елда Казанга күчеп килә һәм «Тасма» оешмасында, башкаланың Авиация һәм Мотор төзү заводларында, Казан дәүләт университетының сәламәтләндерү үзәгендә табиб булып эшли.

Р.Мәннанның «Умырзая» исемле беренче китабы 1998 елда дөнья күрә. Шигырьләре республика газета-журналларында басылып чыга.

Ул күбесенчә пародияләр һәм юмористик-сатирик шигырьләр яза, балалар өчен дә актив иҗат итә.

1993 елда «Молодёжь Татарстана» газетасы оештырган фантастик хикәяләр конкурсында беренче урынны яулый.

**Төп басма китаплары**

* Табиб әлифбасы. Казан : Раннур, 2001.
* Ялкау өстәл : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.
* Исхакый әлифбасы. Казан : Матбугат йорты, 2008.

**Яулаган үрләре**
Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының К.Насыйри исемендәге премиясе дипломанты (2007).



## ТУН КИГӘН АКБАЙ

Салып аттым туфлиемне,
Салдым мин күлмәгемне.
Су буена комга яттым –
Кыздыр, кояш, тәнемне!

Гәзиттән башлык ясадым,
Эссе капмас башыма.
Акбаем да рәхәтләнеп
Ятты минем каршыма.

...Ул да инде – туны аша! –
Кызынам дип маташа.

## ӨЙДӘ КАЛГАЧ...

Илнур радио тыңлый,
Әтисе киткәч чыгып.
Шөрепләрен борып алган –
Эчен карый тырышып.

Кай җирендә сөйләшәләр?
Җырлый радио ничек?..
Шул чагында бүлмәсенә
Ачылып китә ишек.

– Әй, улым, ник радионы
Ваттың? – ди әти-әни.
– Мин эзләдем артистларны,
Анда алар күренми...





## КАЯН КИЛӘ ТУҢДЫРМА?

Сез, малайлар, беләсезме,
Каян килә туңдырма?
Белмәсәгез, тыңлагыз. Бу
Бер дә түгел уйдырма.

Җир шарында, бик еракта
Котып дигән урын бар.
Анда җәен дә, кышын да
Искитәрлек татлы кар!

Әнә шунда, шул котыпта,
Яши икән Баш аю.
Ул бик юмарт аю икән,
Анда юктыр масаю.

Шул котыптан самолётлар
(Болай булмас дип торма!)
Ташып тора бертуктаусыз
Ап-ак тәмле туңдырма.

Баш аюның пәкесе бар,
Ул матурлап кар кисә...
Кичә генә шуннан кайттым.
Әй тутырды туңдырмалар!..
Әллә булды ун кесә?!

# Ләлә Сабирова

*(1947)*



**Туган көне**
1 нче март.
**Туган урыны**
Татарстанның Биектау районы Мәмдәл авылы.
**Тормыш юлы**

Ләлә Сабирова (Гыймадиева), Мәмдәл урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала. Аннары ике ел «Татарстан яшьләре» газетасында әдәби хезмәткәр, 1971–1988 елларда Биектау районының Олы Битаман авылы урта мәктәбендә тел-әдәбият укытучысы һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли. 1988 елдан, Казанга күчеп килеп, «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») газетасына эшкә урнаша. Анда әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип, баш мөхәррир урынбасары, 1995–2004 елларда баш мөхәррир вазифаларын башкара. Бүгенге көндә ул – «Сабантуй» газетасында җаваплы сәркатип.

Л.Сабирова – балалар язучысы. Аның хикәяләре көндәлек матбугатта алтмышынчы еллардан бирле басылып килә. 1986, 1999 елларда Татарстан китап нәшриятында беренче басма китаплары («Кызарган алмалар», «Мыеклы фәрештә») дөнья күрә. Аның хикәяләре җыйнаклыгы, балалар күңеленә үтеп керә торган сәнгатьчә тәэсирлелеге, ялыктыргыч дидактика, үгет-нәсихәтнең булмавы белән аерылып тора.

**Басма китаплары**
* Кызарган алмалар : нәни хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1986.
* Мыеклы фәрештә : балалар өчен хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1999.
* Чуфут-кале малайлары : маҗаралы повесть. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.
* Мин аңа бәхет телим : балалар өчен хикәяләр, повесть. Казан : Татар. кит. нәшр., 2007.

**Яулаган үрләре**
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1997).

## УЛ ДӨНЬЯДА БЕРҮЗЕ

Өй түрендәге бакчаларына чыккан иде Нурзат, андагы аллы-гөлле чәчәкләрне күреп исе китте. Әле кайчан гына боларның берсе дә юк иде! Кызгылт сарылары, шәмәхә төслеләре, җете зәңгәрләре күз явын алып утыралар. Малай йөгереп килде дә чәчәкләрне ашыга-ашыга йолкый башлады. Бабасы чыгып эшне бозды.

– Нурзат, балакаем, нишлисең син? Тимә чәчәкләргә, утырсыннар шулай бакчаны ямьләп.

– Өйгә алып кереп утыртам мин аларны. Өйне ямьләп торсыннар, – дип карышты Нурзат.

Бабасы иплəп кенә оныгының кулларыннан алды.

– Өй өчен үзем җайлап өзеп бирермен, яме. Болай йолыккаласаң, еларлар бит алар, үпкәләрләр сиңа.

Ул Нурзатны өйгә кертеп җибәрде дә, көрәген алып, түтәл казырга тотынды.

Малай кухня ягына авызын турсайтып кереп басты.

– Әйдә, кишер суыңны эч тә, киттек, – диде әнисе, аны өстәл артына утыртып. – Бакчада тәрбияче апаң көтәдер инде сине.

Һаман шул кишер суы, һаман шул бакча. Нурзат киреләнә-киреләнә генә атлады.

– Нигә гел көйсезләнеп кенә торасың икән син, улым, ә? Ни кирәк соң сиңа? – дип аптырады әнисе.

– Әйдә, сагыз алып чыгыйк, теге, карбыз исе килеп торганын, – диде Нурзат, чаттагы таныш кибеткә җитәрәк. – Аннары көйсезләнмәм.

Әнисе улын җилтерәтебрәк алып китте.

– Каян өйрәндең болай сөйләшергә, ә? Менә әтиеңә әйтермен әле.

Бер нәрсә булса, ул шулай әтисе белән куркыта башлый. Тими лә аның әтисе Нурзатка, тик менә андый чакта машинасына гына утыртмый.

– Әниеңне тыңламасаң, беркая да алып бармыйм, – дип кисәтә.

Бакча ишегалды бала-чага чыр-чуыннан гөжләп тора иде. Нурзат әнисенең кулыннан ычкынды да иптәшләре арасына кереп чумды. Ул да булмады, кисәк кенә елашкан, чинашкан тавыштан ишегалды кузгалып куйгандай булды. Апалары атылып килеп җиткәндә, комлыкта күз яшьләренә күмелгән Сәлим утыра, аның янында ачулы йөзле Нурзат басып тора иде.


Рәхим итегез

– Ник алган ул минем машинаны?! – диде ул, апасы сорау биреп өлгергәнче үк. – Кичә мин калдырган идем аны комлыкта!

– Монда синеке-минеке юк бит, Нурзат! – диде апасы кисәтүле тавыш белән. – Комлыкта калдырып та дөрес эшләмәгәнсең, уйнагач, кертеп куярга кирәк иде.

Тагын ул гаепле! Юктан да авызын бәлешләндереп еларга тотына бит ул Сәлим. Әй, мәсәнә машинаңны, бик кирәге бар иде! Нурзат уенчыкны атып кына бәрде дә, кулларын кесәләренә тыгып, читкә китеп утырды.

Кичен әнисе алырга килгәндә, ул бик арыган кыяфәттә иде.

– Кайчан ял көне җитә инде, туйдым бу бакчадан, – дип зарланды.

Кичке ашта да кәефсезләнеп утырды.

– Тагын кәбестә шулпасымыни? Икенчегә солы боткасымы? Әй, ашыйсым килми лә минем боларны! Пирожный булса иде ул менә!

Икенче көнне Нурзатны берәү дә кереп уятмады, ул үзе торып киенде. Кухняга кергән иде, анда да беркем юк иде. Бик иртә микәнни, тормадылар микәнни әле? Нурзат урындыкны сөйрәп китерде дә, ашыга-ашыга шуның өстенә менеп басып, буфетның өске ишеген ачты. Әнисе бөтен тәмнүшкәләрне шунда яшерә, Нурзатка берәмләп кенә алып бирә. Малай башта зур гына бер «Сникерс» тартып чыгарды, аннары борчак конфетларны, учлап алып, кесәсенә тутырды. Ялтыравык кәгазьгә төрелгән ике сагыз да эләгеп чыкты. Аннары, урындыгыннан сикереп төшеп, бакчага чыгып йөгерде. Теге аллы-гөлле чәчәкләрне кочак тутырып җыйды. Тик өйгә алып кереп җиткермәде, әнисе исенә килеп төште дә, чәчәкләрне баскыч төбенә куеп калдырып, йокы бүлмәсенә йөгереп керде. Монда беркем дә юк иде! Әбисе белән бабасы яши торган бүлмә ишеген дә ачып карады, анда да берәүне дә күрмәде. Нурзат кабат урамга чыкты, гараж янына килде. Гаражның йозагы бикле түгел, әтисенең машинасы урынында иде. Нәрсә була соң бу? Әй, нәрсә булсын, кайчан да булса бер кайтырлар, әллә кая китмәгәннәрдер. Малай машина ишеген тартып караган иде, анысы да ачык булып чыкты. Менә, рәхәтләнеп бер урам әйләнсен әле! Ничек кабызырга, кайсы педальләргә басарга икәнен белә ул, карап торганы бар. Тегендә-монда төрткәләве булды, машина гүелдәп эшли дә башлады. Гараж ишеген бәреп кенә чыгып китте, рульне чак тотып өлгерде Нурзат. Әй җилдерә малай урам буйлап! Тик ни гаҗәп, урамда бүтән бер машина да юк. Башка шофёрлар йокыла-

рыннан тормадылар микәнни әле? Шулай уйлап кына бетерде, машинасы, тузан туздырып, теге, бакча юлы өстендәге кибет каршысына килеп туктады. Кибетнең ишеге ачык, тик кергән-чыккан кеше күренми. Нурзат, кыюланып, үзе кереп китте. Анда сатучы да юк иде хәтта. Ә шүрлекләрендә нәрсәләр генә юк! Малай дәшеп-дәшеп карады да, тавышын берәү дә ишетмәгәч, прилавка артына үзе кереп китте. Әнисенең, «ярамый» дип, күптән алып биргәне юк иде инде, рәхәтләнде Нурзат чипсы, кириешки, тагын әллә нинди ул белмәгән тәмнүшкәләр ашап. Ашап туйгач, кесәсенә дә салды, изүенә дә тутырды. Менә ничек рәхәт икән үзең генә булгач! Аннары каршыдагы уенчык кибетенә керде. Күпме сорап та әтисе «хәзергә акча юк» дип алмый йөртә иде, нинди төре бар, бөтен уенчык автоматларны да төяп чыкты малай. Чөнки монысының да кибетчесе юк иде, берәү дә акча сорамады. Автоматларын кочаклап, туры бакча ишегалдына килеп керде. Билгеле инде, монда да берәү дә күренмәде. Рәхәтләнеп берүзе комлыкта тәгәрәде Нурзат, беркем дә комачауламады. Ул елак-мылак Сәлимнәрдән туеп беткән инде! Тик менә бераздан ашыйсы килә башлады Нурзатның, апалары булмагач, ашарга да чакыручы булмады. Малай аш бүлмәсен үзе эзләп китте. Плитә салкын, аш та пешмәгән иде. Үзе пешереп караса гына инде... Плитәсен кабыза алды Нурзат, кәстрүлен дә утыртты, тик менә анда нәрсә саласы? Актара торгач, солы ярмасы табып алды. Ярар, ашыйсы килгәндә, анысы да ярап торыр. Пешерә торгач, ботка ташый башлады, кабара-кабара ишеккә хәтле барып җитте. Нурзат нишләргә дә белмәде. Буш чиләкләргә дә салды ботканы, өстәл тартмаларына да тутырды, аннары, урам якка йөгереп чыгып, аш бүлмәсенең ишеген тышкы яктан теге уенчык автоматлары белән терәтеп куйды. Алай да булмады, ботка, быкыр-быкыр килеп, ишекне эчке яктан этә башлады. Нурзат ишекне аркасы белән терәде дә бөтен көченә кычкырып җибәрде:

– Әни-и!

Тавышы чыкмады, аның каравы беркем дә әйткәнне көтмичә... караватыннан сикереп торды малай. Төш күрә икән ләбаса ул! Аңа шундый рәхәт булып китте. Тиз генә киенеп, кухня ягына чыкты.

– Улым зур үскән икән, әйтмичә дә торып чыккан, – дип сөенде әнисе. – Әйдә, юынып ал да өстәл янына утыр!

Әнисе шундый тәмле солы боткасы пешергән. Телеңне йотарлык. Кишер суын да бик яратып эчте Нурзат. Ишегалдына чыккач, рәшәткә аша бакча

гөлләренә күз төшерде. Бигрәк матур булып утыралар. Гараж да буш, әтисе күптән чыгып киткәндер инде. Аннан башка мәңге утырачак түгел ул машинага. Теге кибет тә үз урынында икән, юк-юк, чипсы-мипсылары кирәк түгел, тамак туйдыра торган нәрсә түгел алар, әнисе дөрес әйтә.

Бакча ишегалды гадәттәгечә гөж килә. Менә ничек күңелле! Үзең генә булганда бер кызыгы да юк бит аның. Сәлимне дә елатмас, уйнасын әйдә, аннан башка күңелсез булыр ул.

Дөньяда үзең генә булсаң, бик-бик күңелсез була икән бит ул!

# Флёра Тарханова

*(1947)*



**Туган көне**
25 нче май.
**Туган урыны**
Татарстанның Чистай районы Яуширмә авылы.
**Тормыш юлы**

Флёра Тарханова, Яуширмә сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, 1962–1966 елларда Арча педагогия училищесында укый. 1966–1970 елларда Чистай районының Чирүле Шонталысы, Кыргызстанның Ош өлкәсе мәктәпләрендә математика һәм рус теле фәннәрен укыта. 1970–1975 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. Ун елдан артык «Радиоприбор» заводында инженер-конструктор булып эшли. Узган гасырның туксанынчы елларыннан башлап Ф.Тарханова хезмәт юлын журналистика белән бәйли: «Шәһри Казан», «Татарстан хәбәрләре» газеталарында тәрҗемәче, тәрҗемә бүлеге мөдире була. 1995 елдан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында тәрҗемәче һәм баш референт, соңрак беркетмәләр бүлегендә баш киңәшче вазифасын башкара. 2005 елда «Эш кәгазьләрендә һәм рәсми документларда русча терминнарның татарча эквивалентлары» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда, әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Ф.Тарханова зурлар өчен дә, балалар өчен дә яза. Шигырьләре тематик яктан әдәп-әхлак, тәрбия мәсьәләләрен күтәрүләре белән үзенчәлекле. Шигъриятенә шулай ук сагыш-шатлыклар белән сугарылган мәхәббәт мизгелләре, балачак, яшьлек хатирәләренә бәйле табигать күренешләре, туган авыл, яшәеш, милләт язмышы турында уйланулар хас. Ул төрле кулланма-ярдәмлекләр белән беррәттән рус, украин, азәрбайҗан язучыларының хикәяләрен, аерым авторларның китапларын да татарчага тәрҗемә итә.

**Төп басма китаплары**

* Уңган кыз : балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1998.
* Серле дөнья : балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2002.
* Яшьлек эзем калган сукмаклар : шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.
* Алтын уклар : әкият. Казан : Мәгариф, 2007.
* Язмышлар язылганда : шигырьләр, хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2007.

**Яулаган үрләре**
Татарстанның Мактау грамотасы иясе (2002), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2007).

## ЯШЬТӘН ӨЙРӘН ТӘРТИПКӘ!



Син, курчагым, киемеңне
Кадерсезләп аунатма,
Китапларыңны буяма,
Уенчыгыңны ватма.

Әйберләреңне ташлама,
Бөтен җирне туздырып,
Бүлмә буйлап чабып йөрмә,
Атлардан да уздырып.

Бар нәрсәң урынлы булсын –
Уйнап туйгач, җыештыр.
Үз артыңнан эш ясама,
Әнием дә орышыр.

Үскәч кенә әдәп кермәс,
Күп мәртәбә әйтеп тә.
Мактаулы кыз булыйм дисәң,
Яшьтән өйрән тәртипкә!

## НӘНИ ДИЛӘ

Бик нәни булса да, Дилә
Чисталыкны ярата:
Үрмәләп кенә йөрсә дә,
Бар чүпне җыеп ата.

Өстәлдә тотмый бер дә
«Артык» тәлинкә-кашык.
Сыпырып кына төшерә,
Авызың торсаң ачып.



## НӘКЪ ӘКИЯТ ДИЯРСЕҢ

Кышның бозлы таулары,
Шыгыр-шыгыр карлары,
Тәрәздәге бизәкләре,
Чыршыдагы шарлары –
Бар да матур, тылсымлы,
Нәкъ әкият диярсең,
Шушындый гүзәл дөньяны
Сөймәс җирдән сөярсең.



## УЙНАВЫ РӘХӘТ ТЫШТА

Дәресемне әзерләгәч,
Киендем дә тиз генә
Дуслар янына уйнарга
Элдердем җитез генә.

Урам матур, чип-чиста,
Уйнавы рәхәт тышта.
Тәгәрәшеп тау шуабыз,
Рәхмәтләр әйтеп кышка.

# Рафаил Газизов

*(1947)*



**Туган көне**

26 нчы апрель.

**Туган урыны**

Татарстанның Мамадыш районы Кече Кирмән авылы.

**Тормыш юлы**

Рафаил Газизов, Мамадыш урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, бер ел Кече Кирмәндә укытучы булып эшли. 1966–1971 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала һәм туган авылы мәктәбендә уку-укыту бүлеге мөдире, 1972 елдан директор вазифаларын башкара. 1981–1986 еллар арасында читтән торып Казан дәүләт педагогия институтының тарих бүлеген тәмамлый.

Р.Газизовның шигырьләре көндәлек матбугатта узган гасырның алтмышынчы елларында күренә башлый. 1985 елда лирик шигырьләре тупланган «Бөре керфекләре» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә, 1988 елда кече яшьтәге балалар өчен «Җиләкле алан» дигән икенче шигъри китабы басыла. Шигърияттә Р.Газизов – авыл җырчысы. Ул авыл кешеләренең уй-хисләрен, эчке дөньясын яхшы тоемлый һәм иҗатында шуны ачык чагылдыра. Яшәеш хакыйкате, авылның киләчәге турында уйлана, өлкән буын белән яшь буын арасындагы гармониянең бозылуына борчыла.

**Төп басма китаплары**

* Бөре керфекләре : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1985.
* Җиләкле алан : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1988.
* Хат : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1994.
* Түбән оч малайлары : чәчмә әсәрләр. Казан : Татар китабы, 1998.
* Бүләгем : шигырьләр. Казан : Мәгариф, 2003.

**Яулаган үрләре**

РСФСРның халык мәгарифе отличнигы (1988), Татарстан Язучылар берлегенең Ш.Маннур һәм Ф.Хөсни исемендәге премияләре лауреаты (1991, 2003), Татарстанның атказанган укытучысы (1994), Г.-Х.Андерсен исемендәге халыкара Почётлы диплом иясе (2006).



## ШАТЛЫК

Иртән коеп яңгыр яуды,
Су ялтырый юлларда.
Көндез адаштым урамда
Күз ачкысыз буранда.

Абый эзләп чыккан мине
Һәм тапты әбиләрдән.
Өйдән чыксак, кар көртләре
Гөрләвеккә әйләнгән.

Киң урамнар тулып ага
Ап-ак буранның суы.
Шатлык безгә – яз да, көз дә,
Җәй дә, кыш та булуы.

## МӘЧЕ ЙӨРИ ЕЛГАДАН

Ыргадан, мыргадан –
Мәче йөри елгадан...
Йөрми лә мәче елгадан,
Йөри безнең коймадан.

Шулкадәр йомшак йөри,
Нәфис йөри, сак йөри.
Егылам дип курыкмый,
Цирк клоуны кебек,
Кулга колга да тотмый.

Тәпиләрен салмак кына
Койма башына сала.
Яңа гына яуган карда
Серле, матур эз кала.

Мәчебезнең күршеләргә
Хәл белергә керүе, –
Татулык һәм дуслык юлын
Такырайтып йөрүе.

Күршеләрнең шундый матур
Песиләре бар, беләм.
Безнең песи ахирәт бит
Шул чибәр песи белән.

Әби, бабай, әтиләр дус,
Әниләр дус ич, беләм.
Шуңа күрә мин үзем дә
Мәчебез салган сукмактан
Алсу янына керәм.

Ыргадан, мыргадан –
Мәче йөри елгадан...



## КИТАБЫМ



Җәй көне болында
Чәчәкләр җыйдым мин,
Аларны китапка
Кыстырып куйдым мин.

Әгәр дә, кыш җиткәч,
Сагынсам җәй көнен:
Чәчәкле болыным –
Китабым бар минем.

Актарам битләрен.
Һәр биттә – бер чәчәк.
Йокларга яткач та
Төшемә керәчәк.

Төшемә керә шул
Авылым гөлләре.
Җемелди китапта
Ямьле җәй
көннәре.

# Рәшит Бәшәр

*(1949)*



**Туган көне**
7 нче октябрь.
**Туган урыны**
Татарстанның Кукмара районы Яңил авылы.
**Тормыш юлы**

Рәшит Бәшәр, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1967–1972 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. Аннары Лениногорск районының Куакбаш авылы мәктәбендә, Лениногорск шәһәренең 32 нче номерлы һөнәр-техника училищесында һ.б. урыннарда эшли. 1987–1989 елларда Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларда укый. Укуын тәмамлап кайткач, Чаллы шәһәрендәге «Таң йолдызы» газетасында – бүлек мөдире, җаваплы сәркатип, «КамАЗ» газета-китап нәшриятында – мөхәррир, «Аргамак» (2001 елдан «Мәйдан») журналында җаваплы сәркатип һәм әдәбият бүлеге мөхәррире булып эшли. Бүгенге көндә ул лаеклы ялда.

Р.Бәшәр, нигездә, балалар өчен шигырьләр һәм проза әсәрләре иҗат итә. Шигърияте тулысынча сурәтлелеккә нигезләнгән. Кечкенә генә шигырьдә дә маҗаралы детальләр, хәрәкәт, вакыйгалар агышы өстенлек итә. Бу исә укучыны фикер йөртергә, уйланырга этәрә. Прозасында кеше шәхесенең рухи дөньясы социаль-әхлакый, тәрбия, табигатьне саклау мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнештә гәүдәләндерелә.

**Төп басма китаплары**
* Әйлән-бәйлән : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1975.
* Бәйрәм : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1977.
* Иртәгә дә яшисе бар : повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1989.
* Сандугачлы бишек : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2000.
* Ачык капка : хикәя, повестьлар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2004.
* Җәй кызы : шигъри әлифба. Казан : Мәгариф, 2007.
* Йолдызлы тай : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.

**Яулаган үрләре**
Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты (2000).

## БӘБКӘЛЕ БОЛЫН

Алар мине әниләре
Диеп, ахры, беләләр.
Томшыкларын суза-суза
Пипелдәшеп киләләр.

– Йомшакларым минем! – дип
Эндәшәм үзләренә.
Сары кояш томшыкларын
Төртәләр тезләремә.



Ипи бирәм, су эчертәм
Һәм сыйпыйм йоннарыннан.
Көн буена берничек тә
Киталмыйм яннарыннан.

Әллә ничек моңсу итеп
Карап торалар күзгә.
Сыеналар бер-берсенә,
Пипелдәүләре үзгә.

Дерелдиләр, кинәт кенә
Салкын яңгырлар яуса...
Их, шунда әниләренең
Канат аслары булса!

Җылы мамыкка күмелеп
Черем итәрләр иде.
Тыңлаусызларын ана каз
Бераз битәрләр иде.

Юк шул инде... Юк шул инде
Тилгәннәрне куркытырлык
Бик батыр әниләре.
Әрекмән астына поса
Инкубатор бибиләре.

Пипелдиләр...
Бу аларның
Күз яшьсез үксүләре.
Бәбкәгә дә рәхәт түгел
Әнисез үсүләре...

## ТАНЫШУ

Күрсәтим дигән идем
Русча белгәнемне,
Әтәч тә аңламады:
– Привет! – дигәнемне.

– Ки-ке-ри-күк! – диде дә
Очты кунды киртәгә.
Акбай әйтә: – Татарча
Исәнләш, – ди, – иртәгә!



## ҺАВАДАГЫ АБЫЙЛАР

Кран
Кама ярына баскан
Зур челәнгә охшаган.
Бик биектә
Абыйлар
Болытларны
Тотып-тотып карыйлар.

Рәхәтләнеп йөриләр
Һавадагы аланда.
Мин дә менәр идем дә,
Тик меналмыйм мин анда.

Бәләкәй булсам, бәлки,
Җил ярдәм итәр иде.
Шул абыйлар янына
Бастырып китәр иде.

Бер кызык итәр идем,
Болытны тотар идем.
Кранны, абый кебек,
Як-якка борыр идем.

Ничек тизрәк үсәргә?
Кранчы булыр идем.

# Фәйрүзә Мөслимова

*(1954)*



**Туган көне**
9 нчы июль.
**Туган урыны**
Татарстанның Актаныш районы Иске Балтач авылы.
**Тормыш юлы**

Фәйрүзә Мөслимова, Актаныш урта мәктәбен тәмамлагач, 1972–1980 елларда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә югары белем ала. Соңгы курста укыганда ук, «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») газетасында эшли башлый. 1979–1980 елларда Казанда С.П.Горбунов исемендәге авиация берләшмәсенең «Алга» исемле күптиражлы газетасында – хәбәрче, 1981 елдан «Ялкын» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире вазифаларын башкара.

Ф.Мөслимованың беренче әдәби язмалары Актаныш районының «Игенче даны» (хәзер «Актаныш таңнары») исемле төбәк газетасы һәм республика балалар газетасы «Яшь ленинчы» битләрендә басыла. 1990 еллардан башлап ул даими рәвештә «Казан утлары», «Татарстан», «Сөембикә» журналларында, «Шәһри Казан», «Сабантуй» газеталарында актив языша. 1992 елда лирик шигырьләре «Бер тауда ун чишмә» исемле күмәк җыентыкта урнаштырыла, балалар өчен язган шигырьләре «Алтын капка» исеме белән «Аргамак» журналында бирелә. 2001, 2004, 2009 елларда Татарстан китап нәшриятында «Ярату яралары», «Апрель кары» һәм «Алтын йозак» исемле мөстәкыйль китаплары дөнья күрә.

Фәйрүзә Мөслимованың шигърияте табигыйлеге, ихласлыгы белән аерылып тора.

**Басма китаплары**
* Ярату яралары : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2001.
* Апрель кары : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2004.
* Алтын йозак : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2009.



## ХЫЯЛЫЙ

Үскәч, капитан булырмын,
Океаннар иңләрмен.
Бәлки, космонавт булып,
Марска ук менәрмен.

Ә хәзергә автобуста
Кунакка китеп барыш.
Шофёр абый, бик сикертмә,
Уйны чуалтма ялгыш!

## КЕСӘ ТЕЛЕФОНЫ

Әти кесә телефонын
Биреп торды бүгенгә.
Чылтыратам Наиләгә,
Диләрәгә, Айгөлгә...

Акчасын әти түлисе,
Борчылып торыйм нигә?
«Кәттә» кыз булып кыланып
Йөреп карыйм әлегә.





## САГЫНДЫМ

Тамагыма салкын тигән,
Бара алмыйм бакчага.
Минем янымда утырса,
Әнинең эше кала.

Әни әйтте: – Син зур инде,
Ялгыз утыр, бул түзем.
Төш җитүгә, озакламам,
Кайтып килермен үзем.

Минут түзәм, сәгать түзәм...
Чыдамлык бетте, дидем.
Караватымнан тордым да
Күчердем сәгать телен.

Сәгать аңлый минем хәлне –
Кичкә авышты инде.
Нигә һаман кайтмый соң ул? –
Бик сагындым әнине.

# Газинур Морат

*(1959)*



**Туган көне**

18 нче август.

**Туган урыны**

Татарстанның Кукмара районы Зур Сәрдек авылы.

**Тормыш юлы**

Газинур Морат, Зур Сәрдек урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. Хезмәт юлын журналистика белән бәйли: 1981–1984 елларда «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә, 1984–1988 елларда «Ялкын» журналында, 1989–1991 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршындагы иҗат берләшмәсендә, аннан соң ике елга якын «Идел» журналында, 1993–1995 елларда «Татар иле» газетасында эшли. Бүгенге көндә ул – «Мәдәни җомга» атналык газетасының баш мөхәррир урынбасары.

Г.Моратның беренче әдәби тәҗрибәләре башта Кукмара район газетасында, аннары республика көндәлек матбугатында һәм «Казан утлары» журналы битләрендә күренә башлый. 1985 елда Татарстан китап нәшриятында «Җир хәтере» дигән шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Аның шигырьләре көтелмәгән чагыштыру-метафораларга, хикмәтле сүз булып китәрдәй тирән мәгънәле гыйбарәләргә бай булуы белән аерылып тора. Ул – үзенә генә хас шигъри алымнарга ия булган, тыгыз фикерле, серле сагыш-моң белән өртелгән, романтик рухлы, бер үк вакытта заманча публицистик яңгырашлы поэзия тарафдары.

**Төп басма китаплары**

* Җир хәтере : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1985.
* Мин дөньяны тыңлыйм : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр, 1988.
* Ачык дәрес : кече яшьтәге балалар өчен шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1995.
* Түбә : шигырьләр һәм поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1998.
* Җәяүле кошлар : публицистик мәкаләләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2002.
* Әкияткә ышанмаучы малай : шигъри әкият. Казан : Мәгариф, 2003.
* Төнге әверелеш : шигырьләр, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.

**Яулаган үрләре**

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге премиясе лауреаты (2000), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), Татарстанның М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты (2007).



### ХЕЗМӘТ

Сыерчык оясы ясыйм.
(Ә кем җимерә, имеш...)
Туган җирдә кошларның да
Өе булырга тиеш.

Кошларга да куыш кирәк,
Салкыннарда, җилләрдә
Сукбай булып йөрмәсеннәр
Туган-үскән җирләрдә...

Кошларга да куыш кирәк,
Шәфкать кирәк кайда да.
Сыерчык оясы ясыйм,
Өй салам кошкайларга.

## ФИЗКУЛЬТУРА

Көн дә күнегүләр ясыйм,
Гер күтәрәм, туп тибәм...
Шаккатмассыз, әгәр мәшһүр
Чемпион чыкса миннән.

Көч-җитезлек бәйгесендә
Эшләрем уңмаса да,
Шаккатмассыз, димен, хәер,
Чемпион булмасам да.

Көчле, нык булып, чыныгып
Үсәсем килә тизрәк.
...Туган илне сакларга да,
Туган телне якларга да
Сәламәт акыл кирәк.





## ТУГАН ТЕЛ

Әткәң-әнкәң телен белсәң,
Адашмассың кайда да...
Туган телемдә эндәшәм
Кояшка да, Айга да.

Туган телемдә аңлашам
Үткән, бүгенем белән.
...Әлифбамны дога итеп
Укыймын күңелемнән.

Игелекле булып үсим
Газиз туган телемә.
Туган тел бер генә була,
Әнкәй кебек – бер генә...



# Зиннур Хөснияр

*(1961)*

**Туган көне**
18 нче июль.

**Туган урыны**
Татарстанның Биектау районы Бикнарат авылы.

**Тормыш юлы**

Зиннур Хөснияр, Олы Битаман авылы урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында белем ала. Студент елларында институт каршындагы «Илһам» әдәби-иҗат түгәрәгенә йөри, алга таба аны үзе җитәкли. Беренче повесть-хикәяләре дә шул елларда языла. Дүртенче курста укыганда, «Ялкын» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире булып; хәрби хезмәттән кайткач, Татарстан радиосында һәм Татарстан китап нәшриятында эшли. Бүгенге көндә ул – «Салават күпере» исемле балалар журналының баш мөхәррире.

З.Хөсниярның беренче басма китабы («Таң ата да кич була» дигән хикәяләр җыентыгы) 1989 елда басылып чыга. Аннан соң «Тәгәри китте язмышлар», «Терсәк сугышы», «Эттән туган» һ.б. китаплары дөнья күрә. Аның әсәрләрендә, нигездә, авыл тормышы, авыл кешеләре образлары гәүдәләндерелә. Шуның белән бергә язучы әхлак нигезләре таркала барган гыйбрәтле вакыйгаларның, кешеләр арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләрнең фәлсәфи асылын ачарга омтыла, тормыш күренешләренә рәссамнарча якын килә, телстиле шома, халыкчан, гади. Ул татар балалар әдәбияты өлкәсендә дә актив эшли.

**Төп басма китаплары**

* Таң ата да кич була : хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1989.
* Тәгәри китте язмышлар : повестьлар, хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991.
* Шүрәле шаяруы : хикәятләр һәм пьеса. Казан : Татар. кит. нәшр., 1996.
* Терсәк сугышы : роман, повестьлар, хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2002.
* Алмачуар әкияте : балалар өчен тарихи әкият. Казан : «Ак барс» нәшр. йорты, 2003.
* Зилә бакчага бара : хикәя. Казан : Татар. кит. нәшр., 2003.
* Эттән туган : роман-дилогия, повесть, хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), Татарстан Язучылар берлегенең Ф.Хөсни исемендәге премиясе лауреаты (2001), Татарстанның М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты (2009).

## КЫШКЫ УРМАН ТАБЫШМАКЛАРЫ...

Урман аланы буйлап кар энҗеләре сибелгән. Җил зур бер чыршыны шыгырдата, ботаклар ботакка бәрелә, алардан ап-ак кар коела, кар белән бергә табышмаклар коела. Күрче, ул табышмакларның җаваплары чәчелеп киткән бит! Хәрефләре буталышып кар өстендә туңып яталар. Әйдәгез, бергәләшеп, аларны тизрәк кар өстеннән җыеп алыйк әле. Йә салкын тияр үзләренә!..

Песидән дә кечерәк ул.
Койрыгын күрсәң менә!
Күз ачып йомган арада
Агач башына менә.
(и т е н)

Ап-ак бүрек тәгәри
Карлы басу буйлатып.
Кишер эзләп чабуымы
Кар бураны уйнатып.
(н я у к)

Хәйләкәр, ди, бик үзе,
Елтырый ике күзе.
Өч тавыкны салып китә
Җилкәсенә берүзе.
(л е т ө к)

Энәле тун кигән ул,
Алпан-тилпән килә ул.
Бу урманда бүредән дә
Курыкмаган сирәк ул.
(е к р п е)

Кыш буена йоклый ул –
Төртсәң дә уянмый ул.
Баллы тамактыр үзе,
Урманда үтәр сүзе.
(ю а)



## ЗИЛӘ БАКЧАГА БАРА

– Кик-ри-кү-үү-үк! – дип кычкырды кызыл кикрикле Әтәч. – Бу өйдә ялкау-лар ю-у-ук!

Инде таң аткан икән, торыр вакыт та җиткән.

– Үс-үс, ү-ү-үс, кызым! – диде Зиләгә әнисе.

– Үз кызым, үз кызым! – диде әтисе.

Зилә күнегүләр ясарга кереште:

– Бер, ике, өч; бер, ике, өч.

Миңа керә көч,

Миндә була көч.

Зилә күлмәк кия, төймәләрен каптыра. Аннары битен юа, ә Песи карап тора.



– Песи, песи, пескәем,
Уеннан һич туймыйсың,
Ник битеңне юмыйсың?
Тычканнарың күрерләр
Һәм үзеңнән көләрләр...

Песи бик тә оялды, кулына сабын алды.

Зилә урамга чыкты, күреп алды Чыпчыкны, үзенә дәште кошчыкны. Чыпчык канат җилпеде, аннары телгә килде:

– Хәерле иртә, хәерле иртә,
Зилә бакчага китә.
Бары ялкау Акбай гына
Һаман да черем итә.

Акбай моны ишетте һәм шартларга җитеште. Зилә аны оялтты:

– Бакчага кәҗә кергән,
Кәбестәне кимергән.
Ишетмәгән, күрмәгән:
Акбай йоклап симергән.

Кызарынды, бүртенде, Акбайга кыен булды, һау-һаулап кәҗә куды.

Зилә бакчага китә, аны әтисе илтә. Зилә җәяүләп бара: ерак түгел ич ара. Бер атлыйсы... Ике, өч, дүрт, биш... Инде юлның яртысы, әнә бакча капкасы, тәрбияче апасы. Килеп җитә ул бик тиз: бер, ике, өч, дүрт, биш...

– Исәнмесез! – ди Зилә.

Тәрбияче апа елмаеп килә. Әтисе китеп бара, Зилә бакчада кала.




## КУЯННАР МӘКТӘБЕ

Алан буйлап элдерә,
Кырлар буйлап йөгерә...
Кырда кала эзләре –
Уйнап үтә көннәре.

– Ник ялкаусың син, Куян?
Мәктәпкә дә йөрмисең...
Бер кишергә берне кушкач,
Ничә була? Белмисең!..

Шулчак Куян телгә килә –
Ул бит сөйләшә белә.
– Мин, – ди, – кибеткә бардым,
Бер букча китап алдым.

Карурманда мәктәп бар,
Без, – ди, – укыйбыз анда:
Төлке түти әкият сөйли,
Аю имтихан ала.

Бүре абый – директор, – ди, –
Поши тарих укыта.
Тукран исә мисал чишә –
Башын кашып утыра.

Дәресләр, – ди, – туган телдә,
Яратабыз, белегез!
Урман теле буладыр ул
Безнең туган телебез.

# Ркаил Зәйдулла

*(1962)*



**Туган көне**
23 нче гыйнвар.
**Туган урыны**
Чувашстан Республикасының Комсомол районы Чичкан авылы.
**Тормыш юлы**

Ркаил Зәйдулла, Чурачык урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1979–1984 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Студент елларында ук «Татарстан яшьләре» газетасында эшли. Шуннан соңгы хезмәт юлы «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй»), янәдән «Татарстан яшьләре» газеталары һәм «Идел» журналы белән бәйле. Бүгенге көндә ул – Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант.

Мәктәп елларында ук каләм тибрәтә башлаган Ркаилнең беренче иҗат тәҗрибәләре – шигырьләре – республика матбугатында 1977 елда күренә башлый. Беренче шигырь җыентыгы («Кояшлы күзләр») 1984 елда басыла. Алга таба «Күрәзә», «Урыс кышын озату» һ.б. китаплары дөнья күрә. Әлеге басмалар җәмгыятьтәге хөр уй-фикер яңарышының татар поэзиясендәге чагылышы итеп бәяләнә. Ул – проза, драматургия, әдәби тәнкыйть һәм публицистик жанрларда да сәләтен күрсәткән әдип. Прозада язучы үзен бигрәк тә тарихи-милли хикәяләр («Тимер Буга», «Тәңре кылычы», «Хан һәм шагыйрь» һ.б.) остасы итеп таныта. Драматургиядә «Саташкан сандугач» исемле драмасы белән билгеле.

Ркаил Зәйдулла – үткен каләмле, туры сүзле публицист. Ул милләт язмышына, дин, тел, мәдәният мәсьәләләренә беркайчан да битараф түгел, аларга матбугат аша үзенең мөнәсәбәтен һәрчак белдереп килә.

**Төп басма китаплары**

* Кояшлы күзләр : шигырьләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1984.
* Күрәзә : шигырьләр һәм поэма. Казан : Татар. кит. нәшр., 1988.
* Урыс кышын озату : шигырьләр һәм поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 1989.
* Ил : хикәяләр, әдәби-публицистик мәкаләләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1999.
* Татар тажы : X–XVIII гасырларда яшәгән олуг кешеләр турында нәни хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2004.
* Мәгарә : шигырьләр, поэмалар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2005.
* Ташка ордым башны : хикәяләр, эсселар. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.

**Яулаган үрләре**

Татарстанның М.Җәлил исемендәге Республика, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты (1990, 2010), Татарстан Язучылар берлегенең Ф.Хөсни исемендәге премиясе лауреаты (2005), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2007).

# АЛТЫН КОЙРЫКЛЫ ТӨЛКЕ

Бишек түшәмнең нәкъ уртасына эленгән кебек иде. Мин йодрыгым белән күземне удым. Бишек алагаем зур булып күренде. Бөтен өйне тутырып тора иде ул. Мин колакларымны томаладым. Ләкин бишектәге энемнең әче тавышы, бармаклар арасыннан саркып, барыбер башымны дөбердәтә бирде. Күрше Фәрит, мине уенга чакырганда, капканы шулай дөбердәтә.

Әнә тагын килеп җиткән әле. Урамга чакыра. Урамда рәхәт. Яңа гына яңгыр явып узды. Юлдагы тәгәрмәч эзеннән гөрләвекләр йөгерешә. Малайлар, шул гөрләвекләрне ерып, диңгез ясап уйныйлар. Кызлар ясаган кәгазь кораблар дулкыннан дулкынга күчә-күчә каядыр ашыга.

Энемнең, ниһаять, тавышы тынды. Мыш-мыш килеп йоклап китте энем. Мин дә, атылган уктай, ишеккә таба очтым.

Малайлар, кызлар Фәритләр турына җыелган иде. Арада бер кызый башкалардан аерылып тора. Чәчендә зәңгәр күбәләк тирбәлә, ак күлмәгендә кызыл алмалар тупырдаша. Аягына кыз ап-ак туфли кигән. Мин, аны күргәч, нигәдер уңайсызланып, игътибар белән үземнең бирчәйгән аякларыма карап алдым. Нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, баш бармакларым кыймылдап куйды.

– Безгә кунак кызы кайтты! – дип кычкырды Фәрит һәм миңа бик тә, бик тә кызганып карап алды.

Хәер, башка малайларга да кунак кызы кайтмаган иде, ахрысы, әнә Нәби кинәт кенә башын артка чөйде, күзләрен уйнатты һәм кесәсеннән кара төстәге бер нәмәрсәкәй тартып чыгарды.

– Магнит... – диде ул серле генә. – Тимерне ун метрдан үзенә сөйрәп ала.

– Ә минем энем бар! – Мин горурланып дусларыма күз йөртеп чыктым.

– Минем дә, – диде Нәби.

– Минем сеңлем менә-ә шуның кадәр. – Фәрит ике кулын ике якка җәеп күрсәтте. – Җитмәсә әле, кунак кызы да кайтты.

Минем түзалмаслык булып күзем әчетә башлады. Кунак кызы нигә безгә кайтмаган икән? Әллә кунак кызы берәү генә буламы?

– Минем энекәшне алтын койрыклы төлке китереп бирде. Вәт! – дидем мин. – Төнлә, сез йоклаганда...



Малайлар эчләрен тотып көлде, кызлар җимгә кунган чыпчыклар кебек чыркылдашты. Тик кунак кызы гына соры күзләрен зур итеп ачып миңа текәлгән иде.

– Алдашырга ярамый, – диде ул. – Бәбиләрне бүлнистә табалар.– Аннары тагын сынап миңа карады. – Әллә шуны да белмисеңме?

Шул вакыт ертык болыт иренеп кенә кояшны каплады. Вак кына яңгыр сибәли башлады. Авыл капкасы янында ат пошкырган тавыш ишетелде. Бераздан ул үзе дә күренде. Арбада иске мылтыгын кочаклап сунарчы Әләү абый утырган иде. Малайлар кунак кызын да онытып аңа таба йөгерделәр. Мин генә каккан казык кебек урынымда басып калдым: Әләү абый янәшәсендә сузылып кызгылт төлке ята иде... Авызы тирәсеннән нәзек кенә сузылып, арбадагы печәнгә мүк җиләгенең суы агып төшкән...

Әләү абый сүгенеп дилбегәне тартты, бер күзе сукыр ат гөрләвек ерып алга атлады. Арбадан төлкенең калын койрыгы салынган иде. Тик ул нигәдер бүген алтынга охшамаган, ә пычракка буялып шәбәргән һәм, белдекле кунак кызы янында басып торган минем кебек, көз ягыннан искән чәнечкеле салкынча җилдән ара-тирә дерелдәп ала иде.

# Лилия Закирова

*(1986)*



**Туган көне**

1 нче декабрь.

**Туган урыны**

Татарстанның Буа районы Кайбыч авылы.

**Тормыш юлы**

Лилия Закирова, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 2004–2009 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетында белем ала. Университетта уку дәверендә «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсенә йөри. Хәзерге вакытта «Җир кадастр палатасы» Федераль дәүләт оешмасында инженер булып эшли.

Л.Закирова балалар өчен хикәяләр иҗат итә. Хикәяләре «Сабантуй» газетасында, «Идел», «Казан утлары» журналларында даими басылып килә. Лилия, «Идел» яшьләр үзәге оештырган «Иделем акчарлагы» бәйгесендә катнашып, 2005 елда – проза, 2007 елда драма жанры буенча беренче урынны яулый. 2007 елда Татарстан китап нәшриятында «Яшерен мәхәббәт» исемле беренче китабы – балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне тасвирлаган, шәфкатьлелек, хезмәт, тәрбия турындагы хикәяләре тупланган җыентыгы дөнья күрә.

**Басма китабы**

* Яшерен мәхәббәт : хикәяләр : Татар. кит. нәшр., 2007.

## НӘРСӘ БУЛГАН РАМИЛГӘ?

Рамилнең ашханәдә үз-үзен тотышы укытучыны аптырашта калдырды. Икенче сыйныфта укучы бу малай, ашханәдә ялгызы гына калгач, иптәшләре ашап бетермәгән ризыкларны пакетка тутыра башлый. Көн саен шул хәл. Ә бит үзе яхшы тормышлы гаиләдән.

Беркөнне укытучы түзмәде, малай янына килеп сүз катты:

– Рамил, нигә сиңа бу ризык калдыклары?

Тегесе гаепле кеше сыман кызарынды, каушап калды.

– Ашарга... Мәрьям Расыйховна, – диде ул аннары, тотлыга төшеп. – Өйгә кайтып җиткәнче карыным ача.

Укытучы уйланып калды. Ул укучысын биш бармагыдай белә. Тикмәгә генә бу эш белән шөгыльләнмәс. Өендә бер-бер хәл булгандыр.

Икенче көнне Мәрьям апа Рамилләрнең фатирына юл тотты. Өйдә әнисе генә иде. Ул да соңгы вакытларда улының сәер гадәтләрен күзәтүе турында әйтте.

– Элек Рамилне көчләп тә сөт эчәргә мәҗбүр итеп булмый иде. Ә хәзер: «Әнием, тагын алып кайт, сөт сәламәтлек өчен файдалы», – ди. Җиткереп булмый. Укудан кайтуга, сумкасын берәр почмакка тондыра да өйдән чыгып йөгерә. «Мәктәпкә, оста куллар түгәрәгенә барам», – ди.

...Ә бу вакытта Рамил, әтисеннән туңдырмага дип алган акчаны күлмәк җиңенә яшереп, даруханәгә кереп бара иде.

– Миңа нәни балаларга сөт эчерә торган шешә һәм имезлек бирегез әле, – диде ул мөлаем гына елмаеп торучы сатучы кызга.

– Нигә ул сиңа? – диде аптекачы, көлемсерәп.

– Э-э... – малай баш артын кашып алды, – энемә кирәк иде.

– Ярый алайса. Менә. Бәләкәчегез тизрәк үссен.

– Рәхмәт!

...Укытучы киткәннән соң, Рамилнең әнисе Фәридә апа үзен кая куярга белмичә йөренде. Нәрсә булган соң аларның сөекле улларына? Бер-бер урам төркеменә эләкмәгәндер бит?! Андыйлар буа буарлык хәзер. Кечерәк балалардан акча сорыйлар. Бирмәсәң, кыйнап ташлауларын көт тә тор! Бәлки, аның улы белән дә шундыйрак хәлдер. Баласын кызганудан ананың йөрәге сыкрап куйды. Тик бу турыда малайның үзенә әйтүдән файда юк. Улы барыбер серне чишмәячәк...

Икенче көнне мәктәптән кайтуга, Рамил көндәгечә каядыр җыена башлады.


– Әни, мин түгәрәккә киттем, ашап торырга вакытым юк, – диде ул.

– Ярар, улым, озак торма.

Аяк тавышлары ерагаюга, Фәридә апа ашыга-ашыга киенә башлады һәм улы артыннан атылды. Рамилнең ботинкаларыннан төшеп калган аяк эзләре подвалга алып бара иде.

Ана, дөп-дөп типкән йөрәген тыярга тырышып, курка-курка гына подвалга төште. Ишекне ачты, мондагы хәлләрне күреп, әздән генә егылып китмәде. Еларга да, көләргә дә белмәде әнисе.

Подвал идәненә чүпрәк-чапрак, картон түшәлгән. Ә алар өстендә... биш көчек баласы. Рамил аларның берсенә көчләп диярлек шешәдән сөт эчереп маташа иде.



Әнисен күргәч, малай сулкылдап елап җибәрде:

– Теләсәң ни эшләт, мин аларны барыбер ташламыйм... – диде ул.

Фәридә апа Рамилне кочагына алды:

– Котымны очырдың бит, улым. Әлләниләр уйлап бетердем. Ә син әнә нишләп йөрисең икән. Кайгырма, үстерерсең, берәр җае табылыр әле...

Кич белән, әтисе эштән кайткач, көчекләре каршына утырып, Рамил «эт балалары турындагы хикәят»ен сөйләде. Аларны ничек табуын, аналары булмавын белгәч кызгануын...

– Менә нинди кайгыртучан икән минем улым, – диде әтисе дә, улының аркасыннан сөеп.

Ә бу вакытта көчек балалары, үзләре турында сүз барганны аңламыйча, ишек катына җәелгән җылы киездә мес-мес йоклыйлар иде.

# Рөстәм Галиуллин

*(1987)*



**Туган көне**
26 нчы ноябрь.
**Туган урыны**
Татарстанның Арча районы Наласа авылы.
**Тормыш юлы**

Рөстәм Галиуллин, туган авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 2004–2009 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетында белем ала. Студент елларында университетның «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсенә йөри һәм әдәби иҗат белән кызыксына башлый. Юморескалар, хикәяләр, публицистик мәкаләләр яза. Аның язмалары башта Казан дәүләт университетындагы татар студентларының «Тәрәзә» газетасы битләрендә, тора-бара республикабызның «Сабантуй», «Шәһри Казан», «Чаян», «Идел», «Казан утлары», «Мәйдан» кебек абруйлы басмаларында дөнья күрә.

Р.Галиуллин студент елларыннан ук «Чаян» журналында, аннары «Шәһри Казан» газетасында эшли. Бүгенге көндә ул – «Шәһри Казан» газетасы журналисты. Проза һәм публицистика жанрында актив эшли, әдәби тәрҗемә (русчадан татарчага) белән шөгыльләнә. Аның балалар өчен язылган хикәяләре шаян, кызыклы, тормышчан вакыйгаларга корылуы, җор һәм йөгерек телле булулары белән игътибарны җәлеп итә.

**Басма китабы**

* Гипнозчы малай : хикәяләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2008.

## ЯРАТКАН ПОЧМАК

Туйдылар, тәмам туйдылар Фаяз белән Илнур балалар бакчасыннан. «Иртәгә бармыйм!» дип, өйләренә кайтып еласалар да, көн саен барыбер илтәләр.

Туйдырды, тәмам туйдырды аларны почмакта басып тору. Тәрбиячене генә күр син: әнә бит Дамир да ашап бетермәгән, аңа бер сүз дә әйтми, ә Фаяз белән Илнурны хәзер шәйләп ала. Соң, булмагач булмый инде тәлинкәнең төбенә төшеп. Аптырагач, Фаяз боткасын өстәл астына бушатып караган иде. Ахыры тагын шул почмак белән тәмамланды... Ярар, монысына ничек тә түзеп була. Алда бит әле йокы сәгате... Уф, тагын ишетеп алды тәрбияче апалары пышылдашып яткан ике малайны.

Туйдылар, тәмам туйдылар Фаяз белән Илнур. Түземлекләре беткәч, качарга уйладылар. Бакчадан уйнап кергәндә, киез итекләрен чистартырга дип калдылар да, тәрбияче апалары күрмәгән арада, бөтен көчләре белән өйләренә илткән тыкрык буйлап йөгерделәр. Тик барыбер ычкына алмадылар. Сатлыкҗан дигән даны чыккан Дамир, аларны күреп, тәрбиячегә әйткән икән – Гөлфия апалары артларыннан куа чыкты. Ничә көннәр буе дулаган буран тыкрыкка кар салган, шуңа да ике дус әллә ни алдыра алмадылар: әле берсе, әле икенчесе кар көртләренә чумып, чыга алмый мышкылдашып беттеләр. Шул арада Гөлфия апалары да килеп җитте һәм, икесенең дә колакларыннан тотып, бакчага, тагын да дөресрәге, газиз почмакларына алып кайтып китте.

Фаяз белән Илнур икенче көнне тәртипле күренергә тырыштылар. Бүген, бәлки, почмакка да басмаслар кебек иде. (Иялә нгән почмаклары ярты көн буш тора инде.) Юк шул, тагын булмады. Йокы сәгатендә тышка чыгып керергә рөхсәт сорады Фаяз. Юлы тәрбиячеләрнең аш бүлмәсе аша иде. Өстәлдәге тезелеп киткән тәм-томнарны күргәч, авызына сулар килде аның. Тиз генә йокы бүлмәсенә кайтып, дусты Илнурга ишарәләр белән хәлне аңлатты. Этлеккә дигәндә, Илнурдан да маһир кеше юк иде. Шул ук сәбәп белән ул да йокы бүлмәсеннән чыкты. Аяк очларына гына басып, теге «тәмле» бүлмәгә юнәлде алар. Тәм-томны ашык-пошык авызларына озатканда:

– Карагыз әле бу нәни каракларны! – дип, кара тавыш куптарды аларны күреп алган мөдир Мәрьям апалары.



– Эх, көн бетте дигәндә генә... – Зур шкафның бер ягыннан Фаязның мышык-мышык килгәне ишетелде.

– Ичмасам, туйганчы ашый да алмадык... – Монысы шкафның икенче ягында басып торган Илнур тавышы иде.

Икенче көнне урамда уйнаганда, алар катгый карарга килделәр: ничек кенә булса да моннан качарга һәм мәктәпкә барырга. Анда йоклатмыйлар да, көчләп ашатмыйлар да икән.

Ике дус планнарын тормышка ашырырга да керештеләр. Иң уңайлы вакытны көтеп, тавышсыз-нисез генә мәктәпкә шылдылар. Икенче катта шау-шу ишетеп, шунда менделәр. Анда линейка бара икән. Берсен-берсе бүлеп кычкырган тавышлар ишетеп, алар якынрак елыштылар.

Директор, завуч һәм укытучылар – барысы да бишенче сыйныфта укучы Фаязның абыйсы Саматны, Илнурның абыйсы Ильярны дәрескә йөрмәгәннәре, икеле алганнары һәм тәртипсез булганнары өчен пыр туздырып сүгәләр иде. Абыйларының башлары түбән иелгән, йөзләре кып-кызыл, күзләре өметсез. Моны күреп Фаяз белән Илнурның котлары очты:

– Монда тагын да начаррак икән! – диде Фаяз.

– Ычкыныйк яхшы чакта, – дип өстәде Илнур.

Алар тиз генә бакчаларына элдерттеләр һәм мыштым гына инде төшләренә керә башлаган, керфекләрен йому белән күз алдына килеп баскан газиз, якын почмакларына барып бастылар...

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

Балачак әдипләре : биобиблиографик белешмәлек : 4 китапта. Казан : Мәгариф, 2002–2008.
Татар энциклопедия сүзлеге. Казан : ТР ФА Татар энциклопедия институты, 2002.
Әдипләребез : биобиблиографик белешмәлек : 2 томда. Казан : Татар. кит. нәшр., 2009.

## ЭЧТӘЛЕК

**Дәрдемәнд** . . . 3
Балалар, әйдә мәктәпкә . . . 4
Ике туган . . . 6
**Фәхрелислам Агиев** . . . 9
Кечкенә карак . . . 10
Сәмруг һәм Май коңгызы . . . 12
**Галимҗан Ибраһимов** . . . 13
Алмачуар . . . 14
**Нәкый Исәнбәт** . . . 19
Тычкан, әтәч, песи . . . 20
Әннә куян . . . 22
Әбәк . . . 23
Бакчада . . . 24
**Хәсән Туфан** . . . 25
Юкмыш бабай малае . . . 26
**Шәйхи Маннур** . . . 31
Урман өендә . . . 32
**Мирсәй Әмир** . . . 35
Алдакчы бозау . . . 36
**Ибраһим Гази** . . . 39
Мәүлия нигә көлде? . . . 40
**Фатих Кәрим** . . . 45
Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл . . . 46
**Җәвад Тәрҗеманов** . . . 51
Кыш . . . 52
Йомшак су, йөгерек су! . . . 53
Табигать китабы . . . 54
Якын дус . . . 54
**Гамил Афзал** . . . 55
Кар сулары . . . 56
Торналар килде . . . 57
Песнәк . . . 58
Көз көне . . . 60
**Гарәфи Хәсәнов** . . . 61
Аккош . . . 62
**Мәхмүт Хөсәен** . . . 65
Пипиләр . . . 66
**Энҗе Мөэминева** . . . 69
Ничек тыңлатыйм? . . . 70
Ул алдан килеп җиткән . . . 71
Кыш бабай хаты . . . 72
**Саҗидә Сөләйманова** . . . 73
Кем уяткан Ләйләне? . . . 74
Чәчәкләр ясыйм . . . 75
Җиде . . . 76
**Әхсән Баян** . . . 77
Булмагач булмый . . . 78
Эт янында тиеннәр . . . 79
Зирәк карга . . . 80
**Аяз Гыйләҗев** . . . 81
Матур . . . 82
**Гөлшат Зәйнашева** . . . 87
Кояш гомере . . . 88
Конфет . . . 89
**Нәҗип Мадьяров** . . . 91
Капмады балык . . . 92
Кара аккош . . . 93
Бик зур мәче . . . 94
**Роза Хафизова** . . . 95
Ак әтәч – затлы әтәч . . . 96
**Мөхәммәт Мәһдиев** . . . 101
Авылдан күчтәнәч . . . 102
**Резеда Вәлиева** . . . 105
Ишегалды бозлавык . . . 106
Шым-шым бабай . . . 107
Хыялый бака . . . 108
**Хәкимҗан Халиков** . . . 109
Аю баласы . . . 110
Агачлар да белә . . . 111
Әкәм-төкәм . . . 112
**Әнәс Хәсәнов** . . . 113
Нәни аучы . . . 114

**Клара Булатова** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Әллә кайсын тыңлыйсы . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Бакчада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Әниемнең кызы юк бит... . . . . . . . . . . . . . . . 122
**Рөстәм Мингалим** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Ак куян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Ә сәгать келт-келт итә . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Чия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
**Рабит Батулла** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Тычкан баласы Чикыл белән ата мәче Мырый . . . . . . 128
**Гакыйль Сәгыйрев** . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Акбай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Без – икәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Бәләкәй Хәмит . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
**Бикә Рәхимова** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Кызыл карлыган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Сана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Чулпанга бөллү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
**Гәрәй Рәхим** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Мин ясаган Кар бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Безнең тауда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Яфрактагы нота . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
**Равил Фәйзуллин** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Табигать кочагында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Бинокль . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Сәгыйть белән сәгать . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
**Фирая Зыятдинова** . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Татарча белмәүче кәҗәләр . . . . . . . . . . . . . . . 148
Кошлар туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
**Ринат Мәннан** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Тун кигән Акбай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Өйдә калгач... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Каян килә туңдырма? . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
**Ләлә Сабирова** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Ул дөньяда берүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
**Флёра Тарханова** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Яшьтән өйрән тәртипкә! . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Нәни Дилә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Нәкъ әкият диярсең . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Уйнавы рәхәт тышта . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
**Рафаил Газизов** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Шатлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Мәче йөри елгадан . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Китабым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
**Рәшит Бәшәр** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Бәбкәле болын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Танышу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Һавадагы абыйлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
**Фәйрүзә Мөслимова** . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Хыялый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Кесә телефоны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Сагындым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
**Газинур Морат** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Хезмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Физкультура . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
**Зиннур Хөснияр** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Кышкы урман табышмаклары... . . . . . . . . . . . . . 182
Зилә бакчага бара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Куяннар мәктәбе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
**Ркаил Зәйдулла** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Алтын койрыклы төлке . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
**Лилия Закирова** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
Нәрсә булган Рамилгә? . . . . . . . . . . . . . . . . 192
**Рөстәм Галиуллин** . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Яраткан почмак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196

Файдаланылган әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . 199